# Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

1995 елның июленнән башлап чыга

№ 5 (1421) 10 февраль 2023 ел

*Татарстанда язылу индексы – П2355.*



**БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:**

madani_zhomga madanizhomga madani_zhomga

2

**Мәскәүгә сәфәребез вакытында татарны борчыган, милләтебезнең алгарышын тоткарлаган күп мәсьәләләр күтәрелде.**

8

**Илһам белән 1952 елда, Теләнче Тамак мәктәбенең тугызынчы сыйныфында укыганда ук дуслаштым...**

11

**Җырчы Гөлназ Гафурова балаларда җыр, сәнгать аша татар теленә мәхәббәт тәрбияләүгә күп көч куя.**

# Мәгъруп һәйкәл булып тора Муса Мәңге тере хәтер сагында...

## БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

● Татарстанның Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы Милли шурасы рәисе Васил Шәйхразыев «Дуслык» ордены белән бүләкләнде.

● М.Гафури исемендәге Башкорт академия драма театрында яңартылган атаклы дипломат Кәрим Хәкимов турында «Кызыл паша» спектакленең премьерасы булды.

● 14 февральдә Татарстан Милли китапханәсендә Бөтендөнья китап бүләк итү көне билгеләп үтелә.

● Әдәбият галимәсе, Казан университеты профессоры Йолдыз Нигъмәтуллина 93 яшендә вафат булды.

● Әлмәт шәһәренең 2 нче китапханәсендә Резеда Фәрхетдинованың Татарстан китап нәшриятында чыккан «Урам керми уйга» исемле китабы тәкъдим ителде.

● Ульяновск шәһәренең 17 нче китапханәсендә Габделҗаббар Кандалыйның 225 еллыгына багышланган түгәрәк өстәл утырышы үтте.

● Башкортстанда халык шагыйрьләре – Нажар Нәҗминең тууына 105 ел, Әнгам Атнабаевның тууына 95 ел һәм Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеевнең тууына 90 ел булуга багышланган «Иртәгә ак кәгазь бите алырмын...» дип аталган иҗади бәйге уздырыла.

● XIX Казан халыкара мөселман киносы фестиваленең гариза бирү кампаниясе башланды.

● Февраль аенда Татарстанның халык язучысы Нурихан Фәттахның «Кырык дүртнең май аенда» әсәре буенча нәфис фильм төшерелә башлый.

### ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

**Васил ШӘЙХРАЗЫЕВ, Татарстан Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе:**

***«Җил тегерменнәнә каршы тора алмаган кебек, без глобализациягә дә каршы тора алмыйбыз. Россиядә һәр баланың – русча, ә дөньяда бөтен кешенең инглизчә беләсе килә. Безгә айкидо көрәшендәге хәрәкәтне кулланып, килгән каршылыкны бөтереп җибәрергә, ягъни катнаш никахлардан туган балаларга татар рухы сеңдерергә кирәк».***

### СЫНАМЫШЛАР

10 февральдә җилле булса, ел яңгырлы була ● 14 февральдә аяз күктә йолдызлар ачык күренсә, яз соң килә ● 15 февральдә кыш белән яз очраша, шунлыктан бу көнне һава торышы нинди булса, яз да шундый килә; кар яуса – яңгырлы ел көтелә; тамчы тамса – бодай, җил иссә – җиләк-җимеш уңа.

### КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **7 сәгать 22 минутта чыкты**, һәм ул **16 сәгать 36 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **9 сәгать 14 минут**. Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **31 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **17 февральдә 9 сәгать 45 минут** тәшкил итәчәк.

### БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

**12 февраль** – язучы, журналист, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Шаһинур Әхмәтсафа улы Мостафинның тууына 75 ел (1948–2020).

**13 февраль** – шагыйрь, педагог Фәрит Таҗетдин улы Ибраһимовның тууына 130 ел (1893–1943).

**14 февраль** – язучы Гайсә Госман улы Гатауллинның тууына 75 ел (1948–2007).

**15 февраль** – фольклорчы галим, филология фәннәре докторы, Татарстанның, Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Хуҗи (Хуҗиәхмәт) Шаһиәхмәт улы Мәхмүтовның тууына 90 ел (1933–2021);

– язучы Заһид Батыр улы Фәйзинең (Фәйзуллин) тууына 90 ел (1933–2013).

### СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Февральнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 10 февраль.**

* * *

Гадәттә, айның соңгы чирегеннән яңа айга кадәр **(13-20 февраль)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә юан эчәклекне чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

### ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

**Бүген рәҗәб аеның 19 нчы көне**

---

**МОСАФИР СӘФӘРДӘН КАЙТТЫ**

**Вахит ИМАМОВ**

# МӘСКӘҮ ТАТАРЛАРЫ ЯНЫНДА

Мәдәни башкала булып саналган Санкт-Петербургтан кайтып ике атна вакыт узуга ук, ил мәркәзен 1918 елда Ленин җәнабләре күчереп куйган Мәскәү каласына сәяхәткә киттек. Элек тә әллә ничә тапкыр барганыбыз бар иде анысы, иллә мәгәр шанлы, гүзәл, европачыл Петербургтан соң патриархаль һәм ташландык Мәскәү урамнары белән танышып йөрү җир белән күк аермасы икән. Питерда – күз карашы белән дә колачлап бетерә алмаслык иркенлек һәм киңлек, утрауларында линейка белән сызып куелгандай төптөз урам, тыкрык һәм мөстәкыйль кишәрлекләр; Европа калалары үрнәгендә төзелгән йорт, собор, канал һәм күперләр; адмиралтейство, патша сарайлары, ат белән чабулап йөрерлек киң мәйданнар, Европа дәрәҗәсендәге һәйкәл, сквер вә парклар... Питерда мәгърифәтлек, зыялылык, хөрлек, итагатьлек, затлылык вә горурлык. Ә Мәскәүдә йортлар берсе өстенә икенчесе атланып утырган, әле аларның да берсен ике-өч ел гына элек яртылаш пыяладан, яртылаш затлы кирпечләрдән өеп куйсалар, аның янәшәсендә үк 1960 елларда бер-берсенә эретеп ябыштырган бетон плитәләрдән йә силикат кирпечләрдән өйгән «хрущевка»лар, йә утызынчы елларда ук салынган ике-өч катлы, унбиш-егерме фатирлы «сыерчык оялары». Андый йортлар Казанда да житәрлек, бик аптырамас та идең, мәгәр шул йортлар артында гына инде яртылаш җимерелгән, бина тирәләре машина йә төзелеш материаллары, яисә кәнкүреш калдыклары белән тулган әллә нинди вак-төяк оешма-предприятие хәрабәләре тезелешеп китә. Үзәктәрәк кайбер урамнарда Мәскәү каласына керү-чыгу газабын җиңеләйтү өчен, урыны-урыны белән хәтта утызар метр биеклектә, бишәр чакрым озынлыктагы бетон эстакадалар да төзи башлаганнар, ләкин мәгълүм сәбәпләр аркасында казна бушаганга, аны да туктатканнар. Без Волгоград, Люблин трактлары буенча, шәһәр читендәрәк урнашкан 1186 номерлы, Муса Җәлил исемендәге мәктәпне күрергә дип юнәлгән идек тә бит, адым саен «бөке»ләрдә утыра-утыра, мәркәз дигәннәренең менә шундый сәер ниғъмәтләрен дә күреп өлгердек шул... Кызыгырлык, көнләшерлек түгел. Казан каласының 500 кв. км, Петербургның 1500 кв.км мәйдан биләвен инде белә идек, ә Мәскәү менә 2500 кв. км га җәелеп яткан икән. Иллә мәгәр Питерда 5,5 млн чамасы кеше гомер итсә, Мәскәү инде әллә кайчан 18 млн чиген дә узып китте, ахры. Мәскәү кешеләренең яртысы гомере бөкеләрдә үтә, дигән сүзләре дә чын хакыйкать бугай...

«Мәскәү» сүзе – урысныкы түгел. Чуашларда ул «сыер яткан урын» дигәнгә тиң. Безнекечә әйтсәк, «утлау, җәйләү урыны» дигән мәгънәне аңлата. Ә чуашлар элек Болгар ханлыгы эчендә гомер иткән. Риваять буенча, Болгарның кайсыдыр бер сәүдәгәре җинаять кылган да, үлем җәзасыннан шүрләп, шушы якларга, яртылаш сазлыклар арасыннан сузылган Мәскәү белән Явыз елга кушылган урында, биек тау өстенә килеп төпләнгән. Ул читтән килгән кеше булганга, тирә-як халкы аңа «Күчкәй» (күчеп килгән) атын биргән, әмма үзара Степан Иваныч, дип йөртә башлаганнар. Суздаль кенәзе Юрий Долгорукий 1145 елларда үз җирләренә борын суза башлаган Смоленск кенәзе Изяславка һәм Рязань кенәзе Ростиславка каршы сугышлар алып барган, бүләкләр бирә-бирә Ростиславның туганнан туганы Святославны да үз ягына аударган. Шушы сугышлар вакытында Долгорукий Күчкәй бистәсенә дә чапкын юллаган һәм аннан һичьюгы йөз кешелек дружина бирүен таләп иткән. Күчкәй тыңламаган. Смоленск белән Рязань кенәзләренә каршы яуларның берсендә җиңү яулаганнан соң, Долгорукий үз ягына ауган Святославны да чакырып, Күчкәй бистәсендә мәҗлес уздырырга карар кылган. Берочтан, килеп җитүгә үк, үзенә дружина бирмәгән Күчкәй-сәүдәгәрне каен ботагына асып куйган. Долгорукийның улы Андрейга (булачак Боголюбский) 34 яшь, хатыны үлеп киткәннән соң һаман ялгыз яши, ә Күчкәйнең бик тә чибәр кызы калган икән. Долгорукий менә шушы Байгөл атлы кызны бирергә көчләп диярлек Андрей белән өйләндереп тә куйган. Тарих белән аз-маз кызыксынган кешеләргә дә мәгълүм: Андрей Боголюбский 1164 һәм 1172 елларда ике мәртәбә Болгар өстенә, Байгөл ватанына яу белән барган һәм аларның беренчесендә – Изяслав, икенчесендә Мстислав атлы улларын югалтып кайткан өчен, хатыны Байгөл-Василиса, аның энесе Хәким-Яким һәм берничә урыс бояры Андрейга каршы заговор оештыра һәм 1174 елда аның гомерен кыя. Соңыннан заговор ачылгач, Байгөл белән аның кечкенә улын агач мичкә эченә томалап, якындагы күл өстенә ыргыталар, әлеге риваятьләргә нигезләнеп, бөек Пушкин берничә әкият тә тудыра... Менә шундый сәер ул Мәскәү каласының ерак тарихлары...

● Без директор Роза Шакирова белән Җәлил мәктәбендә.

(Дәвамы 12 нче биттә).

МҖ Җидегән
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

# Тәкъдирдә язылган язмыш

Һәр халыкның язмышында хәлиткеч минутлар була. Меңнәрчә еллык яшәү дәверендә андый мизгелләр, әлбәттә, татар тарихында да аз түгел. Урталык җирләрендә дөнья тоту үз язмышында тәкъдирдән үк килә торган кавем буларак, Җәнабе Хак аны дан-шөһрәт белән дә, кайгы-хәсрәт аша да бик күп сынаган һәм, сәламәт рухын (югары милли аң, илаһи рух) вә җанын (тел, моң, мәдәният, гореф-гадәтләр) саклап, бүгенге көнгә кадәр китереп җиткезгән. Ә алда төп сынау тора. Кемнәргәдер ияреп һәм алар үзләренә кулай яңа тәртип урнаштыру ниятендә махсус корган геосәяси вәзгыятьтән чыгып кына эш итсәк, бу инде татар өчен үзенә йөкләнелгән илаһи миссиядән тайпылуны, аның дөнья тотучылар кулында гадәти бер «сәясәт коралы» булып калуын аңлатыр иде. Шуңа безнең өчен метасәяси дилемма бүген конкрет куела: иблис уенына бирелеп, үзеңне һәм башка халыкларны фаҗигагә этәрәсеңме, әллә, үзенә йөкләнгән илаһи миссияне үтәп, рухи яңарыш кичерүдә һәм илаһият кануннары буенча яши башлауда башкалар өчен үрнәк вә әйдәп баручы көч булуны максат итәсеңме. Әйе, бу – гаять зур җаваплылык һәм ул андый кавемнән, үзенең тарихи миссиясен аңлап һәм рәсүли аң югарылыгына күтәрелеп гамәл кылуны (нәбилек вазыйфасына керешүне) таләп итә. Ә инде андый юлны сайлаган кавем Аллаһның Җирдәге изге ниятләрен гамәлгә ашыруга хезмәт итә һәм һәрчак Аның яклавында кала, димәк, үзенең киләчәгенә дә ышанычлы итә.

Метасәяси дилемма исә «ияру-ияртү» проблемасын да бүген калку куя. Хәер, ул хакта элгәрләребез дә җитди уйланган. Бу җәһәттән Дәрдемәнднең: «Җитәкләргә тырыш дөньяи дунәнне (дөнья дигән атны), // Икенең бересе: йә сине җитәкләр. // Алып барыр үзеңне бер чокырга, // Барырсың - бардырыр, төртәр, этәкләр», – дигән юлларын искә төшерү дә җитә. Ә бит әле аның дәвамы да бар. Әлбәттә, әйдәп баруга дәгъва кылган милләтнең башкаларны да җәлеп итәрдәй идеясе булуы да лязем. Аллага шөкер, татарда ул бар һәм хәтта тәкъдири миссия дәрәҗәсендә дә куелган. Боларның һәммәсен дә барлагач, алгы планга янә бер мөһим мәсьәлә чыга: ә бармы соң бүген татарда андый эпохаль үзгәрешләргә әзерлек? Җавап исә монда да уңай. Һәрхәлдә, Урталык җирләрендә ул бүгенге көндә рухи, әхлакый, хокукый, тарихи һәм метасәяси яктан иң әзерлекле милләтнең берсе булып тора. Илаһи факторлар тәэсирендәге әзерлеге исә аның, күп гасырлык сынауларны уңышлы узуы белән бергә, бөтен дөньяга таралып яшәвендә һәм асыл сыйфатларын әле бүгенгәчә саклап калуында да күренә. Россия төбәкләрендә татар авылларының (Урта Әләзән, Шыгырдан, Гали һ.б.) әле бүген дә булганлык вә муллык утравы булып яшәве шул хакта сөйли. Мәгәр, җитешсезлекләр дә күп: милли аң вә метасәяси үзоешуның түбән калуы; илаһи исламның тәүхиди-иҗтиһади асылын аңлау һәм аңлатудагы сүлпәнлек; туган тел вә милли мәгариф проблемалары; милләтнең икътисади вә финанс нигезе ныклы булмавы; метасәяси проектларга ихтыяҗ һ.б. Шуңа күрә татарның милли, дини вә иҗтимагый үзәкләрендә эшне шул юнәлешләрдә яңарту мәслихәт.

Мондый куелыш бүген үзен шанлы ата-бабаларының варисы итеп тойган һәм алар рухына тугры калган һәр татар кешесенә кагыла. Шуңа ул үзе өчен бүгенге кыен хәлләрдән чыгуның бердәнбер хак юлы рухи яңарыш һәм илаһият кануннары буенча (киң мәгънәдә) яши башлау икәнлеген акыл югарылыгында аңларга һәм үз язмышы өчен (димәк, милләт язмышы өчен дә) җаваплылыкны үз өстенә алырга тиеш була. Гади телгә күчереп әйтсәк, бу инде әлеге юнәлешләрдәге конкрет эшчәнлекне иң элек үзеңнән һәм гаиләңнән башларга һәм җаваплылыкны да үз өстеңә алу кирәклеген аңлата. Чөнки синең өчен моны башка беркем дә эшләмәячәк. Мәсьәләнең рухи ягын илаһи исламның тәүхиди-иҗтиһади асылын ислам метафизикасы югарылыгында аңлау һәм башкаларга да аңлату тәшкил итсә, гамәли ягы инде яшәү рәвешеңне илаһият кануннарына туры китереп үзгәртә алуда күренә. Ә төп максат – изге эшләрдә башкаларга (аларның диненә, милләтенә, социаль хәленә карамастан) үрнәк һәм алга әйдәүче буларак, милли, дини вә социаль хокук тигезлегенә корылган гадел ватандашлар җәмгыятеңә коруга хезмәт итү. Ул чакта инде гаиләңдәге җитешсезлекләр өчен кемнедер гаепләргә урын да калмаячак.

Әлбәттә, әлеге эшләрдә татар өчен иң катлаулысы милли үзоешу мәсьәләсе булачак. Бүген аны 3 баскычлы итеп – территориаль, экстерриториаль һәм метасәяси принципларда кору мәслихәт. Беренчесе Идел-Урал төбәгендәге татарларның андагы дәүләтчелек төрләре кысаларында үзоешуын максат итсә, икенчесе Урталык җирләрендәге милләттәшләребезнең милли-мәдәни автономияләр аша үзоешуын күздә тота. Ә татарның метасәяси үзоешуы инде милләттәшләребезне дөньякүләм дәрәҗәдә дә берләштерүне максат итә (соңгысы хакында газетабызда инде сүз булды, «МҖ»№31, 12.08 2022).

**Фоат УРАЗАЙ.**

# «Татар уллары» атналыгы

15 февральдә патриот шагыйрь, Советлар Союзы Герое, Ленин ордены иясе Муса Җәлил һәм татар моңын дөньяга танытуга, милләтебезне берләштерүгә гомерен багышлаган легендар җырчыбыз Илһам Шакиров дөньяга килгән.

Шушы уңайдан Бөтендөнья татар конгрессы һәм милләтебезнең затлы, зыялы шәхесләре дөньяга сибелеп яшәгән халкыбызга быелның 15 февраленнән Муса Җәлил һәм Илһам Шакировка багышланган мәдәният атналыгы марафонын игълан итте.

Атналыкның идея авторы – «Җиһангирлар» инициатив төркеме җитәкчесе Хәлил Гайнетдинов һәм проект җитәкчесе – Муса Җәлил исемендәге премия лауреаты, Татарстанның халык артисты, Кырым Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Гөлзадә Сафиуллина.

Бөтендөнья татар конгрессы атналык барган көннәрдә төрки-татар халкы яшәгән төбәкләрдәге мәдәният сарайларында, уку йортларында, җәмәгать оешмаларында, җыр, бию һәм фольклор ансамбльләрендә, китапханәләрдә, гаиләләрдә шушы бөек шәхесләребезнең шигырьләрен, җырларын яңгыратырга, балаларга һәм яшьләргә патриот шагыйрь һәм мәшһүр җырчыбызның тормыш юллары турында сөйләргә, аларга бәйле истәлекләр белән уртаклашырга, мәчетләрдә рухларына багышлап дога кылырга чакыра.

«Муса Җәлил һәм Илһам Шакиров иҗатын, аларның матур киләчәгебез хакына башкарган эшләрен балаларыбызга, яшьләребезгә сеңдереп калдыру ниятеннән кылган гамәлләребез хәтерләребезне яңартсын, күңелләребездә батыр, мәшһүр улларыбыз белән горурлану хисләрен уятсын. Халкыбызның борынгы һәм бөек тарихлы булуын, көчле дәүләтләрнең дәвамчылары, мирасчылары булуын искәртсен, үзаңыбызны арттырсын, безгә көч-куәт бирсен, төрки-татар дөньясын тагын да берләштерсен, бер йодрыкка тупласын. Башкарылган әлеге әсәрләр Муса Җәлил һәм Илһам Шакиров рухларына дога булып ирешсен иде», – ди Гөлзадә Сафиуллина.

Бөтендөнья татар конгрессы атналык марафонга катнашучыларны М.Җәлил шигырьләрен укып яки яттан сөйләгән, Илһам Шакиров репертуарындагы җырларны башкарган, мәшһүр талантларыбыз турында истәлекләр белән уртаклашкан видеоязмаларын, #татаруллары2023 дигән хештег куеп, үзләренең «Вконтакте» социаль челтәрендәге шәхси сәхифәләренә урнаштырырга чакыра.

**Сөембикә КАШАПОВА.**

# Институтка тиң эшчәнлек

Түбән Новгород өлкәсе Сафаҗәй авылында Хөсәен Фәезхановның тууына 200 еллыкка багышланган «Фәезханов укулары» узды. Анда күренекле дин әһелләре, галимнәр, җәмәгать эшлеклеләре катнашты.

Россия мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Равил хәзрәт Гайнетдин үз чыгышында мәгърифәтче Х.Фәезхановның фәнгә керткән өлешен тулы институт эшчәнлегенә тиңләде. «Танылган профессорлар да төбенә төшеп җитә алмаган борынгы кулъязмаларны укый, күчерә яза, тәрҗемә кыла. Болгар чоры, Касыйм һәм Кырым ханлыклары тарихына кагылышлы чыганакларны өйрәнүгә керткән өлеше – тулы бер фәнни институт эшчәнлеге белән чагыштырырлык. Кызганыч, хәзерге кебек бөтен шартлар һәм техник мөмкинлекләр тудырылган дөньяда да гыйлемлелек өлкәсендә Х.Фәезханов дәрәҗәсенә җитүчеләр бик аз. Кырымда Исмәгыйль Гаспралы беренче җәдиди мәдрәсәне ачудан башлап җәдидчелек үсә башлый. Ә бу фикри агымның асылын, максатын алдан күрүче, өммәт алдында күтәреп чыгучы Х.Фәезханов була», – диде Равил хәзрәт.

Аның беренче урынбасары Дамир Мөхетдинов Х. Фәезхановның идеяләрен Шиһабетдин Мәрҗани тормышка ашырганын әйтте: «Хөсәен Фәезханов XIX гасырда татарлар, Россия мөселманнары системалы кризис кичерүен таныган һәм ул үзенең гомерен шул кризистан чыгуга багышлаган. Ш.Мәрҗани Х. Фәезханов идеяләренә таянып, мәдрәсә реформасын тормышка ашыра, татар укытучылары мәктәбенә нигез сала».

Аның фикерен тарих фәннәре докторы Дамир Исхаков куәтләде. Ул Х.Фәезхановның тарихчы да булуы турында диссертация язарга кирәклеген белдерде.

Түбән Новгород өлкәсе мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Гаяз хәзрәт Закиров мәгърифәтченең Россия мөселманнарын берләштерү моделен тәкъдим иткәнлеген искә алды. Гаяз хәзрәт сүзләренчә, Исмәгыйль Гаспралы Х.Фәезханов төзегән мәгариф реформасы планнары турында беренчеләрдән булып язып чыга. Х.Фәезханов урталыкны саклау һәм сабырлык принципларын алга сөрә, көнбатыш цивилизациясенең техник казанышларын, фәнни методикасын кулланырга өнди. Шул ук вакытта белемне туган телдә бирүне кертергә омтыла. 1850 нче елларда мәдрәсәләрдә дәресләр гарәп-фарсы телләрендә укытыла, дөньяви фәннәр бөтенләй керми. «Гасыр ярым элек Х.Фәезханов «Рисалә» һәм «Ислах мәдәрис» хезмәтләрендә өммәтебезнең мәгариф реформасы концепциясен төзи. Галимнең хезмәтләре безнең заманда гына тулысынча билгеле булуына карамастан, алар XIX гасыр азагында татар мәгърифәтчеләренә, җәдидчеләренә мәгариф реформасын тормышка ашырырга зур йогынты ясаган. Ул башкалада фәнни җәмгатьчелек белән диалог булдырырга ирешә», – диде Гаяз хәзрәт.

**Рифат КАЮМОВ.**

**1 нче биттә** – Мәскәүдә Муса Җәлил һәйкәле. В. Имамов фотосы.

# Генерал үз өенә «кайтты»

**Казанда Советлар Союзы Герое, генерал-лейтенант Гани Беккин улы Сафиуллинга мемориаль такта ачылды. Тантанада Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашты.**

Мемориаль такта каһарман, 38 нче укчылар дивизиясе һәм 25 нче гвардия укчылар корпусы командиры (7 нче гвардия армиясе), генерал-лейтенант Гани Сафиуллин (1905-1973) яшәгән Адамюк урамы, 4 йорт фасадында куелды. Бу вакыйга Сталинград сугышында совет гаскәрләренең немец-фашист гаскәрләрен җиңүенә 80 ел тулуга багышланды.

«Бөек Ватан сугышында катнашучыларның кыюлыгы һәм батырлыгы республика халкының хәтерендә һәм йөрәкләрендә мәңгегә калачак, алар үсеп килүче татарстанлылар өчен үрнәк булып тора», – диде үз чыгышында Р.Миңнеханов. Ул Арча районының Иске Кишет авылындагы гади йортта Советлар Союзы Герое, генерал-лейтенант Гани Сафиуллинга багышланган музей комплексы ачылуын искә алды. Казандагы һәм Арча районындагы урамнар аның исеме белән аталган. Түбән Камада Идел буе федераль округының Татарстан кадетлар корпусы Гани Сафиуллин исемен йөртә.

Бөек Ватан сугышы фронтларында Гани Сафиуллин үзен тәҗрибәле командир итеп таныта. 38 укчылар дивизиясе белән командалык итеп, ул иң канкойгыч сугышларның берсендә – Сталинград янында немец гаскәрләрен тар-мар итүдә катнаша. 1943 елда шәхси батырлыгы һәм кыюлыгы өчен Гани Сафиуллинга Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

Тантанада катнашучылар яуларда һәлак булган сугышчыларны бер минут тынлык белән искә алды.

# Көй-моңга укыту мәсьәләләре

Н.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе Фәрит Яруллин исемендәге Әлмәт музыка көллияте белән берлектә музыкаль белем бирү, традицион музыка уен коралларын өйрәнү проблемаларына багышланган күчмә утырыш уздырды.

Көллиятнең концертлар залында узган төп утырышта муниципаль мәдәният бүлекләре җитәкчеләре, балалар музыка мәктәпләре директорлары һ.б. катнашты.

Утырыш Казан дәүләт консерваториясе ректоры Вадим Дулат-Алеевның Казан дәүләт консерваториясендә музыкаль белем бирү системасына кагылышлы доклады белән башланды. Ректор музыкаль белем бирү оешмаларының эш бирүчеләр – концерт оешмалары һәм төрле мәдәният учреждениеләре белән тыгыз элемтәдә булуына басым ясады.

Консерваториянең татар музыкасы кафедрасы мөдире Рөстәм Рәхмәтуллин вузда оешкан традицион уен коралларын ансамбле һәм аның «Яшьләр өчен Россиянең музыкаль традицияләре» гранты кысаларында эшчәнлеге турында сөйләде, бу юнәлештәге җитди проблемаларны да искә алды.

Түбән Кама районы мәдәният идарәсе башлыгы Гүзәл Мөбәрәкшина кадрлар кытлыгы мәсьәләсен күтәреп чыкты. Консерваториядә максатчан укытуны ул чишелеш юлларының берсе дип саный.

Утырыш кысаларында традицион музыка уен коралларын өйрәнү темасына кагылган түгәрәк өстәл дә узды.

**Рузилә МӨХӘММӘТОВА.**

# Асылташ басма

Бөтендөнья Татар конгрессы бинасында музыка белгече, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Филүсә ханым Арсланның «Моң эчендә асылташ…» дип аталган җыентыгын тәкъдим итү чарасы узды. Әлеге чарага шәһәребезнең күренекле музыка белгечләре, җырчылар, авторның педагог коллегалары һәм язмаларының кайбер геройлары да җыелган иде. Ике сәгатьтән артык барган кичә милли музыка сәнгатебезнең бүгенге хәле, аның җанны авырттырган проблемалары хакындагы сөйләшүгә әверелде.

Филүсә Арслан – озак еллар мәдәният институтында студентларга белем биргән тәҗрибәле мөгаллим, музыка сәнгатебез турында аның бөтен нечкәлекләрен белеп татарча җентекләп яза белүче сәнгать белгече, йөзләгән мәкаләләр авторы да. Әлеге саллы җыентыкка аның төрле елларда язылган, татар музыка дөньясындагы шәхесләребезнең тормыш-иҗатларын яктырткан мәкаләләре, рецензияләре, интервью һәм очерклары тупланган. Әллә нихәтле җырчылар, музыкантлар турында монда җентекләп мәгълүмат бирелгән.

Музыка белгече, китапка кереш сүз язган Гөлназ Гыйльми фикеренчә, музыка турында сөйләве дә, язуы да җиңел түгел, чөнки музыканы сүзләргә күчереп тасвирлау осталыгы кирәк. «Ә менә Филүсә апа болар хакында туган телебездә җиренә җиткереп яза белә. Тәнкыйть фикерләрен дә ул озак уйланып, анализ ясап кына җиткерә», – диде ул.

Фәнзилә ханым Җәүһәрова исә җыентыкны «Татар музыка тарихының бер ельязмасы» дип атады. Чыннан да, күпме генә мактанырга яратсак та, татар музыкасы тарихы турында хезмәтләр бик аз. Шул яссылыкта 100 елдан артык чор эчендәге милли музыкабыз дөньясындагы шәхесләрне колачлаган бу җыентыкның басылып чыгуы – шатланырлык вакыйга. Фольклор белгече, галим Илгиз әфәнде Кадыйров җыентыкны милли музыкабызның кече энциклопедиясе булып саналырга лаек, диде. Китапның фәннилек ягыннан, төгәллек, даталар ягыннан искиткеч югарылыкта эшләнүенә басым ясады.

Тәкъдим итү кичәсенә килүчеләр тарафыннан бу саллы җыентык һәр китапханәдә, һәр читтәге татар оешмасында булырга тиеш, дигән фикер берничә тапкыр яңгырады. Тик кызганыч, музыка тарихыбыз турында әтрафлы итеп язылган шушы кирәкле китап бик аз тираж белән – нибары 300 данә басылып чыккан. Аны автор үз хисабына һәм игелекле дусларының ярдәме белән хосусый нәшрияттә чыгарган…

Китап кичәсенең ахырында Татар конгрессы рәисе урынбасары Марс Тукаев Филүсә ханымны котлап, аңа нәфис ак шәл бүләк итте. Коллегалары, кунаклары исә беравыздан мондый бәрәкәтле иҗат җимешләре соңгысы булмасын, дип теләде.

**Эльмира СИРАҖИ.**

# Намазга басыйм дисәң

Диния нәзарәте намаз укырга һәм динебез нигезләренә өйрәтүче «Ислам. Беренче адымнар» курсының чираттагысына тыңлаучылар җыя башлады. Беренче дәрес 25 февраль көненә билгеләнгән. Соңгы дәрес – 8 апрельдә, шул көнне әлеге курска ифтар мәҗлесе белән йомгак ясау, сертификатлар тапшыру тантанасы үткәрү көтелә.

Курс дәвамында укучылар 7 дәрестә тәһарәт алырга, намаз укырга өйрәнәчәк, гакыйдә, хәләл һәм хәрам төшенчәләре, ураза тәртипләре буенча дәресләр тыңлаячак. Шул рәвешчә, изге рамазан аена намаз укырга өйрәнеп керергә теләүче кардәшләребезгә зур мөмкинлек тудырыла.

Ислам динендә беренче адымнарын ясаучылар һәр атнаны шимбә көнне иртәнге сәгать сигездән көндезге сәгать уникегә кадәр Казанның Галиев мәчетенә җыелачак. Якынлашып килүче Рамазан аен истә тотып, дәресләр тәртибенә бераз үзгәрешләр кертеләчәк: беренче дәрес – тәһарәт-госел тәртипләренә, аннан соңгы ике дәрес – намаз укуга, дүртенче дәрес – уразага багышланачак һәм аннан соң кабаттан намаз уку тәртипләрен, гакыйдә, хәләл һәм хәрам төшенчәләрен өйрәнеп дәвам итәчәк. Әлеге мәктәп ислам дине кушканча яшәргә теләүче, әмма 5 ел дәвамында мәчет каршындагы курсларга йөрергә мөмкинлеге булмаган кешеләр өчен оештырыла. Укулар татар һәм рус телләрендә алып барыла, онлайн консультацияләрне тәүлек дәвамында алырга мөмкин. «Ислам. Беренче адымнар» мәктәбендәге укулар – түләүсез.

Әлеге проект Татарстан мөфтияте тарафыннан 2018 елда тормышка ашырыла башлады. Ун сезон дәвамында мәктәптә 940 ка якын кеше белем алды һәм намазга басты.

**Э. СӘГЫЙДУЛЛА.**

● 2023 елда Татарстанда төзелеш һәм объектларны модернизацияләү тармагында 44 республика программасын гамәлгә кертү планлаштырыла, моңа барлыгы 54 миллиард сум акча бүленгән. Әлеге акчага 3,5 меңнән артык объектны төзү, ремонтлау, яңарту һәм төзекләндерү зарур. Былтыр республиканың төзелеш комплексы үзенә йөкләнгән бөтен бурычны үтәгән: 6 илкүләм, 8 дәүләт, 44 республика программасы тулы күләмендә тормышка ашырылган.

● Быел Татарстанда барлыгы 2 миллион 830 мең квадрат метр торак төзеләчәк: 160 мең кв.м – социаль ипотека программасы буенча, 1 миллион 246 мең кв.м – индивидуаль торак төзелеше линиясе буенча, 1 миллион 423 мең кв.м – күп фатирлы инвестицион торак сегментында. Күп фатирлы йортларны капиталь ремонтлау программасына 716 объект кертелгән, аны финанслауга 6 миллиард 198 миллион сум акча бүленәчәк. "Безнең ишегалды" программасына быел 9 миллиард сум акча тотылачак – барлыгы 960 йорт яны территориясен төзекләндерү планлаштырыла.



# Сәхнәдә – Исхакый әсәре

**Әлмәт театры Камал сәхнәсендә Гаяз Исхакыйның «Ул әле өйләнмәгән иде» әсәрен куйды. Режиссер Айдар Җаббаров искиткеч спектакль куйган, минемчә.**

Кем эчтәлеген белми – өч сүз белән искә төшерим. Авылдан чыккан татар малае Шәмси Петербургта Анна белән йөри. Ул «мин әле авылга кайтам, без әле өйләнмәгән», дип үзен алдап яши. Ә үзе Шәмсидән Шурага өйләнеп, күпсанлы маңкортлар отрядын тулыландырган бер мескен икәнен танымый. Балалары туа, алар ата-ана булып җитлегә. Ә Шәмси «Мин әле өйләнмәгән, кайткач өйләнәм, без Анна белән дуслар гына», – дип йөри. Аннасы әйбәт аның – чирләгәч, башкорт даласына кымыз эчәргә дә алып бара. Катнаш никахлар, кеше психологиясе, авыл мокыты проблемаларын ачып биргән иң яхшы әсәрләрнең берсе.

Айдар Җаббаров аны элекке заманныкы, әмма хәзерге чорга аваздаш итеп куйган. Аның әсәрне төбенә төшкәнче өйрәнүе мактауга лаек. Ул үзе әсәрне Гаяз Исхакый булып куйган кебек. Анда ниндидер аңлаешсыз символлар белән уйнау да юк, алар ярылып ята. Ул символлары үзләренең аяусыз чынбарлыгы белән чытырдап йомарга теләгән күз кабакларын да чытырдатып ача. Шәмси, баласы тугач, бишек тирбәтү эпизодын гына күр: татар малае бишек тирбәтмәкче була, ә ул селкеткән саен чиркәү кыңгыравы кебек чыңлый. Татарның үз газиз баласын үз куллары белән башка халыкка бүләк итүе бит инде бу. Шәмсиләр күп бездә. Алар Исхакый заманнарыннан бирле килә.

Сәхнәгә Исхакый әсәрен укучы булып ике сары чәчле бала – актрисалар Диләрә Фазлыева белән Энҗе Сәйфетдинова чыгып баскач та, тамашачылар гаҗәпләнеп кала, бу нинди хәл? Югыйсә, балалар сәхнәгә чыкканчы ук, спектакль алдыннан тамашачыларны кисәтә торган сүзләрне әйтеп, режиссер көлдереп ала. Юкка түгел, Айдар Җаббаровның спектакльләре уйлата да, көлдерә дә шулай.

Бу спектакльнең җырларына тикле дөрес сайланган, әйтик, Әлфия Авзалова җыры бик урынлы яңгырый. Аннары, биюләр. Мин «Санаулы кичләр»дә ялгыз хатын – Люция Хәмитова биюен күреп бер шаккаткан идем, ул ялгыз хатынның кичерешләрен гаять оста бирә. Ә бусында «Анна биюе». Яраткан кешесе ташлап киткәч, дөресрәге «яратып китеп барам» дип югалгач, бии ул аны. Назга сусаган, эчендә җеннәре котырса да, үзен кулда тотарга теләгән бичара Анна биюе. Кеше психологиясен үтә төгәл ача...

Спектакльдә балаларның кыланмышларын күреп тә рәхәтләнеп көләсең. Теге ике сары чәчле бала да спектакльдәге күренешләрне өлкән тамашачыларга кушылып карый һәм әле башкалар уйнаганда жестлар, мимикалар белән котыртып та утыра. Аннары азакка таба ике баланың кем икәне ачыла. Бу ике сары чәчле кыз кара башлы Шәмсинең балалары икән бит! Менә шундый символик күренеш.

Уйнаучылар нибары сигез, әмма аларның һәрберсе әллә ничә роль башкара. Нәфис Газиев башкорт булып та, исерек булып та, Аннага гашыйк егет булып та уйный. Аның Аннага гашыйклыгын сурәтләгән биюен карау өчен генә дә бу спектакльгә килергә кирәк. Егет талантлы, аны труппага алып, йөзләтә уңган театр!

Айдар Җаббаров актерларны оста сайлый белә. Айрат Мифтахов – колаклары тырпаеп торган чын Шәмсидер сыман. Анда – кызгану хисе тудыра торган мескенлек. Менә ул – үзе псих, үзе тупас, үзе надан, әмма күңеле нечкә булган шикчел, куркак, ихтыярсыз татар. Үзе акыллы да, эшен башкара бит. Петербургка килеп, кибеттә эшли ала – эше бара, димәк...

Ә Миләүшә Хафизова – чыпчын Анна. Уйнаганда әсәр искә төшә, уйлап утырасың – шушындый булырга тиеш бит инде ул! Нишләсен – ярата ул Шәмсине. Начар хатын түгел.Тырыш, эшли, итагатьле, белемле, әллә ничә һөнәр белә, Шәмсине тәрбияли, хәтта аңа хатын сайлашырга әзер! Нәфис Газиев биегәндә, йөрәге ярсыса да, аңа да ияреп китми! Шул тупас, төртке Шәмсие белән һаман. Аның җырларын да кабул итәргә тырыша, тик ярата алмый. Күңел башка! Петербургта үскән Анна авыл мулласы малае Шәмси яраткан Әлфия Авзалованы ничек яратсын, ди! Шуңа Шәмси җырларын яратырга тырышкан чагында аның йөзләре сытыла. Ә Шәмси менә Горькийны да ярата ала, Чеховны да. Анна матур булгач, нишлисең? Аннасын яраткач, Чеховын да яратасың инде...

Калган актерлар да, әллә ничә роль башкаруга карамастан, һәр рольдә үзләренчә ачыла. Башкорт булалар – ысын башкорттар дип карап утырасың, аннары алар фин була, бераздан – исерекләр, аннары Питердагы татарлар... Менә шулай төрләндереп уйнавы үзе үк бер кызык.

Анна белән Шәмсинең танышулары, кавышулары карап утыру да мәзәк. Шәмсинең үзенә каршы килә-килә Аннаның кочагына керүе үтә дә кызык сурәтләнә: Анна сәхнәдән шуып, Шәмси янында пәйда була.

Кыска гына вакыт эчендә аларның тормышы тамашачы күз алдында үтә. Һәм менә Анна бала таба. Бала табу күренеше матур уйланылган – кендек бавы да бар анда, ананың газаплары да, баланың тууы да!..

Аннары Шәмси өчен кара көннәр килә. Балалары анык булса да, татар түгелләр бит! Ә ул – мулла малае... Сорауларына җавап эзләп ул муллага да бара. Бу спектакльдәге мулла вәгазе – иң шәп вәгазь. Җиде минут эчендә ул бөтен нәрсәне урыныны утыртып чыга. Өстәвенә, хәзерге сленгта сөйли. Әгәр Актер Динар Хөснетдинов мәчеттә вәгазь укыса, халык өзелмәс иде. Барысын да исламча итеп урынына куя: «Мәхәббәт никахтан соң! Ә син – мөселман, барысы да синең кулда!» Шул ук Динар бераздан поп булып та чыга. Нәкъ атакай сүзләре инде: «Главное же любовь!»

Монда әле башкортлар да бар бит. Анна Шәмсине башкорт даласына алып бара. Бик тәкәббер, юмарт башкорт агае мескен кыяфәтле, урталай бөкрәйгән Шәмсине башкорт даласында күргәч, башкорт хатыны (Римма Заһидуллина) һәм башкорт ире (Фаил Сафиуллин) җырлап җибәргәч, аһ, дип куясың. А.Җаббаров монда кайчандыр Зөлфәт Хәким «моңлы мескенлек» дип атаган күренешне сурәтли. Без «моң» сүзебез тәрҗемә ителми дип горурланабыз бит, әмма үзебезне мескен тотабыздыр...

Сәхнә – авыш. Сәхнә өстендә көзге. Карап утырырга да кызык – чагылышны күрәсең. Символик та – бу бит чын тормыш түгел. Шәмси авыш җирдә йөри, чагылыш та – бу дөньяның чын булмавы, вакытлы икәне күрсәткече...

Спектакльнең азагы Исхакыйча түгел. Шәмси балаларына да Әлфия Авзалованы тыңлата алмагач, барысын да ташлап, авылга кайтып китә. Айдар Җаббаров шәһәрнеке булса да, авыл пычрагын җитәрлек күргән, ахры. Ул авыл пычрагында йөрүне нык шәп тасвирлаган. Тамашачы авыл пычрагы пычырдауның тавышына кадәр ишеткәндәй булды... Сәхнә турая, көзге юкка чыга – Шәмси сәхнә артындагы караңгылык уртасындагы яктылыкка китеп югала. Нәрсә ул яктылык – тәмугмы, татарның алгарышымы – кем белсен. Анысын инде тамашачы үзе уйлап табар.

Катнаш никахлар темасын фаҗига итеп күрсәткән әсәрләр бик күп булды. Ә минем җанга үткәрерлек итеп, сарказм белән, бөтен процессын сурәтләп бирелгәнен күргәнем юк иде. Бик яхшы спектакль. Бу – Гаяз Исхакый. Бу – Айдар Җаббаров.

**Рәмис ЛАТЫЙПОВ.**

## Төркия татары турында фәнни хезмәт

Истанбулдагы Мәрмәрә университетында Төркия татарларының танылган табибы, «Сөембикә» татар җәмгыятен оештыручы, шагыйрь Ләбиб Каранның эшчәнлеге турында диссертация якланды.

Фәнни хезмәт «Татар зыялыларыннан Ләбиб Каран (1887-1964): тормышы, эшчәнлеге һәм фикерләре» дип атала. Аны Мәрмәрә университеты Төрки дөнья тикшеренүләре институты тарих бүлеге аспиранты Җан Караманоглу язган. Фәнни җитәкчесе – әлеге уку йортының гомуми төрек тарихы кафедрасы җитәкчесе Әхмәт Канлыдәрә.

Җан Караманоглу Л.Каранның бөтен гомерен, тырышлыгын татарлыкны яклауга һәм саклауга багышлаган зыялы шәхес итеп күрсәткән. Аның татарларны «мөселман», «монгол», «төрек» дип атауларына каршы чыгуын, Шиһабетдин Мәрҗани фикерләренә өстенлек бирүен, «Татар төркиләре» дигән сүзтезмәне кулланучы шәхесләрне тәнкыйть итүен фәнни кысаларда яктырткан.

Төрек галиме Ләбиб Каранның 77 еллык гомер юлын тикшергән, бүгенгәчә билгеле булмаган мәгълүматларга ирешеп, аның биографиясен тулыландырган. Ул Ләбиб Каранның Хөсәения, Мөхәммәдия мәдрәсәләрендә укуын, белем алуын Петербургта дәвам итүен, гарәп, фарсы, рус, төрек телләрен яхшы белүен ассызыклаган. Төркиядә тире авырулары табибы булып танылуын, кайларда эшләвен язган.

Фәнни хезмәттә Ләбиб Каранның җәмәгать эшлеклесе буларак эшчәнлеге тикшерелгән, Төркиядәге «Төрек йорты» һәм Берлинда Гаяз Исхакый чыгарган «Яңа милли юл» вакытлы матбугатларына язган милли эчтәлекле мәкаләләре анализланган. Ләбиб Каран үзе язып нәшер иткән «Татарларның төп чыгышы», «Шиһабетдин Мәрҗани: тормышы һәм әсәрләре», «Казан һәм икътисади төбәкләр», «Илсөючелек һәм үзеңне фида итүчелек», «Сөембикә ханбикә һәм аның тормышы» кебек уннан артык китабына фәнни бәяләмә бирелгән.

Милләттәшебезнең «Яшь вакытымның җырлары», «Төшенчәмнең җырлары», «Сөмсеремнең җырлары» кебек шигырь җыентыклары да фәнни хезмәтнең бер өлешен тәшкил итә. Галим Ләбиб Каранның гарәп имлясы белән язган әсәрләрен латиницага күчергән.

● Чиләбе өлкәсе Бәгәрәктамак гомуми белем бирү мәктәбенә баян бүләк итү вакыты. Баянны мәктәп директоры Фидалия Кәримова кабул итеп ала.

● Расих Сабирҗанов (уңда) танылган баянчы Ринат Вәлиев белән.

# Гармунның да җаны бар

*Казанның үзәгендәрәк урнашкан «Аксу» студиясенә, сирәк булса да, кагылып чыгарга туры килә. Ә бер килүемдә ишегә ачык торган бүлмәнең киштәләренә күзем төште. Алар музыка уен коралары белән тулы! Ниндиләре генә юк – гармун, баян, аккордеоннар...*

Чехословакиядә эшләнгәне дә, Бөек Ватан сугышыннан алып кайтылганы да, революциягә кадәр ясалганы, Вараксин гармуннары, ягъни тальяннар да бар. Хәтта мандолина, скрипкаларны да күрергә мөмкин. Бүлмә берара гармуннар музеен хәтерләтеп куйды. Хуҗасы – гармуннарга икенче тормыш бирүче алтын куллы оста Расих Сабирҗанов икән. Ә ул музыкант та, җырчы да түгел. Аңа бу һәвәслек, осталык каян килгән?

Расих әфәнденең уен коралларын төзәтә башлау тарихы үсмер чагындагы «Чайка» гармунына барып тоташа. Чүпрәле районының Зур Чынлы авылы урамнарын яңгыратып баянда уйнаучы Харис ага улы Расихка 14 яше тулгач «Чайка» гармунын алып кайтып бирә. Ул үсмер улының да, үзе кебек оста итеп уйнарга өйрәнүен теләгәндер. Әмма Расихның күңеле көйләр чыгаруга бик тартылмый, үсмер бер-ике көй өйрәнә дә гармунны читкәрәк этеп тора. Егетне күбрәк физика кызыксындыра, авыл хуҗалыгы институтын да уңышлы тәмамлый.

Әмма гармун барыбер тик тормый, уйнала. Еллар узгач, ир-егет аны азрак төзәтеп алырга кирәклеген аңлый. Расих «Чайка»ны сүтеп карый, өйрәнә, төшенә һәм төзәтеп тә чыга. Аннары бу эш аны чын-чынлап кызыксындыра башлый. Ул музыка уен коралларының нинди материалдан эшләнүен, механикасын, физик характеристикаларын, һәр деталь-элементларының сыйфатын өйрәнә. Телләр төзелеше, металл, яңгыраш сере... Моннан тыш ноталарны да белү сорала. Октавалар тәртибе, һәрберсенең тональлеген билгеләү үзенчәлеге бар. Әкренләп Расих гармуннар төзәтү буенча чын остага әверелә. Физика яраткан егеткә болар барысы да җиңел бирелә.

Р.Сабирҗанов башта таныш-белешләренең тузан җыеп яткан тальянка-хромкаларын төзәткәләп бирсә, соңрак көе киткән баян кебек катлаулыракларын да кулы аша үткәрә. Тора-бара Р.Сабирҗанов аккордеоннарның да серенә төшенә, гитара, балалайка, мандолина кебекләре дә ир-егет кулына эләккәч ипкә килә. Аннары мәктәпләрдә музыка укытучылары, ансамбльләр оештырып, балаларны сәнгатькә тарта. Уку йортларында ватылып яткан музыка уен кораллары да хәтсез. Гармуны, баяны, яисә аккордеоны... Алар да Расих ярдәмендә яңача яңгыраш ала. Әлбәттә, гармуннар төзәтү остасына заказлар да күп, мөрәҗәгать итүчеләр дә хәтсез. Хәтта Мәскәүдән дә биш заказ килгән. Ул аларны төзәтеп, чистартып, өр-яңа рәвешкә китереп, хуҗаларына кайтара.

Дус-ишләре янына кергәч гармуннарының көе китүен, уйналмыйча ятуын күреп, Расих аларны да төзәтеп бирә. Әкренләп үзенең гармуннар коллекциясе дә туплана. Аңа кызыгучылар да хәтсез. «Уйнап карыйм әле», – диләр. Алып сыздырып җибәрәләр, кулларыннан да төшерәселәре килми. Расих Харис улы коллекциясендәге гармуннарын шулай музыкага мөкиббән киткән дусларына бүләк тә итә. Рәхмәт әйтеп алалар. «Музыка уен кораллары хәрәкәттә булырга тиеш. Аларның тавышын яңартып, яңгыратып тору сорала», – ди ул бу уңайдан.

Гармуннар төзәтү остасы соңгы елларда балаларның, яшьләрнең, компьютерга алданып, музыка уен коралларыннан читләшүенә дә борчыла. Ул үзенең үсмерлек чорларын искә төшерә, балаларның бер-берсеннән күреп гармунда уйнарга өйрәнүен, кичләрен гармун моңнарына күмелеп яшәүләрен матур хәтирә итеп искә ала.

«Минем яшьтәшләрем дә шулай уйнарга өйрәнде. Көйләрне кемнең ничек яңгыратуын бүген дә хәтерлим. Шуларның барысын да искә төшерәм дә гармунга тартылганнарга, талантың бар икән, уйна, дип бүләк иткән чакларым күп», – ди ул.

Бүләк мәсьәләсендә Расих Сабирҗановның игелекле булуын күптән беләләр. Әлфия Авзалова үзәген бизәп торган биш гармун (арада 1910 елда эшләнгән гармун да бар), баянның барысы да – музыка уен кораллары белгече Р.Сабирҗанов бүләге. Яраткан җырчыбыз үз заманында нинди гармуннарга кушылып җырлаган, шуларны коллекциясеннән сайлап, үзәккә тапшырган. Казанның 23 нче гимназиясе, М.Җәлил исемендәге татар гимназиясенә бүләк ителгән аккордеон балаларның сәләтен ачуда озак еллар булышачак әле. Кооперация институтындагы Дәрдемәнд исемендәге татар мәдәнияте үзәге дә Р.Сабирҗанов юмартлыгы аша баянлы булган. Чиләбе өлкәсенең Коншак районында да Расих яңадан җан өргән өч баян бар. Коншак авылы егете җырчы Ирек Галиев, «Аксу» студиясенә кергәч, кызыгып уйный, үзенә баян алырга кирәклеген әйтә. Әмма кибетләрдә баяннар – кыйммәт, егетнең хәзерге вакытта акчасы да җитеп бетми икән. Расих аңа шундук бер баянын бүләк итеп тапшыра. Баяннарның тагын берсе Бәгәрәктамак авылы мәктәбендә булса, икенчесе Мөслим тимер юл станциясе мәктәбенә Төбәкне өйрәнүчеләр уздырган конференция барышында директоры Зөлфия Вәлиевага тантаналы төстә тапшырылды. Аңлашыла ки, бүләк ителгән гармуннарның күбесе интернеттагы мәгълүм сайт аша сатып алына. Берсенең хуҗасы, элеккеге гармунны сатканда, уен коралында Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте рәисе Тәлгать Таҗетдиннең кереп-кереп уйнап чыкканын да искә төшерә.

Гармун төзәтү кебек четерекле, вак эш сабырлык, төгәллек сорый. Какканда ныграк, яки уңайсызрак суксаң да тавыш үзгәрә. Тәҗрибә дә, осталык та кирәк. Шул ук вакытта оста гармунчыдан уйнатып карау да әһәмиятле. «Профессиональ баянчылардан уйнатып карыйм. Алар килешеп бетмәгән урыннары булса шундук сизеп ала», – ди оста.

Әлбәттә, дусларсыз теләсә кайсы эш авыр бара. Р.Сабирҗановның гармун төзәтү буенча тәҗрибә уртаклаша торган белгечләре бар. Алар үзара булышып яши, кирәк икән, бер-берсенә детальләр белән дә ярдәм итә.

**Сөембикә КАШАПОВА.**

● Әлфия Авзалова исемендәге үзәккә Расих Сабирҗанов бүләк иткән баян һәм гармуннар.

●Расих Сабирҗановтан (уңда) журналист, эзләүче, Татарстан патриотик тәрбия бирүгә булышлык ассоциациясе рәисе Михаил Черепановка туган көн бүләге.

●Чиләбе өлкәсенең Мөслим тимер юл станциясе мәктәбенә баян бүләк итү. Аны мәктәп директоры Зөлфия Вәлиева кабул итеп ала.

Нажар НӘҖМИ

# Безгә генә килгән кебек иде Дөньяның бар хәтәр көннәре...

## (Башкортстанның халык шагыйре Нажар Нәҗминең туууына 105 ел)

### ТАТАР ТЕЛЕ

*Вы, прадеды наши, в недоле,*
*Мукою запудривши лик,*
*На мельнице русской смололи*
*Заезжий татарский язык.*
Я.Смеляков

Туган җирең Идел буе,
Һәр телнең бар Туган иле.
Туган җирең кебек назлы,
Җырдай моңлы татар теле.

Ак алъяпкыч бәйләсәләр,
Өзелеп тора кызлар биле.
Кызлар кебек шат чырайлы,
Ачык йөзле татар теле.

Халкың кебек уңган да син,
Хезмәттә син көне-төне.
Ир-егетләреңдәй дәртле,
Гайрәтле син, татар теле.

Фәннән сине аерса да
Гасырларның афәт җиле,
Аксакалларыңдай олпат,
Акыллы син, татар теле.

Ассалар да, киссәләр дә
Үлмәдең син, калдың тере.
Чукындырган чагында да,
Чукынмадың, татар теле.

Яндың да син, тундың да син,
Нишләтмәде язмыш сине.
Дөньяда күп нәрсә күрдең,
Әй, мөкатдәс Тукай теле.

Төрмәләргә дә яптылар
Җәлил белән бергә сине.
Төрмәләрдә дә килмешәк
Булмадың син, татар теле.

Зинданнарны ярып чыктың,
Ялкынланып чыктың кире,
Хәтта фашист тегермәне
Тарта алмады анда сине,
Әй син, батыр татар теле!

Кабатланмас үткәннәрең –
Гасырларның яман чире.
Кабатлар сине гасырлар,
Татар теле, дуслык теле.

### БАР!

Гасырлардан, иске заманнардан
Тутыкмаган иске хәбәр бар.
Кем әйткәндер, кайчан әйтелгәндер:
«Татар барда, – диеп, – хәтәр бар».

Кайда гына хәтәр юк икән соң?
Ул бар, булган һәм ул булачак.
Хәтәрсезме булды безнең заман,
Безнең яшьлек, безнең балачак?

Безгә генә килгән кебек иде
Дөньяның бар хәтәр көннәре.
Яуда гына күпме ятып калды
Татарның да кеме, кемнәре?!

Хәтәр барда да бит татар бар ул.
Барган икән унау үлемгә,
Аның берсе – бер билгесез Әхмәт.
Туры килүме бу? Кем белгән?..

Бер кабердә өчәү ята икән,
Аның берсе – татар егете.
Туры килүме бу? Әллә бары
Горурлануыммы үз итеп?..

Кайда бакма – хәтәр җирдә татар,
Адәм ышанмаслык даны бар.
Карбышевтан кем сораган? Ә ул:
«Миндә, – диган, – татар каны бар!»

Кая бакма – хәтәр җирдә татар,
Үлемнәрнең сыртын сындырып,
Утлардан да, Моабитлардан да
Кем соң чыкты моңлы җыр булып?!

Палач балтасына башны тотып,
Көлеп үлгән икән татарлар.
Дошман өчен, сатлыкҗаннар өчен
Татар барда, чынлап, хәтәр бар...
Бар!

* * *
Мин үземә һәйкәл куялмадым –
Балкырдаен җырлар нурыннан.
Булдым заман колы, ә колларга
Кайда, нинди һәйкәл куелган?

Куйган аны халык мәхәббәте
Шагыйренә борын-борыннан,
Әгәр үзе мәхрүм ителмәсә
Азат җирле халык булудан.

Кеше йөрәгендә мин дә, димен,
Урын алдым бугай, аламын!
Әмма кеше җирдән китә бара,
Ә мин кайда, кемдә каламын?

Кем атар соң минем исемемне
Туган җирдә, туган телемдә,
Әгәр дә ул өйдәш булып калса
Үз өендә, туган өендә?

Мин үземә һәйкәл куялмадым –
Балкырдаен җырлар нурыннан.
Туган телсез мин юк! Ә юкларга
Кайда, нинди һәйкәл куелган?

### ХӘТЕР КӨНЕ

*Хәтер көне игълан ителде!*
Татар газетасыннан

*Кто старое помянет, тому глаз вон.*
Рус халык әйтеме

Үткәннәрне хәтерләмә, имеш,
Хәтерләмә кара үткәнне.
Оныт, имеш, синең өскә ничек
Күпме гасыр пычрак түккәнне.

Күпме гасыр халык йөрәгеннән,
Милли яралардан кан тама.
Татар өчен җәбер, мыскыл нәрсә,
Рус өчен бәйрәм, тантана.

Хәтерләмә кара... Хәтерләтеп
Үткәнеңне Кызыл мәйданда,
Аждаһадай тугыз башлы храм
Сине гел кисәтеп торганда.

Кайтты бүген хәтер көне генә.
Ә хәтердә коллык, күпме кан.
Киләчәгең булмаячак, татар,
Үткәнеңне әгәр онытсаң.

### АК ҖИЛКӘН

*Хәсән Туфанга*

*Белеет парус одинокий...*
М.Лермонтов

Уфаларга килсә, урамнардан үтә
Йә булмаса, бизәп араны,
Утыра ул безнең белән бергә,
Ялгыз җилкән кебек агарып.

Ул ялгыз да һәм ялгыз да түгел,
Безнең белән утырып янәшә,
Ул яшьлеге, ул бүгенге белән,
Киләчәге белән сөйләшә.

Без дә хәзер бик карадан түгел,
Без дә хәзер инде агарган.
Ә барыбер, бергә утырсак та,
Без малайлар әле, малайлар.

Ак башында кара кайгылармы,
Әллә микән Себер карлары?
Бардыр инде, барысы да бардыр –
Сөзәк түгел гомер ярлары.

Бардыр инде, барысы да бардыр,
Шагыйрь гомере – бару юл ярып,
Бер агаргач, кабат караймыйча,
Ул яшәсен шулай агарып –
Юк, акланып түгел, агарып!

Бардыр инде, барысы да бардыр,
Җиңел түгел гомер юллары.
Бөтенесе бергә төйнәлгән бит –
Язмыш моңы, шигырь моңнары.

Уфтану ят аңа, ишеттермәс
Яшәү хакында ул авыр сүз.
«Бер газапсыз шагыйрь буламыни,
Океан буламыни давылсыз?!»

### ЧИТ ТЕЛ АША...

*Рәсүл Гамзатовка*

Онытмыйммын, берчак шулай, белгәч,
Мин Мостайдан өлкән икәнне,
Синең миңа: «Нигә, болай булгач,
Син билгеле түгел?» – дигәнне.

Өйрәнелгән синең тапкырлыкка,
Сүзләреңнән озак көлештек.
Көлештек тә, шәрабыңны эчкәч,
Без үбештек бугай, үбештек!

Дустыңның мин дусты булган өчен,
Дус күрәсең бугай бүген дә.
Ул турыда синең шигырь дә бар,
Сөйләдең син авар телендә.

Яшермимен, синең кебек данлы
Кеше белән, ничек булса да,
Дус булуы ул горурлык, димен,
Яшәү җиңелрәк дөньяда.

Тик авырдыр сезнең кебекләргә,
Бигрәк тә синең кебеккә.
Чит тел аша күпме
«...шагыйрьләрнең
Баш өстеннән» сикереп биеккә.

Очар өчен кирәктер ул булу
Үз халкыңның Пушкин, Тукае.
Ә соң Тукай, Мәхмүт бөтен илгә
Синдәй билгелеме, дускаем?

Һәр юлында очкын чәчрәп тора,
Ут булмый бит, булмый һич юктан.
Анда чыңлау!.. Чыңлап
торганны бит
Ясап булмый кызыл балчыктан.

(Балчыктан ул чүлмәк ясап була,
Чүлмәкнең дә була үз чыңы.
Кайсы чакта чүлмәк тавышында
Күмелеп кала чыңның иң чыны.)

Һәр талантның җирдә үз урыны бар,
Һәр телдә бар акыл, моң вә чәм.
«Син Тукайдан өстен!» – дияр идем,
Татар телен әгәр белмәсәм.

### ТАТАР БУГАЗЫ

*Габдулла Байбуринга*

Но я
себя
смирял,
становясь
на горло
собственной песни.
В.Маяковский

Башкорт, татар – телләр тәрҗемәсез...
Башкортча бар җырым, моң-сазым.
Татар, башкорт кайда гына юк соң?
Әле менә Татар бугазын
Ярып киләм... Теплоходта киләм.
Бер горурлык тоям күңелдә.
Помкапитан якташ: «Саумысыз!» – дип
Сәлам бирә татар телендә.

Бер горурлык тойдым: Сахалинда
Башкорт кызы – таныш кыз миңа –
Балаларга рус теле укыта
Киньябулатова Тәнзилә.

Бугаз дисәң... Җир йөзендә сансыз...
Зуры, бәләкәе... башкасы.
Кайда, дисәң, Татар бугазында
Көнчыгышның Диңгез капкасы.

Сахалиннан материкка Татар
Бугазын мин ярып киләмен.
Палубага түгел,
гүя үз җырымның
Бугазына басып киләмен.

Әй, басылсын! Хәтта бөеклекнең
Кала җирдә бары беразы.
Үзгәрешле дөнья! Синдә әле, димен,
Озак яшәр Татар бугазы.

# БӨЕК ҖЫРЧЫ

*Аллаһ бүләге булгандыр, яшьтәшем һәм дустым Илһам Шакиров белән мәктәптән алып, озак еллар буе фикердәшлек, дуслык насыйп булды. Без 1935 елда хакимият оештырган Ворошилов районы авылларында шул ук елда туганбыз. Ул - Яңа Бүләктә, мин Иске Абдулда. Тик Илһамның әти-әнисе аны Сарман районы тумасы итеп яздырган. Яңа Бүләк авылы моңа кадәр Сарман районы составында булгангадыр, ахры. Шуңадыр, Илһам гомере буе үзен Сарман кешесе дип санады, «Сарман» көен аннан да моңлырак итеп, күңелне айкап җырлый торган оста табылмады.*



Марс Гаитов.

Беренче мәртәбә мин 13 яшьлек Илһамны Ворошилов районы үзәге – Теләнче Тамак авылы сәхнәсендә 1948 елда күрдем. Гыйнвар аеның үтә салкын көне, әл район укытучылары конференциягә җыелган иде. Әнием Маһруй Шакирова – Иске Дөреш җидееллык мәктәбе мөгаллиме, бу җыенга мине дә алды. Соңыннан үзешчән артистлар концерты булды, аны алып баручы бермәл игълан итте:

– Хәзер иң яшь артистыбыз, Яңа Бүләк мәктәбенең 4 нче сыйныф укучысы Илһам Шакиров җырлый. Аны бирегә толыпка төреп, ат чанасында алып килгәннәр.

Сәхнәгә бер малай чыгып басты, озын җырны искиткеч моңлы итеп башкарды. Залдагылар гөрләтеп кул чапты. Мондый малайлар да була икән, дип шаккаттым.

Ә Илһам белән 1952 елда, Теләнче Тамак мәктәбендә укыганда дуслаштым. Без яшьтәшләр булсак та, мин 9 нчыда укыйм, ул 8 нчедә белем ала. Районда бердәнбер урта мәктәп булганга, укучылар 8 нче сыйныфка ерак авыллардан да килә, кышын фатирда яшиләр, ул чакта интернат юк. Һәр көн Илһам – 12, мин 8 чакрым араны җәяү йөрибез. Хуҗи авылы тирәсендә очрашып, сөйләшә-сөйләшә бергә атлыйбыз, кайтканда шунда аерылышабыз. Бу чибәр егет бик кызыклы әңгәмәдәш иде, мәктәптә укыганда ук җырчы булып танылды. Үзешчән концертларда, әдәби-музыкаль кичәләрдә аны һәрчак җырлаталар, ул ялындырмый, теләп җырлый иде. Түзмичә сорадым: «Күп җырлар беләсең, аларны ничек өйрәндең?» Ул елмая: «Безнең Яңа Бүләк авылындагы күршебез Шәрифулла абзыйларның патефоны бар иде. Ул кече күңелле кеше, малайларга шундагы җырларны туйганчы тыңларга рөхсәт итте, мин аларны отып, кабатлый башладым». Ул татар әдәбиятын, күренекле язучыларның әсәрләрен белә, укыганы белән уртаклаша. Мин дә әдәбиятны яратам, китап-журналларны күп укыйм, шуңа әңгәмә икебез өчен дә бик файдалы була. Укытучыларны, кызык хәлләрне искә алып көлешәбез. Шулай юл кыскара.

Кышын без фатирдашлар – мин әнинең сеңлесе Мөнәвәрә апаларда, Илһам күрше йортта – бертуган Гөлсем апасында яшәде. Без китапханәгә, кинога бергә йөрдек, чаңгыда шудык. Илһам белән без яшәгән «мәктәп» урамында тик бер йортта – сабакташ Рубис Зариповларда гына радио бар иде. Илһам моны белгәч, Казан тапшыруларын тыңларга дип, иртән-кичен гел аларга йөрде, бигрәк тә концерт дигәндә үлеп китә иде.

Илһам белән без әле Илсөяр апа Сөнкишева җитәкләгән татар әдәбияты түгәрәгенә дә йөрдек. Ул мәктәптә дивар газетасы чыгаруны да җайга салды. Остазыбыз укучыларда иҗат итү, язу теләге дә тудырды. Өстәвенә, Илсөяр апабыз Муса Җәлилнең әсирлектәге көрәштәше, балалар шагыйре Абдулла Алишның туганы да булып чыкты. Ул Алишның балачагы, тормыш юлы турында сөйли, ә без Илһам белән дивар газетасына мәкаләләр язып бирә идек. Бермәлне Илһам миңа үзе язган «Ана» исемле хикәясен укытты. Миңа бик ошады. Дустыма: «Хикәяңне әйбәт язгансың, шулай дәвам ит, бәлки, әле киләчәктә язучы булып китәрсең!» – дип елмайдым.

Илһам миңа әтисен 1937 елда НКВДның кулга алуы, Минзәлә төрмәсенә озатуы, аның хәбәрсез югалуы турында да сөйләми калмады. Алты бала атасы Гыйльметдин абзый (1890-1940) колхозда оста тимерче булган. Газеталар укып барган, яңалыкларны авылдашларына да сөйләгән. Берчак тимерче алачыгында, берничә авылдашы (берсе НКВД шымчысы) барында аны-моны абайламый әйтеп ташлаган бу: «Троцкий гаепле түгел!» Сексот аның бу сүзләрен шундук НКВДга хәбәр итә. Өч кешедән торган мәхкәмә тимерчене «троцкийчы халык дошманы» булуда гаепләп, 8 елга төрмәгә ябып куя. Концлагерьда 1940 елда вафат булган Гыйльметдин ага 1972 елда гына аклана.

Алты бала белән ирсез калган Нуриәсма (1892-1981) бик авыр хәлгә дучар була. Балаларны ачлыктан, үлемнән сакларга кирәк, ә колхоз хезмәт хакы түләми. Төпчек бала Илһамга нибары ике яшь, апалары да кечкенә. «Халык дошманы» гаиләсе төрле кыерсыту, кимсетүләргә дучар була. Бу гаиләгә миһербансыз хакимият «төрмәче гаиләсе» дигән мөһер суга һәм икеләтә салым түләтә. Алты ач балалы гаилә дәүләткә ел саен 8 кг сары май, 40 кг ит, 200 йомырка, аларга өстәп сөт, йон һәм акчаны үз вакытында илтеп тапшырырга тиеш була. Сугыш башлангач, өлкән уллары Имаметдинны (1915-1943), аксак булса да, фронтка алалар, аның сугыш кырында һәлак булуы турында кара хәбәр килә.

Ачтан үлмәс өчен, балалар күрше авылларга барып, өйдән-өйгә йөреп хәер-садака сорашып та йөри. Үзләре дә кыен хәлдәге хатын-кызлар, аларны кызганып, бер кабымлык ризык суза, тик анысы да Илһамга тәтеми, чөнки ул арада иң кечкенәсе бит. Илһам җырлап җибәрә, күңеле йомшарган хуҗабикә аңа да өлеш чыгара. Еллар үтеп, үсә төшкәч, Илһам чабата ясарга өйрәнә. Аның өчен яшь юкә агачы кайрысы кирәк. Авыл тирәсендә урман, Илһам шуннан төнлә, урман каравылчысы йоклаганда, чимал әзерләп кайта. Урманда йөргәндә, тавышын күтәрмичә генә моңлы җыр суза. Абыйсы Кыяметдин (1932-2002) белән бер төндә бер пар чабата өлгертәләр. Качып-посып, Теләнче Тамак яки Нөркәй базарында саталар. Тик Илһам барыбер 5 нче класска бара алмый. Коточкыч хәерчелек әнисенә берьюлы ике баланы укытырга ирек бирми.

Бөек Ватан сугышы җиңү белән тәмамлангач, Теләнче Тамак авылының Иганә елгасы буендагы болынында һәр елны Сабантуй бәйрәме гөрләп уза, анда төбәк авылларыннан күп халык җыела, без дә гаиләбез белән барабыз. Мәйдан уртасындагы сәхнәдә Яңа Бүләк авылыннан бертуган Кыяметдин белән Илһам Шакировларның парлап җырлавы бик ошады. Сабан туе халкы аларны мөкиббән китеп тыңлады, алкышларга күмде, без дә кушылдык.

Тора-бара җидееллык мәктәпне тәмамлау бәхете эләккәч, Илһам Теләнче Тамак урта мәктәбенә дә килде, барлык фәннәрне тырышып үзләштерде. Математиканы аеруча ярата, мәсьәләләр чишә, башкаларга да ярдәм итә иде.

Беркөнне Илһам миңа яшерен серен ачты: «Сезнең класстагы бер кызга гашыйк булмадым микән?» «Кем ул?» «Клара Мостафина! Тик бер кешегә дә әйтмә!» «Үзенә әйттеңме соң?» «Юк, уңайсызланам, ул унынчы класста, ә мин тугызда». «Ул бит 1936 елгы, синнән яшьрәк, оялма, әйт үзенә!» Соңрак, бер елдан соң ачыкланды: юк, әйтмәгән икән.

Урта мәктәптән без, 9 абитуриент, Казанга югары уку йортына керергә өметләнеп бардык. Ул елда барча институтларда конкурслар бик зур, авыл хуҗалыгы институтында бер урынга 7 дәгъвачы җыелган иде. Берничәбез генә максатка ирештек. Мин һәм Клим Кәлимуллин авыл хуҗалыгы институтына, Клара Мостафина – Казан университетының РТО (рус-татар бүлегенә) керде. Без элекке сабакташлар, инде студентлар, әледән-әле очрашып, Казанның тарихи урыннарын карап йөрдек. Кларага Ленин урамында тулай торакта урын бирделәр, ә без ике ел фатирдаш булып, акча түләп яшәдек.

Бер очрашуда Клара әйтә: «Теләнче Тамактан хат алдым әле. Илһам Шакиров исемле бер малай миңа гашыйк булган, имеш. Сине өзелеп яратам, дип язган, ничек җөрьәт иткән!» «Җавап яздыңмы соң?» «Язып та тормыйм, кем ул шулкадәрле!» Менә шулай, Клара мәктәптә дә үзен башкалардан югарырак куеп, тәкәбберлек күрсәтә иде. Ә университет студенты булгач, бу чире көчәйгән, борын шактый күтәрелгән икән.

Көтмәгәндә Илһам белән без 1954 елда Казанның Горький урамында очраштык, кочаклашып күрештек. Ул музыка училищесында укый икән. Тик мине аның чем-кара чәчләренең төбенә кадәр кыркып алынуы аптыратты. «Ник чәчләреңне болай алдырдың?» «Әйдә, мин яши торган фатирга, тарихын шунда сөйләрмен», – дип иртеп тә китте. Училище подвалындагы бер бүлмәле фатирга төштек. Хуҗабикә – татар хатыны, уку

Илһам Шакиров төшкән беренче фото. 1951 ел. Илһам беренче рәттә сулдан беренче.

# ДУСТЫМ

● Студентлар.

● Илһамның уналты яшьлек чагы.

йортында идән юучы икән, ул өйдә юк. Илһам сөйли. Урта мәктәпне тәмамлагач, Илһам Алабуга педагогика институтының математика факультетына керү имтиханнарын бик яхшы билгеләргә тапшыра. Математика мәсьәләләрен «бишле»гә башкарса да, укытучы Люстиг (немец, антифашист, Бөек Ватан сугышында Совет Армиясе сафында катнаша) аның эшенә «икеле» билгесе куя, Илһамны институтка алмыйлар, чөнки ул «халык дошманы»ның малае бит. Сталинның яшерен әмере нигезендә андый балаларны югары уку йортларына алу тыела, алар НКВДның даими күзәтү астында тотыла. Математик Люстиг, НКВД таләбен үтәп, шундый пычрак гамәл кылырга мәҗбүр була.

Илһам мондый җиңелүне бик авыр кичерә, әлбәттә. Инде күп еллар үткәч, Илһамның Алабуга студентлары алдында узган концертыннан соң, әлеге Люстиг аның янына килеп: «Сезнең математикадан имтиханыгызга мин «бик яхшы» билгесе куйган идем, НКВД таләбен үтәп, «икелегә» төзәттем. Мондый түбән гамәлем өчен, зинһар, кичерегез», – ди.

Педагогика институтына керү өчен якындагы куак кырында чирәмдә ятып, Илһам имтиханга әзерләнә, тәнәфес ясап, моңлы итеп җырлап җибәрә. Тирә-яктагы абитуриент кызлар бу моңга шаккатып, җырчыны эзләп таба, исемен сорыйлар, «Илһам», – ди егет. Бүлмәләренә алып кереп, кат-кат җырлаталар, бүлмә, коридор яшьләр белән тула. Бер өлкәнрәк абитуриент, армия хезмәтеннән кайткан Өлфәт Миңнеханов: «Мондый сәләтең белән йөрмә монда, Казанга бар, консерваториядә укы!» – ди. Имтиханнар тәмамланып, институтка кабул ителмәвен белгәч, Илһам Алабугадан туп-туры Казанга юл ала.

Казан музыка училищесына килсә, Илһам белән сөйләшергә дә теләмиләр, имтиханнар инде тәмам, соңга калгансыз, киләсе елга килегез, диләр. Илһам директор Ильяс Әүхәдиевкә (1904-1968) мөрәҗәгать итә. Ул да башта авыл егете белән теләмичә генә сөйләшә. Егет кабинеттан чыгып китми торгач: «Җырлап күрсәтегез әле», – ди. Илһам «Зәңгәр шәл» спектакле өчен Салих Сәйдәшев иҗат иткән Булат ариясен – «Кара урман»ны сузып җибәрә. Директорның йөзе яктырып китә. Кабул итү кагыйдәләренә каршы килеп булса да, бу җырчы егетне хәзер үк училище студенты итәргә карар кылалар. Шундук укытучылар составында гадәттән тыш комиссия оештырыла, Илһам тагын җырлау имтиханы башкара. Нәтиҗәдә комиссия әгъзалары бертавыштан аны училищега кабул итә. Илһам канатланып Яңа Бүләккә кайтса, энисе аңа Ворошилов районы хәрби комиссары кул куйган повестка тоттыра. Илһам военкомата барып, үзенең музыка училищесына кабул ителүе турында сөйли, миңа укырга мөмкинлек бирегез, дип үтенә. Офицер «илдә андый канун юк, армиягә барасың», дип тәкрарлый. Военком да Илһамның биографиясен өйрәнгән, аның «халык дошманы» улы булуын белә икән. Явыз итеп: «Әтиең юлыннан китәргә җыенасыңмы?» – дип куркыта. Шулай итеп, кирза итек, сәләмә киемнәр кигән, чәче төбенә кадәр кырдырып алынган Илһам Казан каласына, Татвоенкоматка юл тота. Әмма Чаллы пристанендә аның чемоданын урлыйлар, паспорты, башка документлары да шуның эчендә була. Соңрак ул Казаннан энисенә: «Зәйнәп апа Чаллыга барып кайтсын әле, паспортны ташламадылар микән», – дип хат та яза. Бертуган апасы Чаллыда өч көн торып, милициягә мөрәҗәгать итеп карый, ләкин документлар эзсез югала. Илһам Татвоенкомат казармасында бер документсыз көе ята торгач, атналар үк уза. Илһам үзенең сөеклесе – университет студенты Клара Мостафинага хат язып сала, үз хәлен тасвирлый. Клара курсташ дус кызы белән бергә Илһам янына килә. Капка сакчысына 1 сум акча биреп, аны урамга алып чыгалар һәм консерваториягә алып китәләр. Бәхеткә, Казан кызының энисе анда укытучы икән.

Клара укытучыга Илһам турында сөйләгәч, ул сәләмә киемле егетне консерватория ректоры, профессор Нәҗип Җиһанов кабинетына алып керә. Ректор Илһамга: «Я егет, җырлап күрсәт әле!» – ди. Илһам «Туган ил» җырын үзәккә үтәрлек итеп башкаргач, Нәҗип әфәнде бу егетнең киләчәктә бөек җырчы булачагын абайлап ала һәм Илһам язмышын уңай якка хәл итә. Инде музыка училищесына кабул ителгән, әмма әле музыкаль белеме булмаган (районда бер музыка мәктәбе дә юк иде), сольфеджио турында мәгълүматсыз, әмма оригиналь сәләтле авыл егетенә мондый киңәш бирә: «Бер ел училищеда музыкаль белем аласыз, аннан соң безгә, консерваториягә киләсез». Армия хезмәтеннән йолу өчен, шәфкатьле ректор Илһамга консерватория студенты дигән ялган справка тоттыра, ә югары уку йорты студентын армиягә алмыйлар. Ниһаять, минем якын дустыма бәхет елмайды, ул данлыклы Казан консерваториясендә укыячак!..

Шулай итеп, Илһам музыка училищесына килә. Ә өстебашы, киемнәре сәләмә, аякларында кирза итекләр, чәчләре кыркылган. Ул чакта анда өченче курста укучы студентлар, киләчәктә композитор булачак Фасил Әхмәтов (1935-1998) һәм Мирсәет Яруллин (1938-2009) бу сәер яшь егетне коридорда күргәч: «Нишләп соңга калдың, дәресләр башланды бит инде? Ник болай сәләмә киемнән? Чәчеңне ник алдырдың?» – дип сорашалар. Илһам: «Мине армиягә алганнар иде, шуннан килдем. Җырчы булырга, җырларга өйрәнергә исәп, гәрчә өйрәнәсе дә юк, мин җырлый белəм!» – ди. Әлеге студентлар Илһамның җырлавын тыңларга була, аны буш аудиториягә алып кереп, баянчы китертәләр. Илһам җырлый башлый, аудиториягә училище студентлары кереп тула. Гадәттән тыш бу могҗизаны, таныш түгел җырчыны якыннан күрергә теләп, барлык студентлар җыела. «Афәрин!» – дип, Илһамны мактыйлар, кулларын кысалар. Әле торырга урыны да юклыгын белгәч, булачак композиторлар аны училище подвалында яшәүче, идән юучы апа фатирына урнаштыра.

Кайбер авторлар Илһамның музыка училищесына укырга керүе турында дөрес язмый. Ул авылыннан беркемгә әйтмичә Казанга чыгып киткән дә, училищега имтихан биреп кабул ителгән, имеш. Чынбарлыкта алай түгел шул, мин Илһам үзе сөйләгәнне яздым.

Училищеда ачылган «Шәхси эш» папкасында Илһамның бер документы да юк. Администрация аның аттестатының икенче нөсхәсен җибәрүне сорап, Теләнче Тамак урта мәктәбенә телеграмма юллый, озакламый ул килеп тә җитә.

Ул елны мин Маяковский урамында, якташым, урам себерүче Лотфикамал апаның кысан бер бүлмәле фатирында өченче инсан булып яши идем. Илһамга аны күрсәткәч, без еш күрешә башладык. Хуҗабикә исемем «Марс» сүзен дөрес әйтә алмый, мине «Марус» дип атый иде, Илһамга бу кызык, гаҗәп тоелды. Икебез генә булганда, аны көлеп искә алгаладык. Хәтта озак еллар узгач та (2011 елда) онытмыйча, Илһам шуны кабатлады, көлештек. Минем стипендия 290 сум, ә Илһам нибары 130 сум ала, өеннән ярдәм юк, әле шул акчадан фатир өчен дә түлисе. Бик кыен хәлдә иде музыкант студент. Бераз булса да акча эшләү өчен ул пристаньга барып, йөкче сыйфатында баржадан авыр капчыклар (тоз) күтәреп ташыды.Шундый мохтаҗлы вәзгыятьтә дә Илһам оптимист булды, сольфеджионы үзләштерде, рояльдә төрле музыкаль әсәрләр башкарды, белем алу хезмәтендә «энә белән кое казыды».

**(Ахыры киләсе санда).**

**Марс ГАИТОВ.**

Мәдәни җомга
10 февраль
№5, 2023

# Яңа ысуллар кирәк

**Бөтендөнья татар конгрессының Милли шура әгъзасы, Төмән өлкәсе вәкиле Ринат Насыйров фикере.**

Без үзебезне татар халкы буларак саклыйсыбыз килә икән, үз динебез, тел һәм гореф-гадәтләребезгә таянырга тиешбез. Шуның бөтен ягын да канәгатьләндерә алмыйбыз икән, саныбыз кимиячәк. Без Аллаһ Тәгаләнең сөннәте буенча яшәмибез икән, ул әйтә: «Сезнең урыныгызга бүтән халыкларны җибәрәм», – ди.

Татар халкының саны кимүнең объектив сәбәпләренең берсе аның пассионарлыгын (ниндидер максатны тормышка ашыруга юнәлтелгән, үзгәртеп булмый торган эчке, аңсыз омтылыш) атар идем. Безнең уртак таянычыбыз юк. Иманны үстерергә кирәк. Ул ана сөте, бабай фикерләре белән сеңә. Иманыбыз түбән булгач, татар теле дә якын күренми, гореф-гадәтләребез дә онытыла, диннән дә аерылабыз. Цивилизацияле алымнар белән без халыкның пассионарлыгын үстерә алмыйбыз. Шуңа күрә бүтән формаларны карарга кирәк.

Һичьюгы сакланып калу зарур. Укытучыларны гына карагыз, аларның вакытларының күп өлеше ниндидер кәгазь эше, бюрократлыкка сарыф ителә. Безнең җитәкчеләребезнеке дә шулай. Мәктәп директорлары бюрократик статистика белән шөгыльләнә, мәчеттәге имамнар кайсы китапның ярый, кайсы ярамый икәнен ачыклау белән мәшгуль. Аларның 99 % вакыты башка эш белән тулган. Калган 1 процентка гына булса да, «татарлыкны үстерү» дигән стратегия куелса, бәлки, үзгәрешләр дә булыр иде.

Бүгенге көндә татар халкы санын саклап калу күп берни дә эшләп булмый. Татарларның компактлы яшәгән урыннарында – Себер, Әстерхан, Башкортстан булсынмы ул, безгә көчәеп, күбәеп, үзебезнең үрнәк учреждение, оешмаларыбызны булдырырга кирәк. Аны хөкүмәт аркылы эшләп булуына ышанмыйм. Үзебезнең эшмәкәрләр, дин әһелләре, фольклор юнәлешендә эшләүче кешеләребез аркылы гына эшләп була.

Җил кая иссә, шул якка ятабыз без. Безгә яңа юл, яңа методология белән башка юл табарга кирәк. Татар халкы язмышы әле бүген тумаган сабыйлар кулында да булырга мөмкин. Безнең бурычыбыз: татар халкына шул мөмкинлекне бирү.

Безнең статистика буенча бүген Россиядә татарларның 3,5% гына пассионар актив. Телисезме, юкмы, калганнары – биомасса. Безгә ул санны ким дигәндә 20%ка үстерергә кирәк. Шуннан соң гына без 80% нәтиҗәгә ирешә алабыз. Безгә элитаны татар итеп үстерергә кирәк, башкача булмый.

# Сагындык малае ТАҖИ

**Нур ӘХМӘДИЕВ**

*«Атларым, колыннарым» повестеннан*

**(Ахыры. Башы 4 нче санда).**

Ул тиз-тиз атлап бараклар ягына китеп барды. Артыннан Наиләләрнең чебен көтүе иярде.

Юк, Роза апа, сез хаклы түгел. Берәүгә дә борчу китерергә теләмәгән идем. Алай ук начар малай булмавыма ничек ышандырыйм сезне?

Кара алаша хуҗасы тагын:

– Алай икән, – диде. – Исемең кем әле синең?

– Тажи.

– Алай икән. – Шәһит абый башка сүз әйтмәде, борылып, арба тәзәтүен дәвам итте.

Әкрен генә бүлмәмә табан атладым. Шактый китеп өлгергән идем, Шәһит абыйның тавышы ишетелде:

– Вакытың булганда килеп йөр!

Лагерь дигәннәре кызык: егерме дүрт көнгә генә килсәләр дә, нәкъ мәктәптәгечә отрядлар, звенолар оештырган булалар. Безнең отрядка председатель итеп мин сулы табакка чумырган Эдик-Эдуардны сайладык. Наиләләр, Гөлзифалар да безнең отрядтан икән. Исем-акылым китте шәһәрдән килгәннәргә: барысы да диярлек татарлар, үзләре гел урысча гына сөйләшәләр. Исемнәрен дә бозып бетергәннәр: Гамил – Гена, Сәфәрне Сережа дип йөртәләр, якынрак дуслары Серый дип тә җибәрә. Миша дигәннәре Мөнир булып чыкты. Наиләсе – Неля, Гөлзифасы – Гуля. Кыланчыклар. Югыйсә, татарчаны да гел аңламыйлар түгел, ник сөйләшмиләрдер. Ә минем урысчам чамалырак. Лагерьга килгәч, беренче тапкыр тере урыс күрдем. Шулай да әйткәннәренең күбесен аңлыйм.

Эдикның ярдәмчесе итеп Наиләне сайладык. Эдикка күңел тартмаган иде, Наиләгә биш куллап риза булдым. Татарча сирәк сөйләшсә дә, бик ярдәмчел кыз ул. Үзе сөйкемле дә. Кап-кара күзләр. Моңа кадәр аныкыдай шомырт кара күзләрне беркемдә дә күргәнем юк иде.

Нефтьчеләр лагере булгангадыр инде, башлыча монда шәһәр балалары. Минем сыман авыл малае тагын берәү генә. Ул да булса Мәүлит. Күккүз авылыннан. Танышу белән без дуслашып, якынаеп киттек.

Бәхеткә, вожатый Роза апа ачу сакламый. Теге көнне мактанчык дип шелтәләп киткәч, күзенә күренергә шөлләбрәк йөргән идем. Бүтән ул хакта сүз кузгатмады.

Лагерь урнашкан урын чыннан да матур. Урман эчендә булу өстенә, илле-алтмыш метрлар гына читтәрәк күле дә бар. Ул зур да түгел, кечкенә дә түгел, нәкъ кояш нурларында ялтырап ятучы сихерле көзге инде. Кырыена килеп чыктыңмы, киемне салганчы ук чумасы килә.

Күл буенда зур-зур өянкеләр үсеп утыра. Кызык: аларга ничә яшь икән? Өянкеләрнең берсе, тамырыннан йолкынып, су өстенә ауган. Хәзер ул басма урынына хезмәт итә. Су коенганда аңа басып чумабыз, аңа басып балык тотабыз. Тик балыгы гына этләч тә кесми генә. Этләче, ичмасам, ашарга да ярамый, безнең Кирмән малайларыннан ишеткәнем бар, алар аны эткә, мәчегә генә бирәләр икән.

Авылда көннәр тиз үтә иде, лагерьда да сизелми кала. Иртән флаг күтәрергә тезеләбез дә, ашап-эчкәч, йә җыр өйрәнәбез, йә төрле ярышлар уздырабыз, кино да күрсәткәлиләр. Ике көн рәттән җиләк-җимеш бакчасына эшкә алып бардылар. Бакча җиләге җыйдык. Мин аны эшкә дә санамас идем, чөнки чыпчык башы кадәр зурлыктагы җиләкләрне җыйнауның ни авырлыгы бар? Күпме ашасаң да, сүз әйтүче юк. Корсагың гына әйләнеп чыкмасын. Тик, ни гаҗәп артыгын күп ашап булмый икән шундый тәмле җиләкне дә.

Авыл, бабай искә төшкән чакларда Шәһит абый янына килеп чыгам. Ике тапкыр аның белән Баланлы авылына сөткә барып кайттык. Баланлы лагерьга ерак түгел, нибары ике-өч чакрым гына. Кара алашага карап үзебезнең атларны искә төшерәм. Мәсәлим абыйны атлар чит итми микән? Гомере буена тимер-томыр арасында эшләп, йомшак итеп эндәшүне онытып бетермәде микән?

Отрядлардан чиратлап ашханәгә дежурга җибәрәләр. Күптәннән барасым килеп йөри иде, беркөнне миңа да чират җитте. Эдик, Мәүлит, Гөлзифа һәм Оля белән туры килдем.

Аңламыйм шул Эдикны. Үзе отряд советы председателе, үзе эшкә килгәндә, ата ялкау икән. Җиләк җыйган чакта да акыл өйрәтеп, акырып-бакырып кына йөргән иде. Зурлар янында эшем иясе булып күренергә ярата үзе. Отряд советы председателен мин башкаларга һәрьяклап үрнәк күрсәтергә тиеш дип уйлыйм.

Бүген менә ашханәдә дә, бәрәңге әрчергә кушкач, каядыр юкка чыкты. Миңа нәрсә, бәрәңге әрчү минем өчен уен гына. Мәүлит тә авыл малае. Оля шәһәр кызы, моңа кадәр әрчегәне булмаган, ләкин ул уңган кыз, әнә ничек тырыша: безгә карап кабыгын юп-юка әрчемәкче. Әмма пычакның Оляны бик үк тыңлыйсы килми, вакыт-вакыт бәрәңге кабыгы бармак калынлыгы була да китә. Гөлзифа кулыннан узган бәрәңгеләрне бүген күргәзмәгә куярлык: ап- аклар, чисталар.

Үзебезнең чиләктәгесеннән котылгач, өчәүләп Оляга ярдәм иттек.

Ашханәдә бер кат иртәнге мәшәкать тәгәлләнде. Баш пешекче Фәгыйлә апа безне:

– Эш беткәч, балалар, бер утырып чәйләп алсак та ярар. Әче коймак пешердем, килегез, кил, тизрәк, суынганчы ашагыз! – дип табын янына чакырды.

Шуны гына көткән кебек, әллә кайдан Эдик пәйда булды. Барыбыздан алда өстәл артына да барып утырды:

– Минем дә карын ачты, есть хочу, – дип, берәүне дә көтмәстән, коймакка үрелде.

Чәй эчкәннән соң безнең бер сәгатьләп буш вакыт калды. Кызлар чәчәк җыярга китте, без, малайлар, туп тибәргә керештек. Эдикны күрү белән ни өчен эштән качып йөрүе турында сорыйсым килгән иде, Мәүлит алданрак өлгерде:

– Кайда йөрдең, ник бәрәңге чистартышмадың? – дип мәсьәләне кабыргасы белән куйды.

Эдик тәкәббер кыяфәттә:

– Сиңа отчет бирергә, мин отряд советы председателе, син рядовой гына, эшең булмасын! – дип җавап кайтарды.

Мәүлитнең талканы минекеннән корырак булып чыкты, боргаланырга урын калдырмаслык итеп янә сорады:

– Ник эштән качтың? Кайда йөрдең?

Эдик хихылдап көлде:

– Пусть дураки работают. Мин монда эшләргә килмәдем, ял итәргә килдем.

Аның бу сүзе Мәүлитне бөтенләй чыгырыннан чыгарды. Сабыр, юаш кына малай сыман тоела иде, юаштан юан чыга дигәннәре хак икән.

– Синеңчә без ахмак, дурак, син акыллы инде, әйеме? – диде ул күкерт кебек кабынып һәм Эдик тайпылып өлгергәнче, тегенең касыгына берне менеп тә төште. Эдик чайкалып китте, ләкин егылмады, киресенчә, ничектер, җаен китереп, иелеп торган Мәүлитнең битенә җан-фәрманга ботинкасы белән тибеп өлгерде. Мәүлит кычкырып җибәрде һәм ике кулы белән битен тотып ауды.

Аның ярсуы миңа күчте. Мәче житезлеге белән Эдикка ташландым:

– Ах, әле син шулаймы?

Эдик-Эдуард беренче көнне арты белән сулы табакка чумганын онытмаган иде, күрәсең, табанын ялтырату ягын карады. Юк инде, агай-эне, син шәһәр шпанасы булсаң, авыл малае диләр безне! Куып җитеп төртеп җибәргән идем, Эдик барып төште, һәм бөгәрләнеп яткан көйгә:

– Каравыл, үтерәләр! – дип акыра башлады.

Аңардан җирәнеп, читкә атладым. Ә ул арттан:

– Деревня, салаги! Я вам покажу! Елатам мин сезне! – дип яный башлады. Түзмәдем, Мәүлит янына барган җирдән кабат аның ягына ыргылдым. Ләкин Эдик:

– Үтерәләр! – дип шәрран ярып ераграк ычкыну ягын карады.

Мәүлит һаман битен каплаган көе чирәмдә ауный. Аның янына ашыктым.

– Кулыңны ал, карыйк әле...

Аһ, Эдик дуңгыз, тибеп, чак кына Мәүлитнең күзен чыгармаган. Кан савып кара янган сул күзе урынында бары тик кара сызык кына калган. Ничек шулкадәр кансыз булырга мөмкин. Мәүлитнең бу кадәр кызганыч кыяфәтен күргәч, йөрәгемә кан сауды, сулышым кысылды. Этеп егу гына аз булган ул юньсезгә, әттәхиятен әйттерәсе калган.

Моның ише хәлдә калганым булмагач, башта аптырап тордым: ни эшләргә? Әлбәттә врачка, Мария Ивановна янына барырга кирәк. Ләкин бу турыда әйткән идем, Мәүлит кырт кисте:

– Тажи, әгәр дус итсәң, нәрсә булганын беркемгә дә әйтмә. Син белмәдең, күрмәдең... Бармыйм мин Мария Ивановна янына. Сорасалар, егылып, ботакка төртелдем диярмен.

– Ә Эдик?..

– Куркак ул, авыз да ачмас.

# ТЕЛНЕ ҖЫР ДА ЯШӘТӘ

**Милли җыр сәхнәбездә Гөлназ Гафурова тыйнаклыгы, зәвыгы, бай репертуары, чын татарча образы белән аерылып тора. Хит-парадларда беренче урыннарда тормаса да, сәхнә тутырып ялтыраган түш-ботлардан, көйсез замана такмакларыннан соң аның мөнәҗәтләре, дини эчтәлекле, классик әсәрләрне җиренә җиткереп башкаруы, ире җырчы Вәли белән бергә яңгыраткан мәхәббәт җырлары күңелгә шифалы бәлзәм кебек тәэсир итә.**

Гөлназ – Түбән Кама кызы, тугызынчы сыйныфтан соң Казанга килеп, музыка көллиятенә укырга керә, Ания Туишева классында вокал серләренә төшенә. Аны тәмамлагач, сәнгать институтының театр факультетында һәм консерваториядә параллель рәвештә укый башлый. Театр сәнгате дә, музыка да җанына якын булуга карамастан, кыз беренче курсны укыгач, театр бүлегеннән китә. Югыйсә, Камал театры директоры Шамил Закиров аның татарның беренче театры сәхнәсендә Мәйсәрәне уйнавын күрергә теләгән булган. Бикчәнтәев курсыннан китеп баргач, кызга үпкәләп тә йөргән әле. «Ярты ел көтәбез, уйла», – диләр җырчы кызга. Тик сәхнәдә репетиция вакытында алган җәрәхәтнең дә тәэсире булгандыр, ул җыр юлыннан китәргә карар кыла. Консерваториядә Зилә Сөнгатуллина классында белем алып, аны кызыл дипломга тәмамлый. Остазларымнан бәхетем булды, дип саный ул.

Укыган чакта ук, Гөлназ җырчы егет Вәлигә кияүгә чыгып куя. Алар музыка көллиятендә бергә укый, Вәли – ул чакта бик популяр булган «Казан егетләре» төркеме солисты, колледж кызларының йөрәкләрен әрнетеп, мачо булып йөри. Тик тыйнак, моңлы тавышлы Гөлназга гашыйк булуын сизми дә кала. Дүрт ел дуслашып йөргәннән соң, яшьләр гаилә корып җибәрә. Кияүгә чыкканда, кызга – 19, кияүгә исә 21 яшь була. Шул көннән соң Гөлназ өчен гаилә беренче урынга чыга. Дәү әниләренең тәүфыйк теләп кылган догалары кабул булганмы, җырчы ханым акрынлап динебез кушканча яшәү юлына баса. Сәхнә киемнәре дә үзгәрә, репертуарда мөнәҗәтләр, нәшидләр барлыкка килә. Дуэт буларак та җырлар яздыралар. Ләкин Гөлназ популярлык артыннан куып, гастрольләрдә йөреп, гаиләгә дигән вакытын корбан итмәскә була. «Эштән курыкмыйбыз, – ди Гөлназ, – тик балалар, гаилә беренче урында булсын, дибез».

Артистлар гаиләсендә бүген ике бала – 14 яшьлек Мөхәммәт белән 9 яшьлек Җәннәт үсеп килә. Кыз бала бию, җыр, театр сәнгате белән шөгыльләнә. Мөхәммәт музыка мәктәбенең фортепиано сыйныфын тәмамлый. Техникага да һәвәс егет, кораблар конструкцияләү белән мавыга, аңа үз хуҗалыкларында остаханә дә көйләп биргәннәр (гаилә үз йорты белән яши).

Беренче альбомын 19 яшендә чыгарган Гөлназ озак еллар Казан шәһәр филармониясе солисты булып эшли. Үзенең белем-тәҗрибәсен сандыкта яткырмый: филармониянең балалар вокаль ансамблен җитәкли. Төрле мәдәни чараларда күз явын алырлык чыгышлары белән күңелгә кереп калган коллективка Гөлназның күпме көче, җан җылысы салынганы ачык күренә. Ансамбльгә балаларны кастинг юлы белән җыялар. Бу ансамльгә башкару осталыгы, репертуар ягыннан да, костюмнары җәһәтеннән дә тел-теш тидерерлек түгел, сыйфатлы рухи азык бирүче, балаларны сәнгать дөньясына әзерләүче энҗе бөртегедәй коллектив! Репертуарларында эстрада һәм халык җырларыннан тыш, мөнәҗәтләр, нәшидләр, дини эчтәлекле җырлар да бар. Балалар аеруча «Әлвидаг», «Бисмилләһ дип башлыймын» кебек рухи эчтәлекле җырларны яратып җырлый икән. «Балалар дөньяга пакь күңел белән, иман белән туа. Без, әти-әниләр, остазлар ул күңелгә күркәм, әхлакый кыйммәтле, гүзәл нигъмәтләр генә салсак иде», – ди Гөлназ.

Гөлназ өйрәткән ул җырлар да балалар күңеленә иман орлыклары булып төшәдер. Әти-әниләр балаларына шул яклап та тәрбия биргәнгә бик рәхмәтле. Балалар филармониясе ансамбле республика күләмендәге зур чараларда еш чыгыш ясый. Аларны «Шаян ТВ» телеканалында да күрәбез. Бу балалар әлеге каналдагы мультфильмнарны татарча тавышландыру белән дә шөгыльләнә. Бу шөгыль үзләренә дә ошый. Мәктәпләрдә татар теле дәресләре юкка чыгу дәрәҗәсендә кыскартылгач, туган телне саклый торган мондый коллективларның кыйммәте тагын да артты. Тиз арада татарчаны өйрәнү шарты белән, ансамбльгә туган телебезне бөтенләй белмәгән балаларны да кабул иткәннәр. Алар татар телен аерым укытучыларга йөреп өйрәнгән, ансамбльдә татарча җырларлык дәрәҗәгә җиткәннәр. Гөлназ үзе Түбән Кама шәһәрендәге 2 нче татар гимназиясендә белем алган. «Туган телебез яшәсен өчен, балалар үз телебездә сөйләшсен өчен аның чолганышы мөһим, – дип саный ул. – Ә гаиләдә телне саклап кына була, тел үссен өчен ул мәгарифтә, фәндә, сәнгатьтә дә кулланылырга тиеш…»

Гөлназ – интернет челтәрендә танылып килгән «Салаватиклар» проектының да остазы. Хәзерге балалар телләре ачылмас, тәпи китмәс борын ук интернет дөньясына чума. Ләкин андагы бөтен кызыклар – мультиклар, видеолар урысча. Кечкенә балага тәкъдим итәрдәй татарча видеолар, җырлар, мультиклар юк дәрәҗәсендә аз. «Салаватиклар» проекты менә шул бушлыкны тутыру өчен уйлап табылган. Утыздан артык бала Гөлназ җитәкчелегендә балалар өчен татарча музыкаль контент – җырлар, клиплар булдыру белән шөгыльләнә. Гөлназ үзе дә балалары кечкенә чакта аларга күрсәтерлек татарча клиплар, видеолар булмауга эче пошып, шулар хакында хыялланып йөргән. «Сабантуй» балалар журналы мөхәррире Зилә Хөснетдинова белән очрашканнан соң, бу хыялны чынга ашыру эшенә тотынганнар. «Салаватиклар» инде өченче концертларын куярга өлгерде. Җырлар аркылы балалар татарчага өйрәнә. Гөлназ балаларны җырларга өйрәтсә, хореограф бию дәресләре бирә, ә интернет өчен клипларны тулы бер команда әзерли. Русча гына сөйләшүче балалар да «Салаватиклар» җырларына кушылып бии һәм балалар ун гына татарча җырны өйрәнә икән, димәк, бу хезмәт бушка китми дигән сүз. Өч ел эчендә «Салаватиклар»ның беренче составы чыгып китәргә дә өлгергән, алар урынына яңа балаларны җыйганнар.

Балалар белән эшләүдән тыш, Гөлназ «Чулпан» мәдәният үзәгендә куелган музыкаль спектакльләрдә дә уйный. Камал сәхнәсендә уйный алмый калган Мәйсәрә ролендә ул инде монда әллә ничә еллар тамашачы каршына чыга. Быел «Зәңгәр шәл»не тагын да баетып, яңартып куйганнар. Тамашачы челтерәп торган тавышлы бу гүзәл җырчы-актрисаның уеныннан, һичшиксез, ләззәт алгандыр. Шәкертләре арасыннан исә «Гөлҗамал»ларны, «Бөдрә таллар»ны, «Тәфтиләү»не остаз апаларының үзе кебек күңелләргә үтәрлек итеп җырлаячак егет-кызлар үсеп чыгар әле.

**Эльмира СИРАҖИ.**

# МӘСКӘҮ ТАТАРЛАРЫ ЯНЫНДА

● Мәскәү мэры Ю.Лужковның Әсәдуллаев йортын татарларга кайтарып бирү тантанасы.

**(Ахыры. Башы 2 нче биттә).**

Ярар, сүзебез тоташ яманлауга охшап калмасын дип, үзебезнең сәяхәт максатына кайтыйк. Беребезнең дә Җәлил исемен йөрткән һәм «татарныкы» дигән данны алган мәктәпне күргәне юк иде, без шуңа юл тоттык. Иркен генә мәйданга урнашкан уку йорты, ләкин аны да һәр тарафтан 12-16 шар катлы торак йортлар урап алган инде. Мәктәпнең «татарныкы» дигән язуы юк, ләкин капка аша атлап керүгә үк Җәлил хөрмәтенә куелган һәйкәл каршы ала. Мәктәптә 600 гә якын бала укый. Бөтендөнья мәдәниятенә, газиз Татарстаныбызга, каһарман җәлилчеләргә, хәтта күренекле разведчиклар, шул исәптән татар халкының асыл егетләре Исхак Әхмәровка, Бибиирин белән Шамил Хәмзиннарга багышланган дүрт музей булдырылган. Мәктәптә барлыгы 32 милләт вәкиле белем ала, әмма татар балаларының саны 70 кенә. Мәскәүнең ераграк районыннан балаларны махсус машина яллап китерсәң дә, бер якка гына юл да ике сәгать ярым вакыт били, ә мәркәз кешеләренә күпертелгән хезмәт хакы түләнсә дә, алар көненә бишәр сәгатькә такси яки аерым машина яллый алмый инде. Шуңа күрә халык арасында «татарныкы» дип аталса да, асылда әлеге статусны яклап бетерә алмый.

Гәрчә менә шушында белдек: мәркәздәге мөгаллимнәрнең иң түбән класслысы да аена 84 мең, югары квалификациялеләре 125 мең тәңкә күләмендә хезмәт хакы ала, ошбу каладагы кунакханәләргә йөк ташучы, урам себерүче булып ярты ставкага ялланган ирләргә дә 50 шәр мең тәңкә акча түләнә икән ләбаса. Ә без, томаналар, ил казнасының 90 проценты нишләп монда гына утырып кала да, ник бирәдә бордюр алыштыру өчен генә дә елына икешәр миллиард сум акчаны түгүләре өчен забастовка, ризасызлык белдерүчеләр юк, дип гел-гел баш ватабыз...

Җәлил мәктәбенең директоры Роза Шакирова белән ул вакытта Мәскәү татар автономиясенең җитәкчесе булган генерал-полковник Рәсим Акчурин 2000 елларда Чаллы каласындагы Сабантуйларга килеп йөри, үзебез дә берничә ел рәттән Мәскәү Сабан туен уздырышырга дип барган идек, Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова белән янәшә утырып, көймәле арбаларда мәйдан әйләнүләр бүгенгәчә истә. Күптәннән таныш Роза ханым да мәктәпләрдә татар теленең атнасына ике сәгать кенә итеп калдырылуына һич тә риза түгел. Мәскәү татарлары арасында да газиз теленә тугры гаиләләр бик күп. Әминә Арсланова атлы бер кыз ике ел буена икешәр сәгатьлек юл узып, Мәскәү янәшәсендәге Щелково каласыннан ук килеп йөргән. Рушан хәзрәт Аббясов, өч баласын да татар мәктәбенә йөртү өчен, хәтта күрше йорттан аерым фатир сатып алырга да мәҗбүр булган. Әмма кызганычка, һәрбер татар гаиләсе дә андый чыгымнарны күтәрә алмый, хакимиятияләре Мәскәүнең һәрбер округында берәр булса да татар мәктәбе ачып куйса, безнең газиз телебез дә бик тиз үлмәс иде. Ни әйтсәң дә, бер сүз, бер нәтиҗә: Мәскәү хакимнәренә татар, башкорт, чуаш, якут, ингуш, чечен телләре гел кирәкми, безнең ирләр окоп-траншеяларга озатылган чагында гына кадерле шул...

Мәктәптән соң мәркәздәге атаклы Әсәдуллаев йортына җыелган чагында да төп сүзебез татар кадере һәм туган телебез тирәсендә барды. Зыялыларга мәгълүм: әлеге йортны татар милләтенә кайтарып бирү өчен көрәш еллар буена сузылды. Югыйсә, әлеге мәдәни үзәкне сәүдәгәр Әсәдуллаев әле XIX гасырда ук татар зыялыларына бүләк иткән. Бу йортта 1917 елның 1-2 маенда Бөтенроссия мөселманнарының I корылтае шаулап узган. Йорт диварлары милләт данына әверелгән Галимҗан Баруди, Гаяз Исхакый, Садри Максуди, Һади Атласи, Галимҗан Ибраһимов, Мөхлисә Буби һәм тагын йөзәрләгән милләтпәрвәр татар рухын саклый. Бирәдә инкыйлабтан соң Муса Җәлил, Сара Садыйкова, Газиз Айдарский (Вәлитов), янә дистәләгән талант хезмәт куйган. Ләкин Сталин заманында йортны татар кулыннан тартып алганнар да, ул чит-ят кубызында, эт типкесендә йөргән. Ниһаять, 2007 елда Мәскәү мэры Юрий Лужков аны кабат татар милләтенә кайтарып бирде. Ул тантана түрендә Президентыбыз М.Шәймиев, милли автономия рәисе Р.Акчурин, вәкаләтле вәкилебез Н.Мириханов, Мәскәү мөфтие Равил хәзрәт Гайнетдин сәхнә түрендә утырды. Ю.Лужков шул вакытта: «Мәскәү каласында яшәүче татарларның саны 750 мең кешедән дә артып китә», – дигән тарихи хакыйкатьне ярып салды. Әмма 15 ел вакыт узуга инде Мәскәү татарларының санын кәгазьләрдә 84 мең тирәсенә генә калдырдылар, бер Мәскәүнең үзендә генә дә 700 мең татар «йотылып юкка чыкты».

Татар милләтенә карата мондый типкелекле сәясәт һәр тарафта сизелә. Әсәдуллаев йорты элек «Татар бистәсе» дип аталган район үзәгендә калкып чыккан. Ә 1816 елда ук бирәдә тәүге Татар мәчете төзелеп куйган инде. Әлеге мәчет һәм, гомумән, Мәскәү өлкәсендә яшәүче мөселманнар ахуны булып торган Хәйретдин Агеев йорты да фотосурәтләрдә сакланып калган. Әмма утызынчы елларда Әсәдуллаев йортында эшләп килгән театрны, әдәби журнал һәм түгәрәкләрне куып таратканнар, шәһәр буенча гомумсаны белән дүрткә җиткән татар мәктәпләре ябылган. Алтмышынчы еллар җиткәч, тирә-ягына «үтә күркәм хрущевкалар» төзеп, мәчет булып мәчетне дә «халык» күзеннән яшерә башлаганнар. Сиксәненче елларда бер якта озын вә биек заманча йорт төзеп, мәчетне генә түгел, Әсәдуллаев йортын да нурлы кояш күзеннән каплаганнар. Әлеге йорт «Иван Васильевич һөнәр алыштыра» атлы комедия төшерелү уңаеннан кадерле кадерлесен, әмма ул Әсәдуллаев йортына керә алырдай барча юлны каплаган, томалаган. Новокузнецк урамына куелган Тукай һәйкәленә чәчәкләр салу өчен дә кунаклар әлеге «тарихи» йорт аркасы аша йөрергә мәҗбүр хәзер...

Әсәдуллаев йортында ике мәртәбә очрашу, түгәрәк өстәл узды. Тема бер үк: милли оешмалар арасындагы тынмас каршылыклар һәм җанисәп нәтиҗәләренә мөнәсәбәт. Икенче көнге очрашуга милли оешма җитәкчеләре, күренекле зыялылар да чакырылган иде. Муса Җәлил кызы Чулпан ханым, академик Илдар Үтәмешев, «Татарларның һәм төрки халыкларның милли конгрессы» дип аталган оешма башлыгы Рөстәм Ямалиев, Татарстанның элеккеге вәкаләтле вәкиле Назиф Мириханов, күренекле язучыбыз Ринат Мөхәммәдиев һ.б. күп кенә таныш милләттәшләр килде. Күңел элеккеге танышларымнан генерал Рәсим Акчурин, академик Роберт Нигъмәтуллин кебек атаклы шәхесләр белән очрашуга өмет иткән иде дә, алар баш тарткан, ди. Сәбәпләре тиздән ачыкланды. Милли оешмалар арасында җитди каршылык, күптән кабынган утлы низаглар бар. Әйтик, Наилә Җиһаншина атлы рәссам Әсәдуллаев йортында үзенә аерым бүлмә бирелмәвенә ризасызлык белдерә. Шулай ук Мәскәү тирәсендәге әллә ничә шәһәрнең милли автономияләре дә аерым-аерым бүлмә таләп итә икән. Тагын кемдер сәүдәгәр Салих Ерзин 1904 елда Мәскәү уртасында төзеткән «гаҗәеп» мәчетне җимереп ташлаулары һәм аның

● Әсәдуллаев йортында беренче очрашу истәлеге.

# Мосафир сәфәрдән кайтты

● Без мөфти Равил хәзрәт Гайнетдин янында.

● Без Татарстан вәкиллеге йортында Р.Әхмәтшин белән.

урынына өр-яңа һәм мәһабәт җәмигъ мәчет калкытып куюлары белән дә әллә ничә ел буена ризалаша алмый. Күпләр Мәскәү шәһәрендәге милли автономия рәисе Фәрит Фәрисовны бинага хуҗа булып алуда һәм автократ ысул белән җитәкчелек итүдә гаепли, тагын әллә ниләр...

Ирексездән, әле 1709 елның гыйнвар аенда ук Казан каласына беренче губернатор булып килеп төшкән генерал Петр Апраксинның абыйсы, фельдмаршал Федор Апраксинга язган хатыннан бер гыйбрәтле өзек хәтердә яңара:

«Татар белән башкорт халкы, Дон яисә Җаек казаклары шикелле, бер генә атаман сайлап куя һәм аңа гына буйсынып яши белми. Шуңа күрә аларны яуларда тар-мар итү дә, куып тарату да җиңел».

Өч йөз елдан артык гомер үтеп киткән, ә Апраксин сүзләрен һич тә алыштырмыйча, бүгенге татар-башкорт халкына карата да кулланырга мөмкин. Ни сәбәпле шушы кадәр башбаштак һәм нишләп әле дә булса бер-беребезгә юл куеп, кулга-кул тотынып яши белми торган гаҗәеп кавем соң без?!.

Уйланырлык нигез, чыннан да, чиктән артып киткән. Әсәдуллаев йортында бүлмәләр күп, анда Мәскәү өлкәсенең автономия рәисе Могътәсаровка гына аерым бер почмак табып булыр иде. Мәскәү янәшәсендәге шәһәрләрнең һәркайсында диярлек милли оешмалар, иҗат берлекләре оешкан. Аерым график төзеп, һәр ай саен бер шәһәр оешмасын Әсәдуллаев йортына чакыру, аларның иҗат хисаплары шикеллерәк концерт яисә кичә оештыру да фәкать бердәмлеккә генә хезмәт итә. Аннары Мәскәү тирәсендәге калаларда яшәп иҗат итүче татар рәссамнарының кул вә күңел эшләрен Татарстан хөкүмәте һәр ел саен уздыра торган Мәдәният көннәрендә дә күргәнебез бар, шул ук эшләрдән елына ике-өч мәртәбә Әсәдуллаев йортында да күргәзмәләр оештыру, Казан каласындагы Рәссамнар берлегеннән белгечләр чакырып, үзара бәя бирү һәм ясалган эшләрне камилләштерү буенча да күчмә мәктәп уздырырга мөмкин. Шул ук Наилә ханым эшләреннән күргәзмә оештыру, ачык дәресләр үткәрү фәкать татар сәнгатен үстерүгә генә хезмәт итә. Элеккерәк елларда атаклы язучыбыз Айдар Хәлимне чакырып, шушы ук Әсәдуллаев йортында аның белән очрашулар уздыралар иде, шундый ук гамәлне хәзер дә кабатлап булмыймыни? Татар әдибе – Татарстанныкы гына түгел, чөнки безнең милләт барча Россия буенча таралган бит, димәк, аларны бөтен ил буенча таныту да – гомуммилләт эше. Ә Мәскәү автономиясе ни өчен үз кабыгына гына бикләнеп яши, ник булган милли байлыкны арттыру турында баш ватмый – һичкемгә аңлашылмый...

Генерал П.Апраксин сүзләре җәмигъ мәчеткә, Бөтенроссия мөфтиләр шурасы рәисе Равил хәзрәт Гайнетдин белән очрашуга баргач, янә хәтердә яңарды. Мәскәүдәге бер-ике «зыялы» зат мөфтине мәркәздә С.Ерзин төзеткән мәчетне җимереп ташлауда гаепли. Ул мәчет төшерелгән фотоны кулыбызга алдык, аннары бөҗрадай баскычлар буенча атлый-атлый, яңа җәмигъ мәчетнең алтынчы катына да мендек. Гафу итегез инде, элек Чыңгызхан, Туктамыш яисә Олуг Мөхәммәт ханнар күченеп йөргәндә, берәр җирдә туктап намаз укыган тирмәләрне йә булмаса агач мәчетләрне бүгенге мәрмәр сарайлар, заманча колач белән янәшә куеп карау дөрес гамәлмени? Равил хәзрәт ничәмә-ничә еллар буе йөз суын түгеп йөри-йөри, ил башлыкларыннан яңа мәчет төзүгә рөхсәт алган. Аннары шул ук Равил хәзрәт, янә йөз суын түгә-түгә, Согыд Гарәбстаны, Гарәп Әмирлекләре, Төркия кебек ил башлыкларыннан мәчетне аякка бастыру өчен ярдәм итүләренә дә ирешкән. Шул ук кешеләр үзләре үк, үз күзләре белән ел саен күреп тора: дини бәйрәм саен җәмигъ мәчеткә йөз меңләгән мөселман җыела, ә алты катлы итеп төзелгән затлы мәчет тә үз диварлары эченә нибары 20-30 мең чамасы гына диндарны сыйдыра ала. Үз диненә хыянәт итмәгән башка диндарлар кар яисә яңгыр явып торган чагында да догаларын мәчет тышында, койма артына сузылган тыкрыкларда укып чыгарга мәҗбүр. Моңа Равил хәзрәт түгел, ә мәркәздә тупланган алты миллион мөселман өчен нибары дүрт мәчет төзергә рөхсәт биргән ил башлыклары, безнең муеннарга тавык тәпие тагу хакында хыялланган карагруһчы кавем гаепле бит...

Без җәмигъ мәчет буенча сәяхәт кыла-кыла, аның затлылыгына сокланып туя алмадык. Һәр диварда мәрмәр, түшәмнәрдә хрусталь люстралар, идәннәрдә келәм. Ирләр һәм хатын-кызлар өчен аерым намаз заллары, тәһарәт алу һәм вафат булганнарга җеназа уку бүлмәләре. Иркенлек һәм хөрлек. Намаз укырга дип кергән гади узгынчыдан сәдака салу яки шәм куюны таләп иткән һичбер каратун юк. Равил хәзрәт бәйрәмнәрдә намаз-вәгазьләрне әүвәл газиз татар телебездә, аннары инде рус теленә күчеп тә укырга мәҗбүр. Сәбәбе бик гади, без кырык җирдә белештек: Мәскәү каласында бүген бер миллион кыргыз һәм бер миллион таҗик гастарбайтер булып хезмәт итә, әле аларга кадәр үк килеп «төпләнгән» азәри яки чечен-ингуш-даһ сәүдәгәрләренең саны да өч миллион чамасы исәпләнә. Аларның байтагы үзләренә аерым мәчет таләп итә, кәнәфиләр даулый, ә Равил хәзрәтебез, Ходайга мең шөкер, имам итеп һаман үз милләтенең вәкилләрен тота.

Равил хәзрәтнең һәр гамәлен шәһәр хакимияте яисә рус чиркәве дә хуплап тора икән, дип уйлап, берүк ялгышмагыз. Мөфтиебез 2015 елда җәмигъ мәчетне ачу тантанасын үткәрүгә үк, аның гүзәллеген бер ягына әллә ничә катлы торак йорт торгызып каплаганнар. Хәзер икенче ягында, мөфти офисыннан ун адымда ук Олимпия үзәге төзи башлап, икенче яклап та богау кидерәләр. Хакимият дини бәйрәмнәрдә дистәләгән мең мөселманның тыкрыкларга тезләнеп дога кылырга мәҗбүр булуын яттан белә, ә карагруһчылар хәтта шушы җәмигъ мәчетне дә һәрбер яклап бетон коймалар белән төрүен дәвам итә, изге дингә тугрылык саклаучыларга киртә сала...

Равил хәзрәт безгә гаҗәеп бер вакыйга турында бәян итте. 1926 елда Мәдинә каласында Бөтендөнья мөселманнарының I корылтаен уздырган чагында безнең ил вәкиле булып, аның гыйлемлеген һәм бөеклеген бүгенгәчә бәяләп бетерә алмаган Риза хәзрәт Фәхретдин дә барган. Шунда хаҗ кылырга дип килгән мөселманнарның Кәгъбә ташы тирәсендә дә, дивар буйларына тезелеп тә дүрт якка намаз кылуын күреп, Риза хәзрәт: «Безнең кыйблабыз да, Аллаһ Тәгалә үзе дә бер генә бит, без нишләп бер тарафка карап кына дога кылмыйбыз соң?» – дип ярып салган. Аны башка илләрнең мөфти-шәехләре дә хуплаган һәм шуннан бирле хаҗ кылганда сәҗдә кылулар да, намаз укулар да кыйбла ягына карап кына үткәрелә башлаган. Ягъни татар галиме, татар мөфтие изге Мәккә, изге Мәдинә туфрагына, изге мөселман диненә дә менә шулай итеп зур яңарту керткән!..

Равил хәзрәт Бөек Болгар дәүләте Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын бәйрәм итү өчен дә әле 2016 елда ук ил башлыгы В.Путин янына керә һәм аның исеменнән махсус фәрман чыгартуга ирешә. Без Равил хәзрәтнең искиткеч укымышлы, зыялы һәм эчкерсез булуына хәйран калып чыктык. Һәм аның ихлас намазлары, 37 ел буе дәвам иткән мөфтилек хезмәте өчен генә түгел, мәркәз үзәгендәге шушы җәмигъ мәчетне төзетә, Ислам дине кабул ителүнең 1100 еллык тантанасын Россия күләмендә бәйрәм итә алуыбыз өчен дә аның каршында мәңге бурычлыдыр. Аллаһ Тәгаләбез мондый мөфтине дә, мөселман өммәтен дә ярдәменнән генә ташламасын!

**Вахит ИМАМОВ.**
Автор фотолары.

● Татар бистәсендәге мәчетнең элекке күренеше.

● Мәскәүдә С.Ерзин 1904 елда төзеткән икенче мәчет фотосы.


● Яңа мәчет бинасы.

# ҖАНИСӘПКӘ КҮЗӘТҮ:

**Җанисәп анкеталары тутырганда «Өй ничек җылытыла?», «Су кергәнме?», «Өйдә канализация, бәдрәф, җылы су бармы?», «Чүп кая чыгарыла?» кебек сорауларга гаҗәпләнгән идем. XXI гасырда алар урынсыз тоелды. Росстат сайтына куелган җанисәп нәтиҗәләре белән танышкач, тагын да ныграк гаҗәпләндем. Әмма бу сораулар юкка бирелмәгән, XXI гасырда да бөек державабызда цивилизация уңайлыкларыннан мәхрүм кешеләр бик күп икән әле. 2010 елда колонкадан су ташучылар, бәдрәфкә урамга йөрүчеләр, мичкә ягып өй җылытучылар, чүпне өй янындагы чокырга, күчкә, ә табак-савыт юган суны «тирескә» түгүчеләр саны берничә мәртәбә күбрәк булган.**

Фикерләрне саннар белән дәлиллик. 2010 елда Россиядә 52,8 млн торак исәпләнгән. Моңа шәхси йортлар да, шәһәрдәге фатирлар да, тулай тораклардагы аерым бүлмәләр дә керә. 11 ел элек 52,8 млн торакның 12,3 миллионында яшәгәннәр бәдрәфкә урамга йөргән. Хәзер андый торак саны бермә-бер кимеп, 6,7 миллионга калган. Яңа җанисәптә гомуми торак саны 64 миллионга җиткән. 11 ел элек россиялеләрнең якынча биштән бере урамдагы бәдрәфкә йөргән булса, хәзер – уннан бере. Прогресс хәттин. Дистә ел элек чүпне чокырга яки күчкә якынча 10 млн йорттан чыгарган булсалар, хәзер андый йортлар саны 8 тапкырга кимегән – 1,3 млн калган. Димәк, Россиядә чүп түгүне 10 ел эчендә тәртипкә салып бетерә язганнар. Киләсе җанисәптә бу сорау булмастыр, мөгаен.

Канализациясе булмаган йортлар саны 10 ел эчендә 3 тапкырга кимеп, 2,7 млн калган. 2010 елда суны колонкадан 3,5 млн йортка ташыган булсалар, 2021 елда – 1,4 млн йортка. Сусыз йортлар 2,5 тапкырга кимегән. Мичкә ягып җылытыла торган йортлар саны әллә ни кимемәгән: 2010 елда – 7,7 млн, ә 2021 елда – 5 млн булган. Россия Европаны, Кытайны, Японияне газ белән тәэмин итә: елына якынча 200 млрд куб м. газ сата.

Халыкның яшәү шартлары ике җанисәп арасында сизелерлек яхшырса да, аерым төбәкләрдә вәзгыять мактанырлык түгел. «Интертат» хәбәрчесе унышар иң яхшы һәм иң начар төбәкләрне барлап чыкты. Рейтингка Мәскәү, Санкт-Петербург һәм Севастополь шәһәрләре кермәде, чөнки алар үзләре аерым субъект, аерым шәһәрне авыллары булган төбәкләр белән чагыштыру урынсыз.

### БӘДРӘФЕ ЧИТТӘ БУЛГАН ТОРАКЛАР САНЫ

| Төбәк | Торак саны, 2021 ел | Бәдрәф йорттан читтә, 2021 ел | Бәдрәф йорттан читтә, 2021 ел, % |
|---|---|---|---|
| Мурманск өлкәсе | 313377 | 1019 | 0,3% |
| Мәскәү өлкәсе | 3975160 | 56017 | 1,4% |
| Чукотка автоном округы | 19805 | 285 | 1,4% |
| Камчатка крае | 134609 | 2075 | 1,5% |
| ЯНАО | 197454 | 3082 | 1,6% |
| Магадан өлкәсе | 66181 | 1061 | 1,6% |
| Сахалин өлкәсе | 217999 | 5624 | 2,6% |
| ХМАО | 665551 | 17593 | 2,6% |
| Ненец автоном округы | 16545 | 475 | 2,9% |
| Калининград өлкәсе | 448060 | 14085 | 3,1% |
| *** | *** | *** | *** |
| Карачай-Черкес Республикасы | 143477 | 35491 | 24,7% |
| Курган өлкәсе | 360391 | 96831 | 26,9% |
| Ингуш Республикасы | 87676 | 26825 | 30,6% |
| Дагстан Республикасы | 826480 | 266827 | 32,3% |
| Калмык Республикасы | 94472 | 32914 | 34,8% |
| Бурят Республикасы | 364331 | 132064 | 36,2% |
| Байкал аръягы | 396228 | 150410 | 38% |
| Чечня Республикасы | 313613 | 153596 | 49% |
| Алтай Республикасы | 76754 | 40273 | 52% |
| Тыва Республикасы | 98586 | 59839 | 60,7% |

Бәдрәфе читтә булган тораклар саны буенча Кавказ төбәкләре дә антилидерлар рәтенә кергән. Аларда бәдрәфнең читтә булуы дини һәм милли традицияләр белән бәйле. Аларда йомыш үти торган урын өй эчендә булмаса да, гадәттә, уңайлыгы буенча өй эчендәгеләрдән ким түгел. Мәсәлән, Чечня, Ингушетиядә болай да салкын түгел, бәдрәф тә җылытыла, җылы суы, комганы куела.

Татарстанда 169 мең торакның, яки барлык торакның 10,2 процентының бәдрәфе читтә. Башкортстанда 376 мең йортта яки 22,4 процентында бәдрәф читтә. Икенче төрле әйткәндә, Татарстанда һәр унынчы йорт хуҗасының, ә Башкортстанда һәр бишенченең өй эчендә унитазы юк.

Татарстанда барлыгы 1 млн 654 мең, ә Башкортстанда 1 млн 676 мең торак исәпләнә. Аерма әллә ни зур булмагач, ике төбәкне чагыштыру кызыклы.

### СУ КЕРМӘГӘН ЙОРТЛАР. СУНЫ КОЛОНКАДАН ТАШЫЙЛАР

| Төбәк | Торак саны, 2021 ел | Су кермәгән йортлар, 2021 ел | Су кермәгән йортлар, 2021 ел, % |
|---|---|---|---|
| Мәскәү өлкәсе | 3975160 | 7957 | 0,2% |
| Мурманск өлкәсе | 313377 | 710 | 0,2% |
| Магадан өлкәсе | 66181 | 169 | 0,3% |
| Калининград өлкәсе | 448060 | 1454 | 0,3% |
| Камчатка крае | 134609 | 573 | 0,4% |
| Кабарда-Балкар Республикасы | 249352 | 1220 | 0,5% |
| ЯНАО | 197454 | 1028 | 0,5% |
| Төньяк Осетия-Алания Республикасы | 235490 | 1228 | 0,5% |
| Чукотка автоном округы | 19805 | 142 | 0,7% |
| ХМАО | 665551 | 4895 | 0,7% |
| *** | *** | *** | *** |
| Омск өлкәсе | 813734 | 49932 | 6,1% |
| Архангельск өлкәсе | 444074 | 27280 | 6,1% |
| Иркутск өлкәсе | 1039272 | 80950 | 7,8% |
| Амур өлкәсе | 340646 | 28102 | 8,2% |
| Ненец автоном округы | 16545 | 1708 | 10,3% |
| Яһүд автоном өлкәсе | 66815 | 7312 | 10,9% |
| Бурят Республикасы | 364331 | 43146 | 11,8% |
| Байкал аръягы | 396228 | 50049 | 12,6% |
| Алтай Республикасы | 76754 | 10649 | 13,9% |
| Тыва Республикасы | 98586 | 14908 | 15,1% |

Өйгә су кертү өчен бөтен мөмкинлекләр булган заманда кайбер төбәкләрдә халыкның уннан бере, Бурятия, Алтай, Тыва республикаларында, Байкал аръягы краенда аннан да күбесе колонкадан су ташу кызгану хисе уята. Татарстанда 15 мең йортка (0,9 процент) суны колонкадан ташыйлар.

Республикабыз әлеге күрсәткеч буенча яхшы төбәкләр рәтендә. Башкортстанда су кермәгән йортлар 58 меңгә якын (3,4 процент).

### МИЧКӘ ЯГЫП ҖЫЛЫТЫЛА ТОРГАН ЙОРТЛАР

| Төбәк | Торак саны, 2021 ел | Мичкә ягып җылытыла торган йортлар, 2021 ел | Мичкә ягып җылытыла торган йортлар, 2021 ел, % |
|---|---|---|---|
| Мурманск өлкәсе | 313377 | 1441 | 0,5% |
| ЯНАО | 197454 | 1369 | 0,7 |
| Татарстан Республикасы | 1653954 | 13657 | 0,8% |
| Кабарда-Балкар Республикасы | 249352 | 2431 | 1% |
| Белгород өлкәсе | 649081 | 8981 | 1,4% |
| Самара өлкәсе | 1486603 | 20668 | 1,4% |
| Мәскәү өлкәсе | 3975160 | 57024 | 1,4% |
| Магадан өлкәсе | 66181 | 1401 | 2,1% |
| Төньяк Осетия-Алания Республикасы | 235490 | 4987 | 2,1% |
| Саратов өлкәсе | 1111785 | 24034 | 2,2% |
| *** | *** | *** | *** |
| Курган өлкәсе | 360391 | 82185 | 22,8% |
| Амур өлкәсе | 340646 | 81424 | 23,9% |
| Киров өлкәсе | 544354 | 132973 | 24,4% |
| Хакас Республикасы | 227402 | 56643 | 24,9% |
| Яһүд автоном өлкәсе | 66815 | 17161 | 25,7% |
| Псков өлкәсе | 284517 | 85081 | 29,9% |
| Байкал аръягы | 396228 | 150250 | 37,9% |
| Бурят Республикасы | 364331 | 152185 | 41,8% |
| Алтай Республикасы | 76754 | 35327 | 46% |
| Тыва Республикасы | 98586 | 63067 | 64% |

2021 елда Омск өлкәсенә баргач, Тара шәһәрендәге йортлар утын ягып җылытылуы турында гаҗәпләнеп язган идем, җирле татарларның үпкәләре килеп иреште. «Ярты Себер утын якса да, бер безне ямьсез итеп күрсәттең», – диде милләттәшләр. Татарстанда мичкә утын ягучылар 0,8 процент кына булгач, тулы бер шәһәрнең утын, күмер ягуы чыннан да гаҗәпләндергән иде. Себернең яртысы ук утын якмаса да, Себер федераль округында андыйларның өлеше 19 процентка житә. Башкортстанда мичкә ягылып җылытыла торган торакның өлеше 7 процент, ә Россиядә 8 процент тәшкил итә.

### КАНАЛИЗАЦИЯ БУЛМАГАН ТОРАК САНЫ

| Төбәк | Торак саны, 2021 ел | Канализация булмаган йортлар, 2021 ел | Канализация булмаган йортлар, 2021 ел, % |
|---|---|---|---|
| Мурманск өлкәсе | 313377 | 982 | 0,3% |
| Төньяк Осетия-Алания Республикасы | 235490 | 1057 | 0,4% |
| Мәскәү өлкәсе | 3975160 | 24619 | 0,6% |
| Кабарда-Балкар Республикасы | 249352 | 1880 | 0,8% |
| Ингуш Республикасы | 87676 | 705 | 0,8 |
| Калининград өлкәсе | 448060 | 4620 | 1% |
| Магадан өлкәсе | 66181 | 706 | 1% |
| Камчатка крае | 134609 | 1598 | 1,2% |
| ЯНАО | 197454 | 2368 | 1,2% |
| Краснодар крае | 2394822 | 35121 | 1,5% |
| *** | *** | *** | *** |
| Иркутск өлкәсе | 1039272 | 142729 | 13,7% |
| Курган өлкәсе | 360391 | 52825 | 14,7% |
| Амур өлкәсе | 340646 | 60163 | 17,7% |
| Калмык Республикасы | 94472 | 18427 | 19,5% |

# бәдрәфләр вә утын

| | | | |
|---|---|---|---|
| Саха(Якутия) Республикасы | 358828 | 72599 | 20,2% |
| Алтай Республикасы | 76754 | 16370 | 21,3% |
| Яһүд автоном өлкәсе | 66815 | 14396 | 21,5% |
| Бурят Республикасы | 364331 | 94220 | 25,9% |
| Байкал аръягы | 396228 | 119239 | 30% |
| Тыва Республикасы | 98586 | 47632 | 48,3% |

Җанисәп алу Россиядә 4 процент торакның канализациясе булмавын күрсәтте. Бу – әллә ни күп түгел кебек тоелса да, бөек держава өчен абсолют саннарда аз да түгел инде. Үзәк төбәкләрдә табак-савыт юган суны тышка түгүчеләр берән-сәрән генә булса, Урал тауларыннан көнчыгышка таба процентлар югары. Мәсәлән, Тываның ярты халкы канализациянe нәрсә икәнен дә белми. Иркутск, Амур, Курган өлкәләрендә канализация булмаган йортлар 13 проценттан югары. Татарстанда андый тораклар 1,6, ә Башкортстанда – 8 процент.

**ЧҮПНЕ ЧОКЫРГА, КҮЧКӘ ТҮГӘЛӘР**

| Төбәк | Торак саны, 2021 ел | Чүп чыгару оештырылмаган йортлар, 2021 ел | Чүп чыгару оештырылмаган йортлар, 2021 ел, % |
|---|---|---|---|
| Калининград өлкәсе | 448060 | 1018 | 0,2% |
| Татарстан Республикасы | 1653954 | 4054 | 0,2% |
| Мурманск өлкәсе | 313377 | 839 | 0,3% |
| Удмурт Республикасы | 611389 | 1739 | 0,3% |
| Белгород өлкәсе | 649081 | 1865 | 0,3% |
| Чуашия Республикасы | 496664 | 1705 | 0,3% |
| Мәскәү өлкәсе | 3975160 | 14063 | 0,4% |
| Кырым Республикасы | 814548 | 2915 | 0,4% |
| Самара өлкәсе | 1486603 | 6734 | 0,5% |
| Свердловск өлкәсе | 1987645 | 9531 | 0,5% |
| *** | *** | *** | *** |
| Хакас Республикасы | 227402 | 16050 | 7% |
| Курск өлкәсе | 475129 | 35636 | 7,5% |
| Оренбург өлкәсе | 817550 | 64475 | 7,9% |
| Орлов өлкәсе | 320484 | 33402 | 10,4% |
| Дагстан Республикасы | 826480 | 97608 | 11,8% |
| Алтай крае | 972470 | 123925 | 12,7% |
| Яһүд автоном өлкәсе | 66815 | 9242 | 13,8% |
| Саха(Якутия) Республикасы | 358828 | 55051 | 15,3% |
| Алтай Республикасы | 76754 | 15276 | 19,9% |
| Тыва Республикасы | 98586 | 36494 | 37% |

Чүпне чокырга түгү турында мәкалә башында телгә алынган иде. Татарстанда торак хуҗаларының 0,2 проценты гына чүпне чокырга, күчкә ташлый икән. Бу – 1000 йортка 2 йорт туры килә дигән сүз. Юк дәрәҗәсендә. Башкортстанда да чүп җыю әйбәт оештырылган (0,7 процент).

Санап үткән бөтен күрсәткеч буенча Мурманск өлкәсенең лидерлар рәтендә булуы анда тормыш шартлары сизелерлек яхшы дигән сүз түгел. Ул – төньяк төбәк, анда иген үсми, шуңа күрә авыллар юк дәрәҗәсендә. Мурманск өлкәсендә 313 мең йортның 294 меңе шәһәр җирлегендә урнашкан. Шуңа күрә бу төбәк тә кагыйдәләрне раслый торган чыгарылма гына.

**Рифат КАЮМОВ,**
intertat.tatar.

**Теле барның иле бар**

## «Саф» проект

Интернет киңлекләрендә татар телендә эшләүче «Саф» балалар радиосы» 1 февральдән «Саф музыка» проектын башлап җибәрде. Ул музыка белән кызыксынучы балаларга профессиональ яктан үсәргә, татар музыкасы фондын саклап калуга һәм үстерүгә, киләчәк буынга мирас калдыруга, балалар башкаруында татарча музыка әсәрләрен югары сәнгать дәрәҗәсенә күтәрүгә юнәлтелгән.

«Саф музыка» кысаларында Казан шәһәренең музыка, сәнгать мәктәпләрендә укучы сәләтле балалар барланачак. Иң яхшы укучылар башкаруында татар композиторлары иҗат иткән әсәрләрне профессиональ тавыш яздыру студияләрендә эшкәртү, радиода яңгырату күздә тотыла. Шулай ук радионың сайтында ул композицияләрдән ирекле фонотека тупланачак. Теләгән һәр кеше сайтка кереп, ул җырларны тыңлый алачак.

Проектта катнашучы иң сәләтле балаларны сәхнәгә күтәрү дә планлаштырыла. Алар профессиональ музыкантлар белән берлектә ике концерт бирәчәк, ә концертка әзерлек дәвамында танылган композиторлардан, музыка белгечләреннән хәер-фатиха алачаклар.

Проектның җитәкчесе, «Саф» балалар радиосының музыкаль мөхәррире Чулпан Яркәева сүзләренчә, мондый проект күптән көтелгән. «Саф музыка» 1 февральдә башланды. Беренче 5 көн эчендә инде 20дән артык видеоязма алдык. Татар телендә музыкаль проектларга ихтыяҗ шундый зур икән! Музыка мәктәпләре укытучыларыннан бик күп уңай фикерләр, теләкләр ишетәбез», – ди Чулпан ханым.

Музыкаль әсәрләрне берничә юнәлештә кабул итәләр: татар композиторларының әсәрләре, татар фольклоры, балалар үзләре иҗат иткән татарча инструменталь һәм вокаль әсәрләр.

«Саф музыка» проектын Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, «Саф» татар балалар интернет-радиосы гамәлгә ашыра.

**Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.**

## Иманлы бәйге-фестиваль

Татарстанда «Рухи моң» татар рухи мәдәниятен үстерү конкурс-фестивале башлана. Шул уңайдан мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин бәйге-фестивальне оештыручылар – җырчы Марсель Вәгыйзов һәм алып баручы Марсель Әхмәдуллин белән очрашты.

Быел дүртенче тапкыр үтәчәк бәйгене «Рухи моң» иҗат берләшмәсе, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе һәм Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте, Ислам кабул итүнең 1000 еллыгы исемендәге мәдрәсә ярдәме белән оештыра.

Конкурс 4 номинациядә үткәрелә: «Дини җыр», «Мөнәҗәт», «Милли мәкам белән азан әйтү» һәм «Вәгазь сөйләү».

Бәйгенең сайлап алу этабы читтән торып уздырыла. Конкурсның финалы 21 апрельдә – Ураза гаете көнне – Казанда «Чулпан» мәдәният үзәгендә гала-концерт рәвешендә фестиваль итеп оештырылачак.

Әлеге бәйге милли мәкам һәм традицион мелодика калыпларын кайтару, халкыбызның нигез кыйммәтләрен үз эченә алган рухи җыр жанрын баету, татар мәкаме белән азан әйтү культурасын булдыруны, татар теленең кулланылыш даирәсен, ана телебездә вәгазь сөйләү сыйфатын арттыруны максат итеп куя.

## Атнаның сәяси мизгелләре

# БӘЛА ЯЛГЫЗ ЙӨРМИ

Бүген бөтен дөньяны изалаган ясалма табигатьле бәла – Украина белән бәйле хәлләргә, узган атнада инде табигатьтәге процессларга бәйле каза да өстәлде. Төркия халкы һәм Сүриядә яшәүчеләр дә 6 февраль таңында һәм шул көнне көндез көчле (7,4-7,8 магнитудалы) җир тетрәү белән бәйле фаҗигагә тарыды. Газетабыз басмага киткәндәге соңгы мәгълүматлар (7 февраль) буенча, ике илдә һәлак булучыларның гомуми саны 7 меңнән артып киткән (шулардан 6 меңнән артыгы – Төркиядән). Төркиядә зыян күрүчеләрнең гомуми саны 26 меңнән күбрәк дип бәяләнә. Якынча 15 миллион кеше йорт-җирсез калган. Бу ил хакимияте бәяләвенчә, 1939 елдан соң бу фаҗига анда иң зур стихияле бәла-каза санала икән. Күп кенә илләрнең башлыклары (Татарстан Рәисе Р.Миңнеханов та алар рәтендә), Төркия халкының авыр кайгысын уртаклашып, телеграммалар юллаган. Бу илгә ярдәм кулы сузучылар да шактый. Әйтик, 7 февральгә каршы төндә Россиядән дә 100 дән артык коткаручы килгән. Кайбер мәгълүматларга караганда, үз ярдәмен хәтта Украина да тәкъдим иткән.

Әлбәттә, Украина белән бәйле хәлләр дә игътибар үзәгендә кала. Әйтик, Россиянең БМОдагы даими вәкиле урынбасары А.Евстигнеева бүгенге дөнья кризисы башлануын күп кенә илләрнең бер полярлы дөньяны саклап калырга тырышуы һәм күп полярлы гадел халыкара мөнәсәбәтләр системасы формалашуын булдырмаска тырышуы белән аңлаткан. РИА Новости «Washington Post» басмасына сылтап язуынча, АКШ Конгрессында республикачылар арасында Украина үз территориясенең бер өлешеннән Россия файдасына баш тартырга тиеш, дип санаучылар да бар икән. Кремль исә мәгълүмат кинлекләрендә, имеш, ЦРУ Мәскәүгә, Украинаның 20 % территориясен тынычлыкка алыштыру тәкъдиме белән чыккан, дигән хәбәр таратылуын «ялган» дип атаган. Ә Россия саклану министры С.Шойгу АКШны НАТО илләрен Украинадагы низагка тартып кертүдә дә гаепләде.

Игътибарны җәлеп итә торган кайбер башка хәбәрләрне дә бер җөмлә белән генә билгеләп үтик. Сербия Президенты А.Вучич үз иленең НАТОга керергә җыенмавы турында белдергән. Приднестровьеда Молдаванның үз Җинаять кодексына сепаратизм өчен җәза кертүен «агрессия акты» дип атаганнар. Австрия Россиянең 4 дипломатын, бу вазыйфага туры килми торган гамәлләр кылуда гаепләп, илдән сөрүе турында белдергән. Израиль Премьер-министры Б.Нетаньяху Украинага ПВО системалары кую мөмкинлеге турында әйткән. НАТО Россияне ДСНВ килешүен үтәмәүдә гаепләгән. Молдова парламенты спикеры И.Гросу Россия тышкы эшләр министры С.Лавровны, Молдова үзенә «чираттагы Украина» ролен чамалап карый ала, дигән сүзләреннән соң, шовинизмда гаепләгән.

**Фоат УРАЗАЙ.**

# Ильяз –

**Гади татар укучысының кибет яки киоскларадан яңа китап, журнал йә газета, хәтта товар салынган ниндидер картон кап вә пакет сатып алган, алардан да бигрәк изге Болгар җирендә махсус сарайга куелган һәм Җир шарындагы иң зур Коръән китабы буларак танылган ядкәргә соклану белдергән чагында да, аның кәгазен кем җитештергән, дөньяга кем тудырган булуы хакында уйлап та караганы юктыр. Шуңа күрә кулына эләккән рухи азык өчен иң беренче чиратта кайсы изге җанга рәхмәтле булырга тиешлеген дә күз алдына китерә алмый күпләр. Ә югыйсә, республикабызны кәгазь продукциясенең күпчелеге белән үзебезнең үк газиз татарыбыз – Волгоград өлкәсе егете Ильяз Булат улы Мөслимов тәэмин итеп яши.**

Аның тормыш юлын сокланмый һәм гаҗәпләнмичә генә күз алдына китерү мөмкин түгел. Төптәнрәк уйласаң, аның дөньяга килүе – үзе үк зур могҗиза. 1942-1943 елларда Сталинград өлкәсе Бөек Ватан сугышы кайнаган иң зур һәм иң хәвефле, утлы казан булган. Гитлер армиясе туктаусыз рәвештә Сталинградка омтыла, аның юлын бүлү өчен шәһәр белән дошман траншеялары арасына йөз меңләгән совет солдатларын китереп тутыралар (сүз уңаеннан: Сталинград өчен сугышларда 20 меңнән артык татар сугышчысы һәлак була). Сталинградтагы тыныч халыкның – карт-коры, хатын-кыз, бала-чаганың күпчелеге якындагы район вә авылларга качкан. Дошман исә якынтирә авылларның тулысынча хатын-кыз яки бала-чагадан хасил булуы турында уйлап та карамый, көн саен аның самолетлары күк йөзеннән агач өй һәм сарай хәрабәләре өстенә пуля һәм бомба яңгырлары коеп үтә. Күпләр бакча һәм тыкрыкларга окоп яисә тирән баз казып өлгергән. Ильязның әбисе дә бервакыт бер яшь ара белән туган ике нәни улын шул базларның берсе эченә төшереп калдыра да, үзе туңган җирне пычак белән казып бәрәңгә җыю өчен, басуга чыгып китә. Дошманның күк йөзендә пәйда булган чираттагы эскадрильясы әби-чәбине һич кызганып тормый, шул туң җирдә казынучы ач халыкны утка тотып уза, хәтта бер явызы, пулялар яңгырын юри кешеләр өстенә тидермичә сибеп, аерым кешеләрне авыл читенә тикле куып күңел ача. Ильязның әбисе улларын калдырган баз янына кайтса, аның урынында олы чокыр гына. Шашкан ана чокыр диварларын ялан куллар белән казый башлый. Ильязның әтисен табып, ашыга-кабалана, аның балчык белән тулган авыз-борыннарын чистарта. Бала сулыш ала башлагач, икенчесен эзләргә ташлана. Ләкин соң шул инде. Бичара ана анысын бер алмагач төбенә җирләргә мәҗбүр була... Никадәр фаҗига! Ә югыйсә, гарәп, төрек, Европа телләрен – барлызы җиде телне камил белүче ана бит ул. Ире белән бергә Харьков каласында зур сәүдә йорты тотучы бай гаилә була. Комиссарлар барча хуҗалыгын тартып алып, үзләрен шыр-ялангач көе урамга куып чыгарса да сынмый алар. Ильязның бабасы ике тимер юл шпалын берьюлы иңсәләренә күтәреп, яңа хакимият иминлеге өчен бил бөгә, туган илен ташлап китү турында уйлап та карамый. Үзе эшләгән предприятие мөлкәтен коткарып калу өчен, бозлы суга чума һәм шунда үпкәсенә яман салкын тидереп, бакый дөньяга да китеп бара... Икенче бабасы 1941 елда ук Украина азатлыгы өчен Белая Церковь каласы янында һәлак була...

Ильяз үзе 1963 елда дөньяга килә. Волгоград каласының гап-гади бер малаедыр кебек. Ләкин гади генә итеп яшәве дә читен. Янда гына сугыштан ике аяксыз көе кайткан Коля дәдәй. Хатыны сугыш вакытында партизаннар отрядында булган, ул да инвалид, урын өстендә ята. Бөтен тирә-як балалары белән шушы гаиләне шефлыкка алалар. Малайлар кар көри, утын яра, мич торбасын чистарта, түбә яба. Кызлар азык-төлек ташый, кухняда кайнаша. Коля дәдәй дә балаларның изгелеген онытмый, үзенә дәүләт ике урынлы инвалидлар машинасы биргәч, шуның эченә җидешәр-сигезәр малай-кызны утыртып, урамнар буенча әйләндерә, кирәк чакта малайларны стадионга, «Ротор» командасы футболчыларының уеннарын карарга да илтеп куя.

– Гаҗәеп замана! Теләсә кайсы фатирның ачкычлары ишек төбендәге палас астында гына ята иде, мәгәр урлашу, чит-ят кеше малына кул сузуның ни икәнен дә белмәдек. Берәр кешенең туган көне җитсә, барча фатирлардан ризык ташып, ихата уртасында бәйрәм итә идек. Пасханың нинди бәйрәм икәнен аңлап җиткермәсәм дә, күршеләр белән берләшеп, тавык йомыркаларын төрле төсләргә буядык. Ниндидер бәйрәмнәрдә бергәләп боткалар да пешердек. Толерантлык дигән күренеш чәчәк аткан гүзәл заман булган, – дип искә ала Ильяз әфәнде әле бүген дә...

Ә аннары – мәктәп. Гаиләдә тел-теш тидермәслек итеп укуны таләп иткәннәрдер, Ильяз үзе хәтта бишенче сыйныфны тәмамлаганчы йөзә дә белми үсә. Үзең Идел буенда яшә дә, йөзә дә белмә инде! Бервакыт балык тотарга дип Идел уртасына чыккач, көймә борыныннан егылып төшә егет. Күзен ачып караса, кояш шәүләсе һаман саен ерагая, тоныгая бара. Атылып су өстенә калыкса, көймәдә әтисе дә юк. Курыкмый нишлисең ди? Янә чумарга, хәзер инде әтисен эзләргә кирәк. Югыйсә, әтисе дә, нәкъ улы шикелле үк, су төбенә киткән малаен эзләп азаплана, лабаса. Ниһаять, көймә өстенә менеп урнашкач кына, капылт ярып сала:

– Йөзәргә өйрәнмичә торып, балыкка барасың юк!..

Шулай, дөнья бик тиз өйрәтә ул. Ильяз да соңыннан Садовничий, Попов, Панкратов кебек дөньякүләм танылган спортчылар белән бергә йөзү секциясенә йөри башлый. Мәктәптәге билгеләре «өчле», «дүртле» чамасына төшеп беткәч, әнисе киртә сала. Аннары инде Ильяз җиңел атлетикага күчә, 800 метр арага йөгерү буенча спорт мастерлыгына кандидат дәрәҗәсенә ирешә. Ләкин дөньяда аннан да мавыктыргычрак могҗизалар бар икән әле. Әнә, Кача очучылар мәктәбендә булачак космонавтлар отрядына җыя башлаганнар. Анда 8 класстан соң гына кабул итсәләр дә, Ильяз үзенең җиденче сыйныфта укуын яшереп язылa. Самолетлардан парашют белән сикерә башлыйлар, тора-бара бу җитди мавыгуга әверелә. Әфган сугышы барган замана бит, Ильяз да десант гаскәренә язылу, яу-бәрелешләрдә батырлык кылу турында хыялланa. Җитмәсә, бер дусты Әфганнан Сугышчан Кызыл Байрак ордены алып кайтуга да ирешкән бит... Ләкин егетне чик буе гаскәрләренә юллыйлар. Иран белән Гыйрак арасында сугыш барган вакыт. Көньяк чикләрне бозып, совет ягына әле Иран, әле Гыйрак качаклары качып килә. Бер генә качакны тотсаң да туган якка кайту өчен отпуск бирелә, дигән йола бар ул барын, иллә мәгәр монда бер тәүлек дәвамында дүрт-биш качак, нинди ял турында уйлап тору ди ул?..

Җитмәсә, көтмәгәндә Мәскәүнең инженер-физиклар институтыннан махсус делегация килеп төшә. Төрле тестлар һәм аерым әңгәмә үткәреп, солдатларның белем дәрәҗәсен ачыклыйлар. Бер ай узгач, чик буе отрядына Мәскәүдән махсус чакыру килеп җитә:

– Отряд комсоргы Ильяз Мөслимовны безнең институтка укырга озатыгыз!

# бизнес остасы



– Бармыйм! – дип кырт кисә әүвәлрәк чик сакчысы Ильяз. Аннары, әти-әнисе дә «җүләр булма», дип кыстагач, ризалыгын бирә...

Мәскәүдә биш ел буе уку сизелми дә уза. Дөрес, Ильяз институтта «Атом реакторлары физикасы» белгечлеге буенча гыйлем үзләштерә бит, җитмәсә, кара кайгы булып, Чернобыль атом электр станциясендә коточкыч фаҗига да булып уза. Мәскәүдә пропискасы булмаган кешеләрне чебен кугандай читкә типкән заман. Ләкин атом реакторлары буенча белгечләр дә бармак белән генә санарлык. Килмешәк дип тә тормыйча, Ильязны аспирантурада фән белән шөгыльләнергә калдыралар. Аерым төркемнәр белән бергә Чернобыльга да барып кайтырга туры килә. Ә аннан соң Горбачев кузгаткан «үзгәртеп корулар» заманасы, тоташ акчасызлык. Эксперименталь бер будка ясау өчен кирпеч алырга да акча бирүче юк. Кәмит түгел диген, аспирантлар дипломатларына төнлә белән дүртәр кирпеч тутырып, тезелешләрдән урлашырга мәҗбүр була. Шулай итеп махсус будка ясыйлар, шунда сынау уздыралар, төшке ашка дип бирелгән талоннарны сатып та, фәнни сынау өчен кирәк-ярак алырга туры килә. Ул гына да түгел, әле яшәү, киенү өчен дә каяндыр акча юнәтергә кирәк бит. 4-5 егет белән төнлә яшелчә базасына барып, өчәр-дүртәр вагон кәбестә йә бәрәңге бушаталар. Шул акчага музей-театрларга йөрергә дә форсат табалар...

Мондый кытлыкка тагын да түзә алмыйча, 1985-1987 елларда Ильяз, җәй җитүгә үк, өлкән курс студентларыннан төзелеш отряды туплый да, Архангельск өлкәсенә эшкә китеп бара. Егетләрне хәрби хезмәт үткән һәм спорт өлкәсендә югары күрсәткечләргә ирешкәннәр арасыннан сайлап алалар. Ә Архангельскида аларга йөзьяшәр нарат, каен, карагай агачларын егарга туры килә. Кайсыдыр түрәләрнең йорт вә кабинетларына ремонт үткәреп тә «шабашка» эшлиләр. Нәтиҗәдә студентлар аена 1000-1500 сум чамасы хезмәт хакы алырга тиеш була. Ә Ильяз әле мондый үр-кунача белән дә риза түгел, атна буе ялына торгач, Архангельск целлюлоза-кәгазь комбинатының генераль директоры янына үтеп керә:

– Хезмәт хакының яртысы урынына сез безгә кәгазь рулоннары бүлеп бирсәгез иде, зинһар?

Фәлән егетнең яртышар хезмәт хакын туплагач, сумма бик аз гына булып чыкмагандыр. Егетләр шуңа йөзәрләгән рулон кәгазь юнәтә дә, ике ЗИЛ-130 машинасын яллап, аны Мәскәүнең инженер-физиклар институтына алып кайта. Кәгазьнең яртысын капитан Врунгель турындагы китапны бастырып чыгаруга тоталар. Роман-газета форматындагы юка тышлы китапның берсе 80 тиен бәядән сатыла. Нәтиҗәдә китап 850 процент чиста табыш китерә!..

Туксанынчы еллар үре, ата – улын, ана – кызын танымый башлаган болганчык заман бит бу. Кәгазьнең валюта дәрәҗәсендә йөрүен аңлап алуга ук, Ильяз 1992 елда «Папирус» атлы компания оештыра һәм илдәге Архангельск, Краснокамск целлюлоза-кәгазь, Волгоградтагы «Каустик» комбинатлары белән хезмәттәшлек итә башлый. Ләкин асты-өскә килгән илдә берәүгә дә кочак җәеп торган җитәкчеләр юк бит, кырыкмаса-кырык төрле киртәләр аша узарга туры килә. Әүвәл 1998 елда үзенең компаньоны белән ара бозылу нәтиҗәсендә алар предприятиене икегә бүләргә мәҗбүр була. Күп вакыт та үтми, Ильяз юл фаҗигасенә эләгә һәм могҗиза белән дигәндәй исән кала. Шул ук елда аның предприятиесендә коточкыч янгын чыга һәм «Папирус» гаҗәеп зур акчалар югалта. «Самсон», «Комус» фирмалары дәрәҗәсендәге канцелярия кәгазе чыгару тармагын югалтса да, «Папирус» барыбер тиз арада аягына баса һәм сәүдә өлкәсендә үз урынын яулый. Ул бүген елына 160 мең тонна күләмендә төрле сорттагы кәгазь сату белән шөгыльләнә, абруе да какшамас һәм сынатмас югарылыкта.

Ильяз әфәнденең татар җанлылыгы алдында аерым баш иярлек. 1992 елда «Папирус» сәүдә йортын булдыргач та, ул Мәскәүнең үзендә безнең милләт өчен «Татар хәбәрләре» исемле федераль дәрәҗәдәге газета чыгара башлаган һәм 16 ел дәвамында аның гомуми тиражын 50 мең данәгә җиткергән иде. Аннары Ильяс Булат улы 5 нче чакырылышта Дәүләт Думасы депутаты булып сайланды да, милли-мәдәни автономияләрне дәүләт казнасы хисабына финанслау мәсьәләсен күтәреп чыкты, һәм алар бүгенгәчә аның тырышлыгы нәтиҗәсендә ярдәм күреп яши. Ә тагын да гүзәлрәк гамәле – әлбәттә, изге Болгар җире өчен дөньядагы иң зур Коръән китабын бастырып бирү!

Әлеге идеяне Минтимер Шәймиев шәхсән үзе күтәреп чыга. «Янарыш» фонды бу өлкәдә ярдәм күрсәтүен сорап мөрәҗәгать иткәч, Ильяз әфәнде шундук Ватикан типографиясе һәм Шотландиядәге борынгы фабрика белән элемтәгә керә. Үлчәме белән метр ярымга ике метр зурлыкта, авырлыгы белән 800 килограммга җиткән Коръәнне бердәнбер нөсхәдә бастырып алу һәм төпләү һич тә җиңел булмый. Ләкин Ильяз әфәнде изге Коръәнебезне Болгар җиренә кайтарып бүләк итүгә ирешә һәм, әлбәттә, ул сакланган мәчет бинасын ачу тантанасында да катнашмыйча калмый...

Ильяз әфәнде – дүрт бала атасы, һәм аларны татар җанлы, татар телле итеп үстерү өчен гел җан атып яши. Мәгыйшәттә иң төп кайгысы – татар һәм Рәсәй халкында галиҗәнап Китапка булган мәхәббәтне кире кайтарудыр. Россиянең китап союзы рәисе Сергей Степашин белән бергә Мәскәүнең Кызыл мәйданында ел саен китап ярминкәсе бәйрәмен үткәрү дә – менә шул ният-тән. «Европа белән Америкада китапка мәхәббәт кабат элеккеге дәрәҗәсенә кайтты, хәзер халык әсәрләрне электрон челтәрләр аша эзләп түгел, ә ул кулына чын китап тотып укый башлады. Бу чишмәдәй һич корымас гадәт татар милләтенә дә әйләнеп кайтса иде!» – дигән хыялы да менә шуннан.

**И.ВАХИТОВ.**

**РЕДАКЦИЯДӘН. «Татмедиа» Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе А.Сәлимгәрәев, «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы коллективы һәм аның генераль директоры Ә.Әскәров, шушы көннәрдә матур гомер бәйрәмен каршы алучы Ильяз Булат улы Мөслимовны ихлас котлап, аңа нык сәламәтлек, озын гомер, бәхет, күңел биргән эшендә яңадан-яңа уңышлар тели.**

## Айга карама кырын

**Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!**

**11 февраль (шимбә).** ***Рәҗәб аеның 20нче көне. 21 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 0.20 сәгатьтә калка, 9.47 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 9.19 сәгать.***

Сәяхәткә чыгу, теләсә нинди эш башлау өчен айның иң кулай көне. Кеше хәлиткеч карарлар кабул итәргә сәләтле. Физик эш белән шөгыльләнү, җәяү йөрү, чыныгу файдалы. Саф һавада күбрәк булу, табигать белән хозурлану кәефне күтәрә. Умырткалыкның аскы өлеше, әвернә сөяк, аяк зәгыйфь.

### Кычытканлы алма согы

Әгәр баш һәм колак шауласа, күз аллары караңгыланса, баштагы кан басымы күтәрелсә, баш мие тамырлары склерозы интектерсә, 2 аш кашыгы кычыткан өстенә 150 мл кайнар су агызып, яхшылап төреп, җылы урында 4 сәгать тәнәтәләр, сөзеп, шулкадәр үк алма согы кушалар, яхшылап болгатып, 50-100 әр мл сокны көненә 3 тапкыр ашарга 15 минут кала эчәләр. Суыткычта саклыйлар.

**12 февраль (якшәмбе).** ***Рәҗәб аеның 21 нче көне. 22 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында, 1.50 сәгатьтә калка, 9.53 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 9.23 сәгать.***

Акыл җыю, белем алу, фәннәр өйрәнү көне. Юмарт булырга, ашау-эчүдә үзеңне чикләмәскә кирәк. Күбрәк аралашкан саен, яхшы тәэсирләр дә арта бара. Кан әйләнеше системасы, буыннар, умырткалык зәгыйфь.

### Үт куыгына ярдәм

2 лимон согын сыгып, шуңа 2 аш кашыгы зәйтүн мае һәм 1 стакан юкә балы кушалар, әйбәтләп болгатып, суыткычта саклыйлар. 3 атна дәвамында көн саен 3әр аш кашыгы кабалар. Дәва курсын 3 айга бер тапкыр кабатлыйлар. Үт куыгында таш булганнарга болай дәваланырга ярамый.

**13 февраль (дүшәмбе).** ***Рәҗәб аеның 22 нче көне. 23 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында, 2.05 сәгатьтә калка, 10.05 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 9.27 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Тәвәккәл адымнар ясау хупланмый. Арып-талганчы эшләргә киңәш ителми. Дару үләннәре белән дәвалану уңай нәтиҗә бирә. Иҗат белән шөгыльләнү өчен яхшы вакыт.

### Суган шикәрне киметә

Диабеттан интегүчеләр, кандагы шикәр микъдарын киметә алмый азапланучылар өчен бу киңәш: 3 кг суганны бертигез 10 өлешкә бүләләр. Көн саен шуның бер өлешен чистартып, вак кына турыйлар, 1 стакан кайнап торган суга салып, 5 минут пешерәләр. Сөзеп, шул төнәтмәне көн дәвамында эчеп бетерәләр (көненә 3 тапкыр, ашарга 30 минут кала, тигез микъдарда). 10 көн буе тоташ дәваланырга кирәк, югыйсә нәтиҗәсе булмаячак. Дәва курсын тагын 6 айдан кабатларга була.

**14 февраль (сишәмбе).** ***Рәҗәб аеның 23 нче көне. 24 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы***

**(Дәвамы 18 нче биттә).**

## Айга карама кырын

***йолдызлыгында, 3.23 сәгатьтә калка, 10.24 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 9.31 сәгать.***

Артык активлык күрсәтү хупланмый. Ялгыз калып уйлану өчен уңай вакыт. Эчке тавышка колак салу файдалы. Бизләр системасы, кан тамырлары, тире, эчәклек зәгыйфь. Күзне арытмаска кирәк.

### Ангинадан – прополис

Ангинадан иң шәп дәва чарасы – яңак белән аңкау арасына төнгелеккә прополис кисәге кыстырып яту. Прополис югары сыйфатлы булып, телне беразга гына оетырга тиеш. Ангина вакытында ашаганнан соң прополис чәйнәү дә булыша, көненә 5 г китә, 2 көндә чир үтә.

**15 февраль (чәршәмбе).** ***Рәҗәб аеның 24 нче көне. 25 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 4.56 сәгатьтә калка, 10.54 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 9.36 сәгать.***

Акыл җыю көне. Интуициягә таянырга була. Күргән төшләр рас килә. Сизү әгъзалары, баш, колак, кан тамырлары зәгыйфь. Энергияне юк-барга сарыф итәргә ярамый.

### Чикләвекле алоэ

Салкын тиюне, гриппны кисәтү өчен, 100 г алоэ яфрагы согы, ярты кило төелгән әстерхан чикләвеге, 300 г юкә балы, 3-4 лимон согын кушып, сихәтле катнашма ясыйлар, аны суыткычта саклыйлар. Авырый башлауны сизгәч үк, көненә 3 тапкыр, ашарга 30 минут кала, 1 әр чәй кашыгы кабалар.

**16 февраль (пәнҗешәмбе).** ***Рәҗәб аеның 25 нче көне. 26 нчы Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 6.17 сәгатьтә калка, 11.45 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 9.41 сәгать.***

Һәртөрле вәсвәсәләргә бай көн. Әйләнә-тирә дөньяны кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек арта, чит кеше йогынтысына бирешүчәнлек көчәя. Килешүләр төзү уңышлы. Нерв системасы, аяк зәгыйфь. Балык, мүк җиләге, сөт ризыклары ашау файдалы.

### Тибет эликсиры

Ярты стакан лимон согына 1 стакан бал, чирек стакан чистартылмаган зәйтүн мае (көнбагышныкы да ярый) кушалар. Ай буена ач карынга, иртәнге ашка 15 минут кала, 1 әр десерт кашыгы эчәләр. Мондый эликсир буыннарны һәм эчәклекне чистарта, йөрәкне ныгыта, бавыр һәм бөерләрнең эшен яхшырта.

**17 февраль (җомга).** ***Рәҗәб аеның 26 нчы көне. 27 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 7.14 сәгатьтә калка, 13.00 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 9.45 сәгать.***

Бу көннәрдә организм хәлсез, шунлыктан күбрәк йоклау файдалы. Нерв системасы, сизү әгъзалары зәгыйфь. Кан һәм лимфа авырулары кискенләшергә мөмкин. Кан басымын контрольдә тоту сорала.

### Эремчекле печенье

200 әр г эремчек һәм атланмай, 2 йомырка, өчтән бер чәй кашыгы сода, 2 стакан он кирәк, крем өчен исә 2 йомырка агы 1 стакан шикәр белән күпертәләр. Камыр басып, 15 минутка суыткычка куялар. Аннан соң җәеп, өстенә крем сылыйлар да, рулет итеп төрәләр, 3 әр сантиметрлы кисәкләргә бүләләр. Табага ара калдырып тезеп, газ мичендә пешерәләр.

# Бер уч туфрак

*Үләм, дидем, ярый, тик кайгырдым,*
*Күреп үлсәмче, дип, кызымны!*
*Анам кабре – туган туфрагыма*
*Куеп үлсәмче, дип, йөземне!*

Муса Җәлилнең «Соңгы үпкә» шигырендәге шушы сүзләре Оренбург өлкәсенең Яфар авылы мөгаллиме Гөлсем Әсәеваны чиксез тетрәндерә. Шул дәрәҗәдә – ул шагыйрьнең шушы теләгән тормышка ашырырга кирәк дигән хыял белән яна башлый. Гөлсем исә үзе – Оренбург өлкәсенең актив татар хатыны.

Күренгәнчә, Җәлил бу шигырендә әнисе кабере янында җирләнергә теләве турында да игълан иткән. «Мөгаен, бу бик авыр гамәлдер. Әмма аның бу теләгән ничек булса да чынга ашырасы иде. Хыялым – әнисенең кабереннән бер уч туфрак алып, Җәлил каберенә илтеп салу, рухына дога кылып кайту. Бу – изге бурыч төсле. Без бит – Җәлилнең якташлары. Мостафа авылы янибызда гына. Мин аның музее ачылышына да барган идем. Хәзер көн дә уйланам: 11 татар каһарманының җәсәдләрен туган якларына кайтарып җирли алсак иде, дим. Соңгы җәсәд җирләнмичә торып, сугыш туктамый, дигән сүзләр бар. Бәлки, шуңа кан коюлар бүген дә дәвам итәдер. Җәлилчеләрне туган туфракларына алып кайту – безнең бурыч», – дип сыкрана Гөлсем.

Аның улы Германиядә булып кайткан. 2020 елда Г. Әсәева үзе дә анда барырга хыялланган, әмма пандемия киртә куйган.

Ул Җәлилнең туган көненә «Соңгы үпкә» шигыре буенча флешмоб ясарга да тәкъдим итте. «Төрле илләрдәге милләттәшләребез ярдәме белән башкаларга да ишеттерсәк иде!» – ди.

Гөлсем ханым 2008 елда беренче тапкыр Казанда була, Җәлил һәйкәле янында дога кыла. «Казанга беренче тапкыр 50 яшемдә бардым, хәзер инде 3-4 тапкыр булдым. Барган саен һәйкәл янында дога кылам», – ди ул.

Г.Әсәева Яфар авылы мәктәбендә инглиз һәм немец телен укыта. Үзе дә шигырьләр иҗат итә, җыентык чыгарган. Беренче һөнәре буенча ул – фельдшер-акушер, 12 ел медпунктта эшләгән.

– Соңрак кешенең тәне түгел, җаны яралы булуын аңладым. 1983 елда, читтән торып, педагогика юнәлешендә белем алдым. 1989 елдан башлап, туган мәктәбемдә чит телләр укытам. Әмма балаларга татар теле атнасына бер тапкыр гына керә, бу хәлгә күңел әрни, – дип рәнҗү белдерә ул.

Г.Әсәева авылда үзе генә яши. 2 улы нефть юнәлеше буенча укыган. Кызы югары уку йортында белем ала, өлкәдә татар яшьләре оешмасын җитәкли.

Гөлсем ханым «Җәлил кабере», дип сөйләгәч, үзем дә икеләнеп куйдым. Аларның каберләре юк бит, дим. Ул бу мәгълүматка, хәтта, ышанырга да теләмәде. «Аларның үлгән вакыты минутына кадәр билгеле, ә җирләнгән урыннары ачыкланмаганмы?!» – ди. Ул үз теләгеннән баш тартмый, берәр чара буласына ышана.

Ул җирләрне күргәнем булмагач, Германиядә булып кайткан һәм Муса Җәлилне өйрәнгән кешеләр белән элемтәгә чыктым. Киносценарист һәм режиссер Нәсүр Юрышбаев җәлилчеләр батырлыгына багышланган, «77 адым» дип аталган фильм өчен сценарий язган иде. Ул җәлилчеләрнең башы киселгән урында күп тапкырлар булган.

«Җәлил җирләнгән урынны тәгаен генә беркем дә белми. Җәзалаганнан соң, аларның башларын, гәүдәләрен йә андагы крематорийда яндырганнар, йә төрмә янындагы чокырга күмгәннәрдер», – дип башлады ул сүзен. Шул урыннан туфрак алып кайту мөмкин, дип тә фаразлады.

Җәлилчеләрнең башы киселгән урын – хәзер мемориал бит, бөтен җирдә бетон. Төрмә тирәсеннән туфрак алып буладыр. Минем күп тапкыр туганнар каберлекләреннән солдатларның туган якларына туфрак алып кайтканым булды. Җиңүнең 70 еллыгы көнендә Саксониядә туганнар каберендә якташ абзыйның исемен таптым, кечкенә термоска кабердән туфрак тутырып, туган якка алып кайттым. Аның хатыны үләр алдыннан: «Ирем туган якка, минем янга кайтачак», – дигән булган. Ул туфракны хатынының каберенә салдым. Мондый гамәлнең савабы да бик зур, – дип сөйләде Н.Юрышбаев.

Бу гамәл турында Казанның Вахитов һәм Идел буе районнары имам-мөхтәсибе Йосыф хәзрәт Дәүләтшин да болай ди: «Җәлил рухын шатландыра торган хәерле гамәлләр кылырга кирәк. Җәлил исемен без күбрәк иҗат кешесе буларак кабул итәбез, шигырь кичәләре, концертлар уздырабыз, һәйкәлләр куела. Инде җәлилчеләрнең рухларын сөендерү өчен дини гамәлләр дә кылырга вакыт, хәйрия эшләрен башкарырга, ятимнәргә ярдәм итәргә була. Сәдакага тиң хәерле эшләр кирәк. Кое казытырга була. Милләтебезнең вафат булган егетләренә, кызларына шуннан файда күбрәк булыр иде. Туган туфракка килгәндә, аны изгеләштерергә ярамый, ул изге көчкә ия, дип әйтеп булмый. Шулай да, бу турыда китапларда күргәнем, галимнәрнең сөйләвен ишеткәнем бар. Сәхабәләр Мәккәдән чыгып киткәндә, кайберләре үзләре белән туфрак алган. Күңелгә тынычлык алу өчен булгандыр».

Республика мөфтиятенең «Даруль-ифта» call-үзәгеннән шәригать сораулары буенча бүлек белгече: «Кеше үзе өчен аны эшли ала, тик дин ягыннан андый гамәлнең асылы юк. Әрвахлар рухына дога кылу, Коръән уку савап», – дип аңлатты.

Бу очракта Җәлил әнисенең мөнәҗәтен дә искә аласы килә.

*Муса улым, сиңа әйтәм,*
*туганнарыңны кара,*
*Миңа үлем вакыты җитте,*
*кылып булмый бер чара.*
*Кара туфрак астында*
*калачак бу тәннәрем,*
*Берегезне дә күрә алмыйм,*
*шуңар әрни җаннарым.*

Күренекле татар композиторы Мәсгудә Шәмсетдинова М.Җәлилнең әнисе Рәхимә Җәлилованың мөнәҗәте табылу тарихын болай дип сөйләгән:

«Бу мөнәҗәтне Оренбург өлкәсендәге Сакмар районының Татар Каргалысы авылында яшәгән Фатыйма апа Абдрахмановадан 1992 елда язып алдым. (Абдрахманова Фатыйма Галиулла кызы 1927 елда туган, вафат инде, дип хәбәр бирде авылдашлары.) Аның сөйләве:

«Соль-Илецкига барган елны бер әби алып килде. Шушы гарәпчә язуны укыды. Гарәпчә белмим. Теге әбигә әйтәм, язып алыйм әле. Балам, вакытым юк, ди. Ул гарәпчә әйтеп торды, мин язып тордым. Шуны төнлә булса да барып язып алдым квартирында. Теге әби: «Җәлилләрнең авылында сарайларын җимергән чагында бүрәнәләр арасыннан килеп чыккан», – ди. Аны әбигә, гарәпчә дога, дип биргәннәр. Ә ул Җәлил әнисенең мөнәҗәте икән».

Фатыйма апа ничек теге әбидән күчергән, мин дә Фатыйма апа авызыннан шулай күчердем. Дәфтәрләре бик күп иде. Арып, хәлдән таеп, киләчәккә хәбәр булсын, тарих югалмасын, дия-дия, бер-беребезне арып-талудан яклап, бик күп хатирәләрне саклап калдык», – дигән.

*Муса Җәлилнең «Соңгы үпкә» шигыре*

*Эчем тулы каргыш, үпкә белән*
*Китәм инде җирнең өстеннән.*
*Мескен әни мине юкка гына*
*Күз нурларын түгеп үстергән.*
*Юкка гына күкрәк сөтен имезеп,*
*Бишек җыры җырлап тирбәткән.*
*Дөньясына нәфрәт, каргыш булып*
*Чыкты ул җыр минем йөрәктән.*
*Әйтче, дөнья, синең газабыңа*
*Түзмәдемме хәлем җиткәнче?*
*Түзмәдемме... иксез-чиксез сабырым*
*Яшем белән агып беткәнче?*
*Һәр хәшәрәт җирдә теләгәнчә*
*Суда йөзде, суда җебенде.*
*Ә мин менә соңгы сулышымда да*
*Чылаталмыйм кипкән иренемне!*
*Мин күрмәдем дуслык... дус урнына*
*Богау кысты минем кулымнан.*
*Кояш... ул да үләр минутымда*
*Мәхрүм итте мине нурыннан.*
*Үләм, дидем, ярый, тик кайгырдым,*
*Күреп үлсәмче, дип, кызымны!*
*Анам кабре – туган туфрагыма*
*Куеп үлсәмче, дип, йөземне!*
*Нигә миңа төрмә кабер булды,*
*Ник кан юды йоклар урнымны?*
*Җирне әллә артык сөйгән өчен*
*Җылысыннан мәхрүм булдыммы?*
*Дөнья, сине Ләйлә төсле күреп,*
*Мәҗнүн гыйшкы белән яраттым,*
*Ә син минем керсез йөрәгемне*
*Вәхши этләреңнән талаттың.*
*Аерып мине анам-Ватанымнан,*
*Кай җирләргә китереп ташладың?*
*Еласам да үксеп, үз илемнең*
*Туфрагына таммый яшьләрем.*
*Туган илем, үксез улың булып,*
*Үләм инде читтә тилмереп.*
*Яшем барсын сиңа елга булып,*
*Каным шытсын кызыл гөл булып.*

**Гөлүзә ИБРАҺИМОВА.**

intertat.tatar

# Акмулланың яңа басмасы

**(Ахыры. Башы 4 нче санда.)**

Текстларда очраган бер үк сүзләрнең төрлечә язылу фактлары сакланырга тырышылды. Чөнки бу, беренчедән, язма әдәби стильнең ул вакытларда әле ныклап урнашып, тәртипкә килеп бетмәве белән бәйле булса, икенчедән, күчерүченең кем булуы, аның укымышлылык дәрәҗәсе яки язылу мохитенең тәэсире нәтиҗәсе. Мәсәлән, айтып-әйтеп. Бу сүзләрнең беренчесе казах теле йогынтысына дәлил булса, икенчесе исә татар һәм башкорт телләренең хосусиятләрен чагылдыра.

Җыентыкны басмага әзерләү барышында мондый характердагы мирасны текстологик эшкәртү принципларының уңышлы апробация үткән һәм фәнни кулланылышка кертелгән казанышлары нигез итеп алынды.

Икенче бүлектә Акмулланың шәкертләреннән берсе булган Д.Качкынбаевның әле беркайда да басылмаган (аерым сылтамаларны искә алмаганда), фактларга бай, объектив язылган, документальлеге шик уятмый торган күләмле истәлеге урнаштырылу (Казахстан Фәннәр академиясенең кульязмалар фондында саклана: Папка 399, № 1) җыентыкның зур яңалыкларыннан берсе. Ул шагыйрь хакында хәзергә билгеле булган мәгълүматны тагын да баета һәм киңәйтә. Мәсәлән, тексттан күренгәнчә, аның аралашкан даирәсен, совет хакимияте чорындагы аңлатмалардан аермалы буларак, төрле социаль катлау вәкилләре тәшкил иткән икән. Алар арасында Күкчәтаудагы Муса (ул аңа шигырь дә багышлаган), Батуч, Орынбай хаҗи Корысбай угылы, Моктаганҗан Җегет угылы, Иманкол Моктабай угылы, Сәйфел исемле казах байлары, төрмәдән коткаруда турыдан-туры көч куйган Әхмәт бай Бакиров, Троицкидагы танылган сәүдәгәрләр, иганәчеләр, җәмәгать эшлеклеләре бертуган Габделвәли (1840–1906), Мөхәммәтсадыйк (1845–1899), Мөхәммәтшәриф (?–1906), Муллагали (1864–1926) Яушевлар, сәүдәгәрләр, алтын приискалары хуҗалары, җәмәгать эшлеклеләре, иганәчеләр бертуган Мөхәммәтшакир (1857–1914) һәм Мөхәммәтзакир (Дәрдеменд, 1859–1921) Рәмиевләр һ.б. булган.

Әлеге истәлектә шагыйрьнең чын физик сурәте дә тасвирлана: «Кыяфәттә урта буйлы, урта корсаклы, ак зур булып кыр борынлы, борынының очы могтәдил (уртача) иде. Сул колагының йомшагы илә аяк бармакларының өшегәннәре дә бар иде. «Бала вакытта өшеп төшкән», – дияр иде. Йөреше-торышында Шиһаб хәзрәтнең шәкерте Нәҗҗар хәлфә кеби иде. Әгәр дә Акмулланың портретын салам (ясыйм) дигән кеше булса, Нәҗҗар хәлфәнең портретын төшереп алса, һич хата булмас. Акмулла шадрасыз иде, әмма Нәҗҗар хәлфә шадра кеби иде. Троискига ишан хәзрәткә Нәҗҗар хәлфә зияратькә килгәнендә Акмулла килгән икән, дип, ничә мәртәбә ымсынып калганым бар». Әйтергә кирәк, әлеге мәгълүматка (ул өземтә матбугатта бар иде – Р. И.) һәм дин эшлеклесе, мәгърифәтче Хәбибен

нәҗҗар бине Мөхәммәткяфи Үтәкинең (1861–1921) сакланып калган фотосурәтенә нигезләнеп, Татарстанның халык рәссамы З. Гыймаев (1951–2022) шагыйрьнең портретын язды һәм ул бу җыентыкның тышлыгына да куелды. Билгеле ки, моңа кадәр рәссам Ә.Арсланов (1926–1987) күзаллавында язылган портрет кына киң таралыш алган иде.

Истәлектә шулай ук Акмулланың фаҗигале вафаты һәм аны соңгы юлга озату хакында мәгълүмат та шагыйрьнең тәрҗемәи хәленә шактый ачыклык кертүе ягыннан әһәмиятле. Якын киләчәктә без аңа аерым махсус мәкалә багышларга җыенабыз.

Педагог һәм телче-фольклорчы Х.Галинең Акмулланы өйрәнү, аның мирасын туплау юнәлешендә башкарган һәм әле беркайда да басылмаган хезмәте (Казахстан Фәннәр академиясенең кульязмалар фондында саклана: Папка 399, № 2) шулай ук бирелә урын алды. Кереш өлешендә ул болай яза: «1902 елдан башлап 1912 елга чаклы миңа Акмулланың үзеннән йөрергә туры килде. Акмулла Костанай, Петропавел, Күкчәтау өязләрендә кемнәрдә торган булса, мин дә шул кешеләрдә тордым, бала укыттым. Акмулла[га] тегелгән киез өйләрне мин туздырып киттем. Ул вакытта Акмулладан укыган кешеләр тере иде әле. Алар Акмулланың бик күп сүзләрен, шигырьләрен язып алганнар. Яттан белүчеләр дә күп иде. Акмулла үз кулы белән язган шигырьләрен, хатларын күп күрдем».

Дөрес, хезмәт вульгар социологизм рухында язылган булса да, андагы аерым фактлар, тупланган шигырьләр Акмулланы өйрәнү юнәлешендә кызыклы чыганакларның берсе булып тора. Шуңа күрә аны бу җыентыкта тулаем урнаштыру мәгъкуль күрелде.

Болардан тыш Акмулланың тормышы һәм иҗаты хакында төрле чорларда дөнья күргән аерым 14 мәкалә дә урнаштырылды. Алар, нигездә, киң даирә укучыга бик үк таныш булмаган, шагыйрь яшәгән тарихи чорның үзенчәлекләрен, аралашкан шәхесләрен чагылдырган, кульязма күчермәләрне барлау-җыйнауга һәм аларны фәнни нигездә өйрәнүгә, әсәрләренең тел үзенчәлекләренә багышланган язмалар. Кайберләрендә фикер каршылыклары да юк түгел. Бу табигый. Һәрхәлдә, текстлар белән якыннан танышканнан соң, ул хакта укучы үзе хөкем йөртер.

Җыентыкта китерелгән шигырьләрнең кем тарафыннан табылу тарихлары, беренче мәртәбә яки аннан соң басылган чыганаклары һәм бастыру өчен кайдан алынганлыклары күрсәтелеп барылды. Алай гына да түгел, әсәрләр, мөмкин кадәр беренчел чыганактан, ягъни кульязмалардан алынырга тырышылды. Моңа кадәр кульязма рәвешендә сакланып килгән һәм беренче тапкыр биредә басылган әсәрләрне дә әйтеп үтү урынлы булыр. Хосусан алар: «Әүвәлдә сүз башланыр бисмиллаһтан» дип башланган шигырьнең бер варианты, «Йа Хода, юлыңда улсын бу газиз җаным фида», «Кирей-Самайда Җансакалның хатынының кулын остаб әйткән», «Кузбайның өендә Даңдыбай әйткән» һәм «Хатимә»нең бер варианты. Ә «Мин нәбинең варисы», – дип, муллалар мактанса да» дип башланган шигырь тарихчы, археограф Җ.Миңнуллин (1953–2019) тарафыннан 2002 елда фәнни кулланылышка кертелгән иде.

Кушымтада Акмулланың Диния нәзарәтенә язган ике үтенече урнаштырылды. Алар шагыйрьнең шәхси тормышында булган кайбер вакыйгалар белән тулырак танышырга ярдәм итәр.

Билгеле булганча, 1989 елда Миякә районы хакимияте Мифтахетдин Акмулла исемендәге премия булдырды. Биредә шушы хакта Карар һәм 1989–2020 еллардагы премия лауреатларының исемлеге китерелде.

Башкортстан Республикасы Ә.Вәлиди исемендәге милли китапханәнең сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлеге хезмәткәре Ф.Тимашева (1981), мәгълүмат һәм библиография бүлеге хезмәткәре Г.Әхмәдиева (2006), М.Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогия университеты китапханәсе хезмәткәре В. Миронова (2006), филология фәннәре докторы Р.Исламов (2015) тарафыннан шагыйрьнең рус, башкорт һәм казах телләрендә биобиблиографик күрсәткечләре төзелеп нәшер ителгән иде. Бу җыентыкта үзенең шактый тулылыгы, корылыш системасы ягыннан аерылып торган яңасы тәкъдим ителде.

2007 елда Акмулланың тууна 175 ел тулу уңае белән Казанда үткәрелгән Төбәкара фәнни-гамәли конференциядә ясаган чыгышында М. Госманов болай дигән иде: «Акмулла иҗатын өйрәнү «Ул – безнеке, ул – сезнеке» дигән бүлешүгә кайтып калырга тиеш түгел. Ул нинди эшләр башкарган, аның иҗаты кай ягы белән әһәмиятле, нәрсәсе белән аерылып тора, уртак яклары нидән гыйбарәт – өйрәнүләр әнә шундый юнәлештә алып барылырга тиеш». Хезмәт галимнең шул мәсләгенә муафыйк рәвештә башкарылды.

Әйтергә кирәк, бу җыентык та шулай ук камил тулылыкка дәгъва итми. Чөнки киләчәктә Акмулла әсәрләренең башка төп нөсхәләре, күчермәләре тагын да табылуы ихтимал.

**Рәмил ИСЛАМОВ,**
филология фәннәре докторы.

# Озын гомерле ремонт

Бездә кайвакыт кирәкмәгән эшләр белән мавыгып китеп, кирәкле эшләрне эшләргә вакыт җитми, вакыт җитсә – теләк җитми, теләк булса – мөмкинчелек булмый, мөмкинчелек булса – акча юк дигән сылтау табыла. Үз милләтебезгә багышланган гамәлләрне башкарасы булганда, төрледән-төрле сәбәпләр уйлап чыгарылып, тоткарланып калган очракларны күз алдында тотып әйтүем. Үз дәүләтебезне саклап калу өчен сугышларда һәлак булган ата-бабаларыбызга һәм мәшһүр композиторыбыз Сара ханым Садыйковага багышлап куеласы һәйкәлләрнең, хөкүмәт карары чыгарылганнан соң да, хәзерге көнгә кадәр куелмаганлыгын күреп торабыз. Бу турыда төрле югарылыктагы җитәкчеләргә, депутатларга һәм президентка мөрәҗәгать итеп язуларның, газеталарда басылган мәкаләләрнең дә файдасы булмады. Ил башлыгының «иң мөһиме халык фикерен тыңлый белергә кирәк», – дигән сүзләрен ничек аңларга? Халык фикерен түгел, Төп Закон саналган Конституциядә бирелгән миллилек хокукларыбызны үтәргә ирек бирелмәгәндә, буш сүз сөйләүләрдән нәрсә көтәргә кала?

Бу мәкаләне Салих Сәйдәшев музее өчен борчылып язарга булдым. Мәшһүр композиторның музеены 2016 елдан бирле үзенең эшчәнлеге туктатылып, ремонтка ябылган булса, хәзерге көннәргә кадәр ремонт эшләре башкарылып бетмәве, дөресрәге, ремонт эшләре алып барылмавы ачыкланды. Музей җитәкчесенең төрле югарылыктагы түрәләргә мөрәҗәгать итүе уңай нәтиҗәләр китермәгән. Бу музейның ремонт эшләре хөкүмәт карары буенча башлангандыр дип уйларга кирәктер. Шулай булганда, ремонт эшләренә кирәкле сумма да, акча да каралган була бит инде. Бина әллә ни зур түгел, димәк ремонт эшләрен башкарып чыгу өчен, миллиард сумнар таләп ителмидер. Бу очракта, акча юклыгын сылтау итеп кую ышандырмый. Бер кирәге булмаган урыннарга галәмәт зур суммаларның агып торуын күрәбез.

Салих Сәйдәшевне сәнгатьсөяр халык кына түгел, кесә каракларына кадәр хөрмәт иткән бит. Бер елны Кызыл мәйданда хәрби парад Сәйдәшевнең Совет Армиясе маршы музыкасы белән алып барыла. Шул вакытта, Ворошилов аңа исемле сәгать бүләк итә. Ул сәгать караклар кулына эләгеп, С. Сәйдәшевнеке икәне билгеле булгач, аңа сәгатен шул көндә үк, гафу үтенеп, китереп бирәләр. Без шушы каракларга да түбән дәрәҗәдәге кешеләр түгелдербез бит?

**Рәфкать ИБРАҺИМ,**
Татарстан Республикасы Аксакаллар шурасы әгъзасы.

## Җинаятенә күрә җәзасы

Кайвакыт шулкадәр рәхимсез җинаять кылалар ки, нинди генә җәза бирсәң дә аз тоела. Кешелек тарихында иң озак вакытка төрмәгә утыртылганнар исемлегенең беренче дистәсенә керүчеләр белән танышыйк. Хатын-кызларны үтерү белән куркытып көчләүче Кейт Вудс 160 елга төрмәгә утыртылган. Талаучы һәм көчләүче Райан Бранд һәм Джеффри Колли икесе дә 265 әр елга ирекләреннән мәхрүм ителгән. Инвесторларны алдап байлык туплаган миллионер Шмидт 330 елга хөкем ителгән. Пенсия системасында эшләп, йөзләрчә АКШ гражданын алдаган Шалом Вайска башта 2 мең еллык срок чәпәгәннәр, аннары 845 елга калдырганнар. Талаучы, көчләүче Даррон Андерсон 2 мең ел төрмәдә утыруга хөкем ителгән. 1969 елда ике иранлының һәркайсына 7109 ар ел бирелгән. Калифорниядә үзенә ялланган 25 кешенең гомерен өзгән һәм аларны үз басуында җирләгән Хуан Коронага 25 гомерлек срок билгеләнгән. Флорида штатында иллеләп артык кызны көчләгән һәм шулардан яртысын үтергән маньяк Бобби Джо Лонг 28 гомерлек срокка хөкем ителгән. 1981 елда аеруча рәхимсезлек белән хатынын үтергән Дадли Вэйн Кизер 10 мең елга хөкем ителгән, аннары әбисен һәм бер студентны үтергән өчен тагын ике гомерлек срок өстәгәннәр. Дөнья тарихында иң озак вакытка – 384 912 елга хөкем ителгән хат ташучы исә 1972 елда Испаниядә яшәгән һәм беркемне дә үтермәгән, тик ялкаулыгы аркасында 4 меңнән артык хатны адресатларына тапшырмаган!

(“Newsweek”).

## Алма йөрәкне саклый

Британиядәге Оксфорд университеты галимнәре даими алма ашауның кешенең йөрәк-кан тамырлары системасына уңай тәэсир итүен дәлилләгән. Эш шунда: алмада калий һәм тимер күп, алар организмның иммунитетын ныгытуга булыша. Йөрәк авырулары килеп чыгу куркынычы 30 процентка кими икән. Тикшеренү алма яратучыларның, башка кешеләр белән чагыштырганда, йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан 12 процентка сирәгрәк интегүен күрсәткән. Белгечләр әйтүенчә, яшел алма анемия булганда бик файдалы, ә кызыллары гипертония ихтималын киметә.

(“Die Presse”).

## Заманага бирешмиләр

Ни гаҗәп тоелса да, Җиребездә әле кешеләр моннан мең ел элек ничек яшәгән, хәзер дә шулай яшәүче урыннар бар. Һинд океанындагы Төньяк Сентинель утравы – шуңа ачык мисал. Белгечләр фаразлавынча, сентинель кабиләсендәгеләр 60 мең еллап тулы изоляциядә яши. Һәм шул вакыт эчендә рәтләп ут табарга да өйрәнмәгән – кисәүне балчык чүлмәктә саклап, утны ничек тә сүндермәскә тырышалар. Утрау халкы беркем белән дә элемтә урнаштырырга теләми, үзләренә якынлашырга җөрьәт иткәннәргә һөҗүмгә ташлану җаен гына карый. 1974 елда “National Geographic” оешмасының кино төшерү төркеме утрауга керергә җыенгач, уктан атып, режиссерны яралаганнар. Галимнәр бүләккә алып килгән кокос һәм савыт-сабаны аборигеннар үзләре белән алып киткән, ә дуңгызны суеп, җиргә күмеп куйганнар. 2004 елгы цунамидан соң Һиндстан хакимияте утрауга вертолет җибәргән, тик аны да уктан атып каршылаганнар, кире борылырга мәҗбүр иткәннәр. 2006 елда ике браконьер балыкчыны үтергәннәр, аларның җәсәден алырга килгән вертолетларга тагын ук яудырганнар. Биредә күпме халык яшәве дә билгесез. 2001 елгы җанисәп алу вакытында 39 кеше – 21 ир-ат һәм 18 хатын-кыз дип, еректан күренгән кешеләрне генә санап язып куйганнар. Анда 500 ләп кеше яшәргә мөмкин. Сентинель кабиләсе – аралашырга яратмаган бердәнбер халык түгел. Мәсәлән, Эквадорда тагаери һәм тароменан халыклары, Бразилиядә Риу-Парду кабиләсе шулай яши. Кайбер халыкларны исә, мәсәлән, Андаман утрауларындагы джарава кабиләсен, цивилизация белән элемтә харап иткән: алар арасында төрле чирләр һәм наркомания таралган да, халыкның күпчелеге үлеп беткән.

(“The Local”).

## Иң озын кышкы юл

Кышкы чорга гына салына торган дөньяда иң озын юл Вапуск сукмагы дип атала. Ул Канаданың Онтарио штатында Гиллам, Манитоба һәм Пеаванук провинцияләрен тоташтыра. Озынлыгы 757 чакрымлы юл кар һәм боз өстеннән һәр елны гыйнварда салына һәм җирле халыкка берничә атна дәвамында Гудзон култыгы тирәсендә урнашкан ерак районнарга бару мөмкинлеге бирә. Җылы вакытта бу төбәкләргә һава транспорты белән генә барып җитеп була.

(“The Mirror”).

● Кайли Дженнер.

● Селена Гомес.

## Эшләп баю гаеп түгел

***Социаль челтәрләр хәзер чын бизнес мәйданчыгына әйләнде, анда һәркем акча эшләргә омтыла. Төрле тармакта дан казанучыларның акчасы болай да күп булса да, алар җиңел генә тагын бер-ике миллион эшләүдән бер дә тартынмый. Башта син исемеңне таныту өчен эшлисең, аннары инде исемең синә эшли: моны Инстаграмдагы (Россиядә эшчәнлеге тыелган социаль челтәр) реклама өчен гаять күп акча бирергә әзер булучыларның һаман арта баруы дәлилли. Әлеге челтәрдә иң күп акча эшләүче – супермодель Кайли Дженнер, ул үз сәхифәсендәге һәр реклама материалы өчен берәр миллион доллар ала. Ай саен кызга реклама бирүчеләрдән әллә никадәр тәкъдим керә, һәм аның байлыгы искиткеч тизлектә арта. Кайлиның косметика җитештерү линиясе 900 миллион долларга бәяләнә, әмма өстәмә керем чыганагы беркайчан да артык түгел. Икенче урында – бик популяр яшь җырчы һәм актриса Селена Гомес. Челтәрдәге һәр реклама сәхифәсе өчен чибәркәйгә 800 мең доллар түләнә. Өченче урында – Португалия футболчысы Криштиану Роналду. Аның 172 миллион язылучысы бар. Брендлар аңа бер реклама өчен 750 мең доллар түләргә риза.***

(“The Guardian”).

● Криштиану Роналду.

*Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.*

## Дүшәмбе

### 13 февраль
### «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «АЛМАШ». 16+
10.00, 23.00 «ТРИ ТОВАРИЩА». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.10 «ДЕТЕКТИВ ӘНИ». 12+
13.00 «Семь дней». 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Переведи!» 6+
16.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Әдәби хәзинә». 16+
19.00, 0.40 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
23.50 «Соотечественники». 16+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

5.30 «Калеб». 6+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Туган җир». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «КЕШЕЧӘ ЯШИК!» 16+
15.30, 20.30 «Заман көзгесе». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
19.00, 22.05 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

### «ЭФИР»

3.00, 7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
8.30, 23.00 «АКВАТОРИЯ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЧУЖАЯ КРОВЬ». 16+
11.30 «НЕЛЮБИМАЯ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «НЕ БЫЛО БЫ СЧАСТЬЯ». 16+
15.00 «Земля людей». 12+
15.30 «Бастионы России». 6+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

### «1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ПРОБУЖДЕНИЕ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 Подкаст.лаб. 16+

### «РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ШАЛЯПИН». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

### «КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Василий Жуковский.
7.35 «Звезда жизни и смерти».
8.15 Цвет времени. Эль Греко.
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50, 16.30 «ПРИМИТЕ ВЫЗОВ, СИНЬОРЫ!»
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Москва слезам не верит... Владимир Меньшов».
12.10 «Белоруссия. Коссовский замок».
12.40 Линия жизни. Александр Румянцев.
13.35 «Забытое ремесло».
13.50 «Евгений Вахтангов. У меня нет слез - возьми мою сказку».
14.30 «Секретные физики». Анатолий Александров.
15.05 Новости. Подробно. АРТ.
15.20 «Агора».
16.20 Цвет времени. Эдгар Дега.
17.40 Пианисты XXI века. Дмитрий Шишкин.
18.40 «История жизни».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.50 Больше, чем любовь.
21.30 «Сати. Нескучная классика...»
22.15 «ОПАСНЫЙ ПОВОРОТ».
23.50 XX век. «Москва слезам не верит... Владимир Меньшов».

### «НТВ»

4.50 «А.Л.Ж.И.Р.». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ДЕЛЬТА». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АКУШЕР». 16+
22.00 «МЕЛЬНИК». 16+

## Сишәмбе

### 14 февраль
### «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 15.00, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «АЛМАШ». 16+
10.00, 23.00 «ТРИ ТОВАРИЩА». 16+
11.00, 16.30 «Татарлар». 12+
11.30, 22.10 «ДЕТЕКТИВ ӘНИ». 12+
12.30 Хоккей. «Адмирал» - «Ак Барс».
15.15 «Төймә».
16.00 «Туган җир». 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00, 0.15 «Соотечественники». 16+
23.50 «Видеоспорт». 16+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 12+
9.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «КЕШЕЧӘ ЯШИК!» 16+
15.30, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.05, 22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

### «ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «АКВАТОРИЯ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЧУЖАЯ КРОВЬ». 16+
11.30 «НЕЛЮБИМАЯ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «НЕ БЫЛО БЫ СЧАСТЬЯ». 16+
15.00 «Рассекреченная история». 12+
15.30 «Бастионы России». 6+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

### «1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ПРОБУЖДЕНИЕ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 Подкаст.лаб. 16+

### «РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ШАЛЯПИН». 12+
23.25, 0.55 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

### «КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино. Лидия Смирнова.
7.35, 18.40 «История жизни».
8.20 Цвет времени. Пабло Пикассо. «Девочка на шаре».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50, 16.30 «ПРИМИТЕ ВЫЗОВ, СИНЬОРЫ!»
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Очевидное- невероятное. «Отражение».
12.20, 22.15 «ОПАСНЫЙ ПОВОРОТ».
13.35 «Игра в бисер» «Александр Пушкин. «Сказка о царе Салтане».
14.15 «Борис Борисович Пиотровский».
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20 «Эрмитаж».
15.50 «Сати. Нескучная классика...»
17.40 Цвет времени. Леонид Пастернак.
17.55 Пианисты XXI века. Николай Луганский.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.35 95 лет со дня рождения Сергея Капицы. Линия жизни.
21.30 «Белая студия».
23.10 Цвет времени. Караваджо.
23.50 XX век. «Очевидное-невероятное. «Отражение».

### «НТВ»

4.45 «А.Л.Ж.И.Р.». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ДЕЛЬТА». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АКУШЕР». 16+
22.00, 0.00 «МЕЛЬНИК». 16+

## Чәршәмбе

### 15 февраль
### «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «АЛМАШ». 16+
10.00, 23.00 «ТРИ ТОВАРИЩА». 16+
11.00, 0.15 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ДЕТЕКТИВ ӘНИ». 12+
13.00 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Если хочешь быть здоровым». 16+
14.15 «Туган авылым». 12+
15.15 «Бергәләп өйрәник».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00, 0.40 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Спортивная среда». 6+
23.50 «Соотечественники». 16+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
9.40 «Йөрәктән-йөрәккә». Илһам Шакиров турында телеочерк. 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «КЕШЕЧӘ ЯШИК!» 16+
15.30, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.00, 22.05 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.30 «Юлчы». 16+

### «ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «АКВАТОРИЯ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЧУЖАЯ КРОВЬ». 16+
11.30 «НЕЛЮБИМАЯ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «НЕ БЫЛО БЫ СЧАСТЬЯ 2». 12+
14.50 «Молодая наука». 12+
15.00 «Рассекреченная история». 12+
15.30 «Бастионы России». 6+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

### «1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ПРОБУЖДЕНИЕ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 Подкаст.лаб. 16+

### «РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ШАЛЯПИН». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

### «КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 Лето Господне.
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 18.40 «История жизни».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50, 16.35 «ГЛЯДИ ВЕСЕЛЕЙ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10, 23.50 XX век. «Ансамблю «Ариэль» 20 лет».
12.15 Дороги старых мастеров. «Балахонский манер».
12.30, 22.15 «ОПАСНЫЙ ПОВОРОТ».
13.20 «Первые в мире».
13.35 Искусственный отбор.
14.15 Острова. Николай Еременко.
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20 «Библейский сюжет».
15.50 «Белая студия».
17.40 Цвет времени. Жан Этьен Лиотар. «Прекрасная шоколадница».
17.55 Пианисты XXI века. Андрей Коробейников.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.50 Абсолютный слух.
21.30 Власть факта. «Северная Корея: опыт изоляции».

### «НТВ»

4.50 «А.Л.Ж.И.Р.». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ДЕЛЬТА». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АКУШЕР». 16+
22.00, 0.00 «МЕЛЬНИК». 16+

## Пәнҗешәмбе

### 16 февраль
### «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 15.00, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «АЛМАШ». 16+
10.00, 0.00 «ТРИ ТОВАРИЩА». 16+
11.00, 16.30 «Татарлар». 12+
11.30, 23.10 «ДЕТЕКТИВ ӘНИ». 12+
12.30 Хоккей. «Адмирал» - «Ак Барс».
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Казаннан - казанга». 16+
18.00 «Юлчы». 16+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Погружение на 100». 12+
21.10 «Ватандашлар». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Безнең Республика - безнең гамәл». 16+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 17.00 «Сагышларым, гомер агышларым». 6+
8.40 «Кунак БИТ Шоу». 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «КЕШЕЧӘ ЯШИК!» 16+
15.30 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10, 22.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
23.05 «Кәмит Җәвит». 16+

### «ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «АКВАТОРИЯ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЧУЖАЯ КРОВЬ». 16+
11.30 «НЕЛЮБИМАЯ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «НЕ БЫЛО БЫ СЧАСТЬЯ 2». 12+
14.50 «Молодая наука». 12+
15.00 «Рассекреченная история». 12+
15.30 «Бастионы России». 6+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

### «1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ПРОБУЖДЕНИЕ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 Подкаст.лаб. 16+

### «РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ШАЛЯПИН». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

### «КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 18.40 «История жизни».
8.20 Цвет времени. Илья Репин. «Иван Грозный и сын его Иван».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50, 16.35 «ГЛЯДИ ВЕСЕЛЕЙ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10, 23.50 ХХ век. «Мастера искусств. Народный артист СССР Николай Мордвинов».
12.20 «ОПАСНЫЙ ПОВОРОТ».
13.35 Абсолютный слух.
14.15 Острова. Чингиз Айтматов.
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 Моя любовь - Россия! «Свадебное платье для осетинки».
15.45 «2 Верник 2».
17.40 Пианисты XXI века. Дмитрий Маслеев.
19.45 Главная роль.
20.05 Открытая книга. Марина Письменюк. «Лабиринт из черёмухи».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.50 «15 лет тому... вперед».
21.30 XVI Зимний международный фестиваль искусств. Гала-концерт открытия фестиваля «Юрий Башмет - 70».
23.20 Цвет времени. Василий Поленов. «Московский дворик».

### «НТВ»
4.50 «А.Л.Ж.И.Р.». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ДЕЛЬТА». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АКУШЕР». 16+
22.00 «МЕЛЬНИК». 16+

## Җомга

### 17 февраль «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35, 14.45 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 16.00 «АЛМАШ». 16+
11.00 «Нәсыйхәт». 16+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00 «Ком сәгате». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я». 12+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
18.00 «Туган җир». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Көчтәнәч».
21.00 «Юлчы». 16+
22.10 «КВН РТ - 2023». 16+
23.10 «НАВСТРЕЧУ МЕЧТЕ». 12+

### ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 17.00 «Халык җырлары». 12+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 16+
9.40, 15.30, 0.15 «Нәсыйхәт». 16+
10.30 «Казаннан казанга». 16+
11.00, 15.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Татарлар». 12+
12.05, 21.25 «Рәгыйдь - яшен яшьнәү». Рәгыйдь Халитов турында телеочерк. 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 0.40 «Калеб». 6+
18.00 «Яңалыклар». 12+
18.20 «Илһам - вдохновение». 16+
19.15 «Туган җир». 12+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.30 «Заман көзгесе». 6+
22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

### «ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «АКВАТОРИЯ». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЧУЖАЯ КРОВЬ». 16+
11.30 «ПРАВО НА ЛЮБОВЬ». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «АНОНИМНЫЕ РОМАНТИКИ». 12+
14.45 «Молодая наука». 12+
15.00 «Рассекреченная история». 12+
15.30 «Прокуроры 5. Без срока давности. Крысиные тропы в Новый свет». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.20 «Fam TV». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

### «1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «Голос. Дети».
23.20 «КАК БЫТЬ ХОРОШЕЙ ЖЕНОЙ». 16+

### «РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.30 «Ну-ка, все вместе!» 12+
23.55 «Улыбка на ночь». 16+

### «КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «История жизни».
8.20 Цвет времени. Ван Дейк.
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50, 16.10 «ГЛЯДИ ВЕСЕЛЕЙ».
10.20 «ДОН КИХОТ».
11.35 Больше, чем любовь.
12.20 Дневник XVI Зимнего международного фестиваля искусств в Сочи.
12.50 Власть факта. «Северная Корея: опыт изоляции».
13.35 «Забытое ремесло».
13.50 Открытая книга. Марина Письменюк. «Лабиринт из черёмухи».
14.15 «Кузьма Петров-Водкин. Мне легко в этой необъятности».
15.05 Письма из провинции.
15.30 «Энигма. Вайклеф Жан».
17.15 Пианисты XXI века. Юрий Фаворин.
18.45 «Царская ложа».
19.45 «Смехоностальгия».
20.20 Линия жизни. Игорь Петренко.
21.15 «ЛАРЕЦ МАРИИ МЕДИЧИ».
22.45 «2 Верник 2».

### «НТВ»
4.45 «А.Л.Ж.И.Р.». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ДЕЛЬТА». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «АКУШЕР». 16+
22.00 «МЕЛЬНИК». 16+
23.50 «Своя правда». 16+

## Шимбә

### 18 февраль «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
7.00 «Şиңа Миннән Sәлам». 16+
9.00 «Кайнар хит». 16+
10.00 Хоккей. «Амур» - «Ак Барс».
12.30 «Видеоспорт». 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
13.30 «Гаилә учагы». 16+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.20 Спектакль «Гөлҗамал». 12+
16.50 «Казан» бию ансамбле концерты. 12+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 16+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «КунакБит- шоу». 16+
23.30 «ПЕРЕД ПОЛУНОЧЬЮ». 16+

### ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Әмирхан Еники турында телеочерк. 16+
7.00, 15.00 «Şиңа Миннән Sәлам». 16+
9.00 «Кайнар хит». 16+
10.00 «Кәмит Җәвит». 16+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 Спектакль «Күзләреңнән үбеп...» 16+
17.10 «Казаннан казанга». 16+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Егет чак, җырлар чак». Рөстәм Закировның юбилей кичәсе. 16+
22.30 «КЕШЕЧӘ ЯШИК!» 16+

### «ЭФИР»
5.15 «Молодая наука». 12+
5.30 «Дело №». 12+
6.30 «Тайные механизмы природы». 12+
7.00 «Супер МЯУ».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Русский граф Болгаров». 12+
8.45 «ХОЗЯЙКА БОЛЬШОГО ГОРОДА». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ГОЛЛИВУДСКИЙ ФИНАЛ». 12+
14.50 «Кавалеры ордена Александра Невского». 12+
15.00 «Звезда и смерть графа Вронского. Сербский гамбит». 12+
15.50 «ОСОБЕННОСТИ НАЦИОНАЛЬНОЙ МАРШРУТКИ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ДИКАЯ ЖИЗНЬ». 16+
22.50 «ИНДИЙСКОЕ ЛЕТО». 16+

### «1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «ПроУют».
11.10 «Поехали!» 12+
12.15 «Видели видео?»
13.25, 18.20 «СЕМНАДЦАТЬ МГНОВЕНИЙ ВЕСНЫ». 12+
19.15 «Сегодня вечером». 16+
21.00 «Время».
21.35 Концерт «Руки Вверх!» 12+
23.30 «НОТР-ДАМ». 16+

### «РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
12.00 «Доктор Мясников». 12+
13.05 «ВРАЧИХА». 12+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ЛЕТИ, ПЁРЫШКО». 12+

### «КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
8.10 «ЛАРЕЦ МАРИИ МЕДИЧИ».
9.40 «Мы - грамотеи!»
10.20 «Передвижники. Василий Перов».
10.50 «ДАЙТЕ ЖАЛОБНУЮ КНИГУ».
12.20 Дневник XVI Зимнего международного фестиваля искусств в Сочи.
12.50 «Эрмитаж».
13.20 Черные дыры. Белые пятна.
14.00 «Цефалоподы - покорители морей».
14.55 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
16.20 «Век Эркюля Пуаро и мисс Марпл королевы детектива Агаты Кристи».
17.10 «ТАЙНА «ЧЕРНЫХ ДРОЗДОВ».
18.45 Искатели. «В поисках «Русской красавицы».
19.35 Вспоминая Наталию Рязанцеву. Острова.
20.30 «ДОЛГИЕ ПРОВОДЫ».
22.00 «Агора».
23.00 «НЕБО НАД БЕРЛИНОМ».

### «НТВ»
4.50 «А.Л.Ж.И.Р.». 16+
5.40 «СТАЖЁРЫ». 16+
7.25 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!»
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 Научное расследование Сергея Малозёмова. 12+
14.00 «Новая высота». 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «ЧП. Расследование». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.25 «Секрет на миллион». 16+
23.25 «Международная пилорама». 16+

## Якшәмбе

### 19 февраль «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Халкыбыз мирасы». 12+
8.00, 13.00 «Адымнар». 16+
8.30 Мультфильмы. 6+
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Туган авылым». 12+
10.00 Хоккей. «Амур» - «Ак Барс».
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 16+
13.30 «Погружение на 100». 12+
13.40, 0.45 «Янам мәхәббәт дулкынында». Марат Фәйрушин. 12+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
16.00 «Ком сәгате». 16+
17.00 «Видеоспорт». 16+
17.30 «Соотечественники». 16+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 16+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 12+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.00 «ДОБРО ПОЖАЛОВАТЬ В КАПКАН». 16+

### ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 16+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
7.00 «Адымнар». 16+
7.30, 22.00 Спектакль «Мәхәббәт карагы». 16+
9.30 «Идрис Газиев тәкъдим итә. Моңга чорналган язмыш. Александр Ключарев». 16+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 6+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Гаилә учагы». 12+
13.50 «Ике аккош». Фатих Кәрим. 16+
14.20 «ЯЛГЫЗ ТӘКӘРЛЕК». 16+
16.20, 21.10 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 16+
20.00 «Семь дней». 16+

### «ЭФИР»
5.15 «Молодая наука». 12+
5.30 «Дело №». 12+
6.30 «Тайные механизмы природы». 12+
7.00 «Супер МЯУ».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Звезда и смерть графа Вронского. Сербский гамбит». 12+
8.50 «ОСОБЕННОСТИ НАЦИОНАЛЬНОЙ МАРШРУТКИ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ДИКАЯ ЖИЗНЬ». 16+
14.50 «Кавалеры ордена Александра Невского». 12+
15.00 «Русский граф Болгаров». 12+
15.45 «ХОЗЯЙКА БОЛЬШОГО ГОРОДА». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ГОЛЛИВУДСКИЙ ФИНАЛ». 12+
23.00 «ЖЕНЩИНА В ЗОЛОТОМ». 18+

### «1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10, 14.00, 23.30 Подкаст.лаб. 16+
7.00 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.45 «Часовой». 12+
8.15 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 «Жизнь своих». 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 «Видели видео?»
16.25 «Век СССР». «Восток». 16+
19.00 «Три аккорда». 16+
21.00 «Время».
22.35 «КОНТЕЙНЕР». 16+

### «РОССИЯ»
6.15 «СТРАХОВОЙ СЛУЧАЙ». 16+
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
12.00 «Большие перемены».
13.05 «ВРАЧИХА». 12+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

### «КУЛЬТУРА»
6.30 Мультфильмы.
7.55 «ЧЛЕН ПРАВИТЕЛЬСТВА».
9.35 Тайны старого чердака. «Форма имеет содержание».
10.05 Диалоги о животных.
10.50 «МОРЕ СТУДЕНОЕ».
12.20 Дневник XVI Зимнего международного фестиваля искусств в Сочи.
12.45 Невский ковчег. Теория невозможного. Федот Шубин.
13.15 «Игра в бисер» «Поэзия Евгения Рейна».
13.55 К 250-летию Большого театра России. Елена Образцова и Владимир Атлантов в опере Ж. Бизе «Кармен».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 «Первые в мире».
17.30 «Пешком...»
18.00 150 лет со дня рождения Георгия Сперанского. Корифеи российской медицины.
18.35 «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
20.10 «ДАЙТЕ ЖАЛОБНУЮ КНИГУ».
21.40 Великие Имена. Владимир Горовиц.
22.35 «ФЛИБУСТЬЕР».

### «НТВ»
4.50 «СТАЖЁРЫ». 16+
6.35 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.55 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Человек в праве с Андреем Куницыным». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Маска». 12+
23.30 «Звезды сошлись». 16+



# Биниһая зур иҗат

**Татарстанның халык шагыйре, күренекле әдип, балалар язучысы, җәмәгать эшлеклесе Роберт Миңнуллин турында үткән заманда сөйләү дә, язу да сәер тоела. Ләкин ни эшләмәк кирәк: каләм иясе хәзер әсәрләрендә, шул әсәрләре дөнья күргән китапларында, укучыларының, каләмдәшләренең күңелендә яши.**

Әле генә Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Мәхәббәтле күзләрем» китабының кульязмасын Роберт абый үзе алып килгән иде. Ул аны миңа тапшырды да: «Сүз башы Ленар Шәехнеке инде, яме?» – диде. Яраткан шагыйрем, остазымның сүзләрен сөенеп, зур җаваплылык белән кабул иттем. Кайчандыр үзе, Татарстан Язучылар берлегенә керү өчен, миңа тәкъдимнамә, «Дүртенче кат... Бишенче кат...» китабыма сүз башы язган иде. Еллар дәвамында һәрвакыт аның игътибарын тоеп, киңәшләрен тыңлап, фикерләрен ишетеп яшәдек бит. Татар халкының олы шагыйре, чәчләренә чал керсә дә, заман белән бергә атлаучы, тормышка елмаеп караучы чын шәхес иде.

Күпләр кебек, мин дә аның белән балачагымда ук таныштым. Безне «Энекәш кирәк миңа» китабы дуслаштырды. Елмайта торган, сүз уйнатуларга корылган, шаян, шул ук вакытта балаларны тәрбияләүгә нигезләнгән шигырьләрне кем генә яратмас икән?!

1991 елда туган авылым Такталачыкта (Актаныш районы) яңа ике катлы таш мәктәп ачылды. Тантанада, шагыйрь һәм халык депутаты буларак, Роберт абый да катнашты, чыгыш ясады. Миңа, икенче сыйныф укучысына, аны күрү гомергә истә калырлык зур вакыйга иде.

Казан дәүләт университетында укый башлагач, Роберт абый белән якыннан аралаштык. «Күңелләр нечкәргәндә...» дигән китабына, күзәтү ясап, бәяләмә язарга туры килде. Актанышның Сабан туе мәйданында узган 60 яшьлек юбилеенда, туган авылы Шәммәттә (Илеш районы) үткән 70 яшьлегендә кунак булып катнаштым. Төрле театр сәхнәләрендә узган иҗат кичәләрен, балалар бакчалары, мәктәпләрдәге очрашуларны санап та тормыйм. Әйе, Роберт абый гел халык арасында булды, һәрвакыт үз артыннан дусларын, шәкертләрен ияртте, остазларына игътибарлы булырга да онытмады.

Соңгы елларда әдәби тәрҗемә эше белән ныклап шөгыльләнде: төрекмән шагыйре Мәхтүмколый, төрек шагыйре Али Акбаш, удмурт шагыйре Вячеслав Ар-Серги, казах шагыйре Нурлан Оразалин, Черногория шагыйре Душан Джуришич, башкорт шагыйрьләре Факиһа Тугызбаева, Хәсән Назар һ. б. ның шигырьләрен татар теленә әйләндерде, аерым җыентыкларын чыгарды. Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев, Башкортстанның халык шагыйре Нажар Нәҗми, Татарстан һәм Башкортстанның халык артисты Фәридә Кудашевалар турында саллы-саллы истәлек китаплары төзеде.

Ахырга таба, социаль челтәрдә үз сәхифәсен булдырып, иҗатын бар дөнья белән бүлешә башлады. Языучыларының саны 50 меңгә җитте. Көн кадагына суга торган, туган телнең һәм милләтнең киләчәген кайгырткан шигырьләре, лирик һәм фәлсәфи, юмор хисе катыш әсәрләре шактый языла.

Яңа гына дөнья күргән «Мәхәббәтле күзләрем» дип аталган китапта Роберт Миңнуллинның әле ташка басылып өлгермәгән яңа шигырьләре һәм элегрәк язылган сайланмалары урын алган. Чыннан да, биниһая зур иҗат! Әле бу – зур тауның бер өлеше генә. Татар әдәбияты классикасын тәшкил иткән балалар шигырьләре, татар эстрадасының алтын фондына кергән җырлары, туры сүзле һәм объектив фикерле публицистик һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре, тәрҗемәләре һ. б. Саный китсәң, әдипнең иҗат канатлары күп. Иҗаты чын бриллиант кебек: кайсы яктан карасаң да, үзенә күрә бер матурлык, яктылык белән балкый, күңелгә көрлек, җылылык бирә, дәрт өсти.

Роберт абыйның рухы шат, иҗаты мәңгелек булсын!

**Ленар ШӘЕХ.**

### Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

**10 февраль** – «Өйләнәм.tat» (И.Зәйниев).
**11 февраль** – 15.00 – Шәрык клубында балалар өчен «Нәни куллар» дип исемләнгән рәсем дәресе. 18.00 – «Миркәй белән Айсылу» (Н.Исәнбәт).
**12 февраль** – «Бию пәрие» (И.Зәйниев).
**13 февраль** – Кече залда – «Көл» (К.Митани). Зур залда – «Җанкисәккәем» (Т.Миңнуллин).
**14 февраль** – Кече залда – «Исәнме, улым!» (Б.Абдураззоков). Зур залда – Чаллы Татар дәүләт драма театрының «Яшь йөрәкләр» спектакле (Ф.Бурнаш).
**15 февраль** – Зур залда – Чаллы Татар дәүләт драма театрының «Капка» спектакле (А.Әхмәтгалиева). Кече залда – «Җәйнең бер көнендә» (Й.Фоссе).
**16 февраль** – 14.00 – Театр оркестры концерты. 19.00 – Чаллы Татар дәүләт драма театрының «Болан» спектакле (А.Гыйләҗев).
**17 февраль** – «Тормышмы бу?..» (Г.Исхакый).

### М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

**30 гыйнвар** – 28 февраль Ф.Шаляпин исемендәге XLI халыкара опера фестивале:
**11 февраль** – «Набукко» (Дж.Верди).
**13 февраль** – «Борис Годунов» (М.Мусоргский).
**17 февраль** – «Царская невеста» (Н.Римский-Корсаков).

### К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

**10 февраль** – «Хыялый» (С.Әбүзәров).
**11 февраль** – «Кияү урлау» (С.Юзеев әсәре, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).
**12 февраль** – «Өч аршын җир» (А.Гыйләҗев).
**14 февраль** – «Гашыйклар тавы» (И.Юзеев).
**15 февраль** – «Хан кызы Турандык» (К.Гоцци).

### Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

**10 февраль** – «Йосыф» (Кол Гали).
**11 февраль** – 13.00 – «Бәхетле көнем» (Е.Гороховская). 18.00 – «Кичер мине, әнкәй» (Р.Батулла).
**12 февраль** – «Ак чәчәкләр кебек...» (Р.Мухина).
**14 февраль** – 13.00 – «Асылкош җыры» (Р.Мөхәммәтшин). 18.30 – «Мәхәббәт күгәрченнәре» (В.Гуркин).
**16 февраль** – «Ромео һәм Джульетта» (В.Шекспир).

### «ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

**10 февраль** – 11.00 – «Буратино» (А.Толстой). 19.00 – «Әлдермештән Әлмәндәр» (Т.Миңнуллин).
**11 февраль** – зур залда – «Красная шапочка» (Ш.Перро). Кече залда – «И, кызык Шүрәле» (Г.Зәйнашева).
**12 февраль** – Зур залда – «Сказки Маршака» (С.Маршак). Кече залда – «Бүре җиләге» (Р.Зәйдулла).
**17 февраль** – «Дитя Аллаха» (Н.Гумилев).

### Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

**10 февраль** – Татарстан Республикасы фольклор музыкасы дәүләт ансамбленең осталык дәрес-концерты.
**11 февраль** – «Доктор Ватсон» төркеме концерты.
**13 февраль** – «Иисус Христос – суперзвезда» рок-операсы.
**14 февраль** – «Гашыйклар өчен джаз» дип исемләнгән концерт.
**16 февраль** – Романслар кичәсе.
**17 февраль** – Бөек композитор П.И.Чайковскийның иҗатына багышланган концерт.

### С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

**10 февраль** – «La Primavera» Казан камера оркестры концерты.
**12 февраль** – Казан хореография училищесы укучылары концерты.
**13 февраль** – Җырчы Ф.Шаляпин һәм композитор С.Рахманиновның 150 еллыгына багышланган «Шаляпинны илһамлы иткән Казан» исемле концерт. Катнашалар – Россиянең атказанган артисты Б.Березовский, «Новая опера» Мәскәү театры солисты В.Ладюк, С.Гобәйдуллинаның заманча музыка үзәгенең дирижер А.Гөлишамбарова җитәкчелегендәге оркестры, Татарстан Республикасының М.Тәминдарова җитәкчелегендәге дәүләт камера хоры, Татарстанның халык артисты И.Славутский (нәфис сүз).

Мәдәни җомга

# Аладдин маҗаралары

*«Әкият» Татар дәүләт курчак театрында 2023 елның беренче премьерасы булып «Аладдин» спектакле сәхнәләштерелде. Тамаша шәрыкчә музыка, перчатка-курчаклар, мәхәббәтле Җен белән истәлекле.*

Курчакларның холык-фигыльләре йөзләрендә язылган. Аларның сәнгати кыйммәтен әйтеп бирү өчен авторы, С.Образцов исемендәге курчак театрының баш рәссамы, күп тапкырлар «Алтын битлек» премиясе иясе Виктор Антонов исемен әйтү дә җитә. В.Антонов рәссам гына түгел, актер, режиссер, драматург та. Үзе курчаклар иҗат итеп кенә калмый, бүтән иҗат ияләрен дә бу һөнәргә өйрәтә. Сәнгать белгечләре әйтүенә караганда, Антоновның иҗаты образларның кәмит рәвеше, сәхнә күренешләренең шигъри аһәңе, җете метафоралар, стиль төрлелегеннән гыйбарәт. Шуңа өстәп, ул – төрле трюклар башкара торган марионеткалар остасы да. Марионетка, перчатка, таякчыклы курчаклар белән идарә итүдә Антоновка тиңнәр юк.

Латин Америкасыннан алып Көньяк Кореяга кадәр курчак театрлары, Антонов белән хезмәттәшлек итәргә теләп, чиратка тезелгән, ди. «Әкият» театрының сәнгать җитәкчесе, «Аладдин» спектакленең режиссеры Илгиз Зәйниев шундый дәрәҗәдәге рәссамны кулга төшерә алган икән, сәнгать дөньясында абруе зур, сүзе үтә, димәк. Спектакльнең ярты уңышын Антоновның курчаклары билгеләсә, Зәйниев стиленә хас җиңеллек, хәзерге заманда кулланышта булган кызыклы төрткеле сүзләрне кертеп җибәрү шулай ук нәни тамашачыларның мәхәббәтен яулады.

Эльмир Низамовны төрле жанрларда иҗат итүче композитор буларак беләбез. Һәм бүгенге көндә иң актив автор да ул. «Аладдин» спектаклендә Эльмир, чыннан да, шәрыкчә мелизмнар кулланып иҗат итәргә тырышкан. Әмма музыкаль бизәлештә урыны-урыны белән барыбер Европа музыкасы аһәңнәре ишетелеп китә, геройлар өчен язылган бериш җырларда да, күренешләргә туры китереп иҗат ителгән кайбер музыкаль өлешләрдә дә Низамовның Европа классик музыкаль традицияләренә иярүен ишетми мөмкин түгел.

Спектакльдә рольләргә икешәр состав артистлар билгеләнгән. Премьера көнне Аладдинны, мәсәлән, Илсур Минкеев башкарды. Бу рольдә Айвар Гыймаевның да уңышка ирешәсенә бернинди шик юк. Чибәр Будурны Юлия Василишина һәм Ирина Гайнуллина алмашып уйнаячак. Явыз вәзир – Эдгар Гайнуллин. Сөйләме белән генә дә шәрык хатыны образы иҗат итүгә ирешкән Алсу Хәйсарова күңелгә уелып калды. Аладдинның әнисен Алсу белән алмаш-тилмәш Гүзәл Гаязетдинова да уйнаячак. Солтан образын Сергей Кузнецов гәүдәләндерә.

Җен образын тамашаның йөзек кашы дияргә мөмкин. Ул курчак рәвешендә дә, тере планда да гәүдәләндерелгән. Бу рольне күренекле артистыбыз Дилүс Хуҗәхмәтов башкара. Нәни курчаклар янәшәсендә артист шундый зур күренә ки, бу иҗат алымын режиссер Җеннең кодрәтен, көчен ассызыклар өчен махсус кулланган, дип уйларга мөмкин. Дилүснең сәхнә сөйкемлелеге һуштан яздыра. Җеннәрнең җене, бөтен тамаша залын үзенә гашыйк итәрлек Җен ул! Бер артистта шулкадәр талант, дәрт, импровизация осталыгы булыр икән!

Спектакль Камал театрыннан хореограф Сәлимә Әминова куйган биюләр һәм «Казан» журналының баш мөхәррире, шагыйрә Альбина Әпсәләмова сүзләренә иҗат ителгән җырлар белән үрелеп бара.

«Аладдин»ны төрле куелышларда күргән бар. Гарәп егете хәтта Голливудта да гәүдәләндерелде. Һәр спектакль үзенчә матур. Казан тамашасында исә мәхәббәтнең сихри көченә басым ясала. Мәхәббәт ул – үзе могҗиза. Аңа ирешер өчен, тылсымлы Җеннәргә ышанып ятмаска, үзеңә тырышырга кирәк, дияргә тели сыман авторлар.

**Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.**





ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

**Вахит Шәих улы ИМАМОВ**

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

**Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)**

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

**Индекс П2355**

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кулъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

**Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:**

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

**НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ**

420097, Казан, Академия урамы, 2

**Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:**

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

**Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 10.02.2023**

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе иреклe

Тираж – 2600 данә

Заказ 2604

16+